ЯШӘР ӨЧЕН ЖИҢҮ

«ВТ» журналисты – янә «кызыл зона»да

> 7

МИНЕМ ТАТАРСТАНЫМ

Азнакай районына сәяхәт

> 9-12

ЮЛ ЧАТЫНДА КАЛГАНДА...

Татар әдәбиятында фантастика ни өчен юк?

> 18-19

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 176 (28758) | Җомга | 3 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

pixabay.com

ТАБИГАТЬ САТАШТЫ

КИЛӘЧӘКТӘ ҺАВА ТОРЫШЫННАН НӘРСӘ КӨТӘРГӘ?

Көз – көзгә, кыш кышка охшамаган хәзер. Агачлар ут янып утырган сентябрьдә кар төшә. Җир өстенә, ниһаять, кар ятты дип сөенергә дә өлгермисең, коеп яңгыр яварга тотына. Һәрхәлдә, быелгы кышны әнә шундый елак һава торышы белән каршыладык. Табигать елдан-ел саташа, кыскасы. Галимнәр исә бу саташу киләчәктә бик кыйммәткә төшәргә мөмкин дип кисәтә.

> 5

Ишетми калмагыз

Карантинга ябылган мәктәпләр юк

Татарстанда балаларның ОРВИ йоктыруы сәбәпле карантинга тулысынча ябылган мәктәпләр юк. Роспотребнадзорның республика буенча идарәсе башлыгы Марина Патяшина шулай дип белдергән. «Сыйныфны карантинга җибәрү-җибәрмәү мәсьәләсен уку йорты үзе хәл итә. Сыйныфтагы балаларның 20 проценты ОРВИ сәбәпле авырып китсә, сыйныф бер атнага карантинга җибәрелә», – дигән баш санитар табиб.

Марина Патяшина фикеренчә, балаларның еш авыруы гриппка каршы прививка ясатучылар саны аз булуга бәйле. «Күмәк урыннарда вакцинация – чиктән тыш мөһим. Ата-аналарга мөрәҗәгать итәм: әле соң түгел – 15 декабрьгә кадәр балаларыгызга гриппка каршы прививка ясатып, аларның сәламәтлеге турында кайгыртсагыз иде», – дигән ул. Сүз уңаеннан, республикада гриппка каршы вакцинация 15 декабрьдә төгәлләнә.

Белешмә бер ел гамәлдә була

Коронавирус белән авырганны раслаган белешмә хәзер савыкканнан соң бер ел гамәлдә булачак. Бу хакта Россия сәламәтлек саклау министры ярдәмчесе Алексей Кузнецов белдергән, дип хәбәр итә «РИА Новости». Аның әйтүенчә, яңа документларның барысы да шушы чорга рәсмиләштерелә, моңа кадәр бирелгәннәре 12 айга озайтыла. «Техник эшләр якын арада төгәлләнәчәк. Кирәкле барлык карарлар кабул ителде», – дигән Кузнецов. Исегезгә төшерәбез: моңа кадәр андый документ алты ай гына гамәлдә булды. Россия сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко аңлатып үткәнчә, документның гамәлдә булу вакытын ике тапкыр арттыру ковид инфекциясен кабат йоктыручылар саны кимүгә бәйле. Кабат чирләүчеләр нибары 0,74% тәшкил итә.

Чемпионга фатир бүләк иттеләр

Казан мэры Илсур Метшин Олимпия чемпионы Марта Мартьяновага фатир алу өчен башкала иганәчеләре әзерләгән сертификатны тапшырган. Шәһәр башлыгы Мартаның Казанда яшь фехтование осталарын тәрбияләүдә катнашуына, вакытлар узу белән Татарстан башкаласында даими эшләвенә ышанычын белдергән. «Казанда фехтование буенча бөек спортчыларның берничә буыны бар иде инде. Сезнең үрнәккә ияреп, әлеге спорт төренә кызыксынуның көчәюенә өметләнәбез», – дигән ул.

Исегезгә төшерәбез: Казан спортчысы Марта Мартьянова быел җәен Токиодагы Олимпия уеннарында, аягын имгәтүгә карамастан, ахырга кадәр көрәшеп, команда ярышларында алтын медаль яулады.

Районнарда ни хәлләр?

Балтач

Россия җыелма командасы составында чыгыш ясаган спорт остасы Чулпан Габделганиева Төркиянең Анталия шәһәрендә мөмкинлекләре чикле спортчылар арасында шашка уеннары буенча дөнья чемпионатында беренче урынны алды. «Балтачыбызның нык ихтыяр көченә ия спортчы кызын хәзер дөнья күләмендә дә танышлар! Уңышларың дәвамлы булсын, Чулпан, без синең белән горурланабыз! Нинди генә хәлдә дә ярышларга әзерлек белән барып, үз максатыннан тайпылмавың өчен сиңа, ерак юлларны якын иткән туганнарыңа, олы йөрәкле остазларыңа рәхмәтемне җиткерәм. Сәламәтлек,якты киләчәк телим!» – дигән район башлыгы Рамил Нотфуллин. («Хезмәт»)

Мамадыш

Мамадышта шәһәргә нигез салучыга һәйкәл куярга җыеналар. Аны Мәмдәш дип тә, Мәмәйдеш дип тә, Мамадыш дип тә атыйлар. «Һәйкәлдә Мамадышка нигез салучының көймәдәге образы гәүдәләндерелә. Ул көймәгә басып офыкны күзәтә, кулында нәселе штандарты. Аның очына кадәр биеклеге 8 метр 60 сантиметр булачак. Ә нигез салучының үз биеклеге – 3 метр 20 сантиметр. Һәйкәлнең скульпторы – Николай Афанасьев бюстының авторы Мәскәүдән Алексей Чебаненко. Нократ яр буе тирәнәйтелгәч, анда теплоходлар белән туктау мөмкинлеге дә булачак, шуны күз алдында тотып, ул тирәләргә причал да эшләнәчәк», – ди районның баш архитекторы Рамил Минһаҗев. («Нократ»)

Арча

4 декабрьдән Кыш бабай һәм Кар кызы резиденциясендә кышкы сезон башлана. Тамашачылар бәйрәм программасын карый һәм Яңа ел тылсымчысының өенә керә ала. Әмма моның өчен аларга коронавирустан вакцинация турында QR-код кирәк. Шулай ук вакцинация ясатмау өчен медицина күрсәтмәсе булган очракта да резиденциягә керергә мөмкин. Оештыручылар кунакларга уеннар, әйлән-бәйлән, салют һәм башка сюрпризлар вәгъдә итә. («Арча-информ»)

Питрәч

Районның үзәк китапханәләр системасы Татарстанда тел күптөрлелеген саклау буенча грант конкурсында җиңүче булды. 500 мең сумга Питрәчтә өлкәннәр китапханәсендә балаларны мультипликациягә өйрәтү буенча беренче туган якны өйрәнү түгәрәге булдырылачак. Проект «Күпмилләтле буынлар» дип атала. «Без балалар белән төрле милләтләрнең гореф-гадәтләре һәм йолалары турында мультфильмнар ясаячакбыз. Алар сценарийлар уйлап табачак, декорацияләр әзерләячәк, геройлар ясаячак, аларны тешерәчәк һәм туган телдә тавыш яздырачаклар. Мәктәп укучылары, шулай ук коррекцион интернат-мәктәбендә тәрбияләнүчеләрне җәлеп итәргә планлаштырабыз. Түгәрәк бушлай булачак», – дип сөйләде проект авторы Алсинә Карсакова. («Алга»)

СОРЫЙ БЕЛЕП СОРАСАҢ...

Бер эшмәкәр дә ярдәмсез калмас. Республиканың эшмәкәрләр йортында узган очрашуда Дәүләт Думасы депутаты Айдар Метшин шулай дип ышандырды. Урта һәм кече эшмәкәрләр 15 декабрьгә кадәр хөкүмәттән бер тапкыр бирелә торган грантка дәгъва итә ала. Россия Президенты Владимир Путин карары белән бу максатка барлыгы 38,5 миллиард сум акча бүлеп бирелгән.

«Татар-информ»

Пандемия чорында аеруча зыян күргән күп кенә оешмалар бу грантларны алырга өлгергән инде. Бигрәк тә кунакханә, җәмәгать туклануы, спорт, өстәмә белем бирү, кинокүреш, мәдәният, күңел ачу юнәлешендә хезмәт күрсәткән оешмалар турында сүз бара. Депутат сүзләренә караганда, коронавируска каршы кертелгән яңа чикләүләр шартларында кече һәм урта эшмәкәрләр, ярдәм сорап, ешрак мөрәҗәгать итә башлаган.

«Дәүләт органнары, эшмәкәрләрнең хәленә кереп, хезмәт хакы түләү өчен минималь хезмәт хакы күләмендә субсидия, 3 процент ставка белән ташламалы кредит бирүне күздә тоткан ярдәм чаралары кабул итте. Без, хөкүмәтнең закон чыгару һәм башкарма органнары, Татарстандагы эшмәкәрләрнең бу мөмкинлектән файдалануын телибез. Аларның берсе дә ярдәмнән читтә калырга тиеш түгел», – диде Айдар Метшин.

Очрашуда эшмәкәр түрәләргә үзләрен борчыган сорауларны да ирештерә алды. Татарстанның рестораторлар һәм отельерлар ассоциациясе президенты Зөфәр Гаязов иң табышлы чор саналган Яңа ел төнендә һәм бәйрәм ялларында иркенләп эшли алмауларына борчыла. «Бу чорда безнең өчен чикләүләрне бераз йомшартсагыз иде. Шушы көннәрдә эшләвебез аркасында без тагын 2–3 ай тынычлап яши алабыз әле», – дип мөрәҗәгать итте ул. Татарстан Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев бу мәсьәләне хәл итү өчен җәмәгать туклану урыннарының бәйрәм көннәрендә эшләү тәртибе буенча төгәлрәк тәкъдимнәр җиткерергә кушты.

Эшмәкәрләрдән килеп ирешкән чираттагы сорау хезмәт хаклары мәсьәләсенә багышланган иде. Айдар Метшин Россия Дәүләт Думасы кабул иткән закон нигезендә минималь хезмәт хакы күләменең киләсе елдан 8,6 процентка артачагын белдерде. «Бу, үз чиратында, яшәү минимумы күләме артуга да китерәчәк. Аны баштарак планлаштырганча 2,5 процентка түгел, ә 8,6 процентка арттыру күздә тотыла», – диде депутат. Очрашуга җыелган эшмәкәрләр чүп өчен норматив буенча түгел, ә күпме чүпләсәң, шул өлеш өчен генә түләргә рөхсәт итүләрен дә сорады.

Якын арада Татарстанның яшь эшмәкәрләренә дә финанс ярдәме күрсәтәчәкләр. «Старт» микрозаемы кысасында алар минималь ставка буенча (елга 4,5 процент күләмендә) кредитка өметләнә ала. Микрозаем Татарстан югары уку йортлары студентлары һәм аны тәмамлаучылар өчен Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды тарафыннан эшләнгән. Гариза бирү шартлары һәм документлар турында тулырак мәгълүмат Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды сайтында урнаштырылган. Гаризалар 30 декабрьгә кадәр порталда кабул ителәчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Депутатлар сезне тыңлый

«Бердәм Россия» партиясе рәисе Дмитрий Медведевның төбәк иҗтимагый кабул итү бүлегендә, «Бердәм Россия»гә 20 ел тулуга багышлап, республикада яшәүчеләрне кабул итү декадасы башлана. Ул 10 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Кешеләрнең гозер-үтенечләрен Дәүләт Думасы депутатлары, республика Дәүләт Советы депутатлары тыңлый. Һәр көн аерым темага багышлана.

Кабул итүне партиянең Татарстандагы төбәк бүлеге секретаре урынбасары Юрий Камалтынов башлап җибәрде. «Татарстанда 2014 елдан башлап сайлаулар барышында алынган барлык наказлар тупланып өйрәнелә. Без Президентка мөрәҗәгать итәбез, ә ул Хөкүмәткә, тегe яки бу эшнең кайчан башкарылачагын күрсәтеп, һәр район буенча «юл картасы»н эшләүне йөкли», – дигән ул.

Яшел Үзәннән Нариман Сәйфетдинов Чапаев урамыннан Октябрь урамына кадәр тротуар төзелешен тәгәлләү үтенечен җиткергән. Аның әйтүенчә, 200 метр араны эшлисе калган. Тик мәсьәлә һаман хәл ителми: шәһәр хезмәтләре белән уртак тел табып булмый икән. «Юл эшләре программасы эшләнгән, әмма анда бу «200 метр» юк. Шуңа да карамастан, 2023 елга кадәр әлеге мәсьәләне хәл итәчәкбез. Район башлыгы белән эшләячәкбез, ул 2023 елга кадәр һич югында тротуарның бер өлешен салу мөмкинлеген табачак», – дип ышандырды Камалтынов.

Шушы ук районнан Ирина Андросованы ишегалдын төзекләндерү мәсьәләсе борчый. Ул үзләренең ишегалдын заманчага әйләндерергә тели. Юрий Камалтынов Ирина ханымга ишегалдының кайчан төзекләндереләчәген ачыкларга вәгъдә итте. Партия төбәк бүлеге секретаре урынбасары сүзләренә караганда, нәкъ менә Яшел Үзән ишегалларын төзекләндерү проектын беренчеләрдән булып башлап җибәргән икән, бу ишегалды гына игътибардан читтә калмаска тиеш.

Ә инде Илгәр Мохтәров Яңа Тура бистәсендәге йортларны газлаштырып бетерү үтенечен җиткергән. «Бары тик рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләре һәм күчемсез милек объектлары гына газлаштырып бетереләчәк. Сездә милеккә хокукыгызны раслаучы документлар булырга тиеш. Бар икән, мәсьәлә якын арада хәл ителәчәк», – дип аңлатты Камалтынов.

Сабыйларда кунакта

ДРКБның Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәгендә дәваланучы сабыйларга «Батырлык тартмасы» акциясе кысасында җыелган бүләкләр тапшырдылар.

Бүләкләрне Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов һәм Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова тапшырды.

Светлана Захарова әйтүенчә, Татарстанда балалар иҗаты өчен уенчыклар, язу-сызу әйберләрен җыю буенча акция 15 ноябрьдә башланган. Аны «Бердәм Россия» тарафдарлары советы һәм гражданлык инициативалары үзәге тәкъдим иткән. Акциягә депутатлар, эшмәкәр, танылган блогерлар кушылган. «Бу акция белән без сабыйларның хастаханәдә үткәрелгән авыр көннәрен ничек тә җиңеләйтергә тырыштык», – ди комитет рәисе.

Айрат Фәррахов, сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева һәм «Татарстанда балалар спорты» партия проекты җитәкчесе Ольга Павлова исә Балалар республика хастаханәсендә кирәкле барлык уңай шартлар тудырылуын искәртеп, медицина хезмәткәрләренә рәхмәт сүзләре ирештерде.

IT-тармак белгечләре берләшә

Иннополиста «Цифрлы алгарыш» илкүләм конкурсының финал ярышлары уза. Ике көн дәвамында Россиянең IT-тармак юнәлешендәге иң көчле 1,3 меңләп белгече 12 төрле биремдә үз көчен сынаячак. Ярышның матди фонды да саллы – 24 млн сум.

Әлеге конкурс илнең мәгълүмати технологияләре үсешенә зур өлеш кертә. Россия Президенты Владимир Путин әлеге фикере белән катнашучыларга дип җибәргән сәламләү хатында уртаклашты. «Конкурсның үз традицияләре бар, ул абруйлы. Бүген ул бөтен ил буенча дистә меңнән артык сәләтле кешеләрне – тәҗрибәле IT-белгечләрне, яшь профессионалларны берләштерә», – диелә аның мөрәҗәгатендә.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, әлеге мәртәбәле ярышның республика өчен дә аерым әһәмияткә ия. «Катнашучылар өчен дигән биремнәр уйлап чыгарылмаган. Алар чынбарлыктан алынган, кешеләрнең тормыш сыйфатын арттыру өчен юнәлдерелгән. Татарстан цифрлы тармакта алдынгы урынны били», – диде республика җитәкчесе.

Россия Президенты администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Кириенко да бу конкурсны үткәрү мәйданчыгы итеп Татарстанны сайлаулары юкка түгел дип белдерде. «Татарстан ил буенча идарә итү һәм хуҗалык процессларын цифрлаштыру буенча алдынгы тәбәкләрнең берсе булып тора», – диде ул.

КҮП ТЕЛӘСӘ, АЗ БИРЕЛМӘС

Үзем тапкан мал түгел, дипме, дәүләт биргән акчаны башка ихтыяҗлар өчен тотучылар юк түгел. Кайсы машинасын төзәтә, кемдер акчаны янда калдыру ягын карый, кайсылары законны урап узармын дип ышана. Без капчыкта ятмый инде ул, барыбер кайчан да булса тишеп чыга. Кырын эшләрне хокук саклау органнары да тиз ачыклый.

pixabay.com

Республикада коррупциягә бәйле очраклар 80 процентка арткан. Бу елның 9 аенда алышбиреш эшләрдән күрелгән зыян күләме 450 млн сумга җиткән. Акчаны үз теләге белән кайтаручылар күп булмаса да, бар. 56,6 млн сумны шулай кайтарганнар.

Татарстан Президентының Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе Салават Рәхимов сүзләренчә, 2015 елдан бирле «Халык контроле» хезмәтендә «Коррупциягә каршы тору» бүлеге мөрәҗәгатьләр кабул итә. Килеп ирешкән коррупцион шикаятьләр саны узган елгысыннан әллә ни аерылмый. Былтыр – 39, быел 41 мөрәҗәгать булган. Аларның күп өлеше тирә-юньне төзекләндерү тармагына туры килә. Транспорт һәм юл хуҗалыгы, торак-коммуналь хуҗалык, мәктәпкәчә белем бирү, сәламәтлек саклау өлкәләренә бәйле зарлар да кимеми.

– Мондый мөрәҗәгатьләрне һәрвакыт игътибар белән тикшерәбез. Аны коррупциягә каршы республикакүләм белгечләр төркеме эше кысасында да башкарабыз. Комиссия белән берлектә Татарстанның 44 районында тикшерүләр булды инде, моннан тыш биш министрлык эшчәнлеге тикшерелде, – диде Салават Рәхимов.

Татарстан Президентының Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе Руслан Никонов акчага бәйле кырын эшләрдә тотылган кайбер очракларга аерым тукталды.

Кәгазьдә – кыйбатлысы, ә кырда – арзанлысы. Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгын миллионнар белән бәйле махинациядә тотканнар. Министрлыкның «Сәләт» фонды белән үзара мөнәсәбәтләрендә хокук бозулар ачыкланган. «Фонд тулысынча Татарстан бюджеты исәбеннән субсидияләнә. Ел саен 105–115 млн сумга кадәр акча бүлеп бирелә. Барыгыз да Биләрдәге форум турында беләсез. Аның өчен палаткалар сатып алына. Рәсми кәгазьдә палаткалар бәясе 2 млн 380 мең сумга арттырылуын ачыкладык. Подрядчы «Арсенал» палаткаларын 119 мең сумга сатып алуын күрсәтте. Асылда 85 мең сумлык арзанлы палаткалар сатып алынганын ачыкладык», – дип сөйләде ул.

Урман хуҗалыгы тармагына да бәйле күп кенә кагыйдә бозулар теркәлгән. Әйтик, республиканың бер урманчылыгы үзеннән-үзе урман сатып алу белән шөгыльләнгән. Бөгелмәдәгесендә подрядчы машинасына урманчылык машинасының двигателен күчереп урнаштырганнар. Кайбыч урман хуҗалыгында исә дәүләт учреждениесе хисабына подрядчының кыйммәтле машинасын төзәткәннәр. Шунысы кызык: компания җитәкчесе – урман хуҗалыгы җитәкчесенең улы.

Татарстанда коррупцион юнәлештәге җинаятьләр саны арту турында Татарстан прокуратурасының ришвәтчелеккә каршы тору турындагы законнарның үтәлешен күзәтү бүлеге башлыгы Ринат Латыйпов белдерде. 165 кешегә гаепләү карары чыгарылган. Болар арасында хокук саклау органнарының – 20, дәүләт хакимияте органнарының – 1, җирле үзидарә органнарының – 10, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең – 15, коммерция оешмаларының 17 вазыйфаи заты бар. Узган ел 875 кырын эш ачыкланса, быел аларның саны меңнән артып киткән.

Юристлар көне белән!

3 декабрьдә Россиядә Юристлар көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан Татарстанның юстиция министры Рөстәм Заһидуллин редакциябез аша әлеге бәйрәм белән котлау сүзләрен җиткерә.

– Юрист – профессиональлек, компетентлык һәм белем, гражданлык җаваплылыгы һәм әхлак таләп итә торган күпкырлы һөнәр. Әмма барлык юристларны да бер уртаклык – законлылыкны тәэмин итү, хокукый мохитне яхшырту һәм җәмгыятьнең хокукый культурасын үстерү омтылышы берләштерә, – диелгән министр котлавында. – Татарстанның юридик җәмәгатьчелеге республикабызның социаль-сәяси тормышында актив катнаша, хокукый ярдәм күрсәтүгә, шул исәптән түләүсез хокукый ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән күп кенә проектларны гамәлгә ашыра. Юридик берләшмә вәкилләренең намуслы хезмәте, актив гражданлык позициясе, принципиальлеге һәм максатчанлыгы киләчәктә дә республикада тотрыклылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуның нигезе булыр дип ышанам.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Теләк

Кешене, иң акыллы зат, диләр. Бу чынлап та шулай – кешедә акыл чамасыз. Шуңа күрә ул акыл җыярга теләми. Киресенчә, ул акылын башкаларга бирергә тели. Акылымны башкаларга бирсәм, минем кебек акыллылар күбәер дип уйлый. Тик акыллылар күбәйми. Чөнки башкалар ул акылны алырга теләми. Чөнки акыл аларның үзләрендә дә күп. Һәм алар да үз акылын башкаларга бирергә тырыша. Бөтен халык бер-берсенә акыл бирә. Беркем дә алмый. Кеше – иң акыллы зат. Тик ул акыллы булырга теләми.

Кеше баерга тели. Кешегә байлык кирәк. Ни өчен? Әлбәттә, тәмле итеп ашар өчен. Кеше иң модный ризыклар ашарга тели. Файдалы түгел. Туклыклы түгел. Хәтта тәмле дә түгел. Ә модный. Исеме яңгыравыклы булсын. Байлар ашый торган ризык булсын. Мондый ризыкларны ашау өчен бай булырга кирәк. Шуңа кеше баерга тели. Байый. Ашый. Симерә. Аннан ябыгырга тели. Ә ябыгу өчен ашамаска кирәк. Тик кеше ашамаска теләми. Ул күп итеп, тәмле итеп ашарга һәм ябыгырга тели. Әлбәттә, ашаган саен ябыктыра торган дарулар бар, диләр. Файдасы бармы, юкмы – белмим. Һәрхәлдә, аларны саталар. Әлбәттә, алар кыйбат тора. Шул даруларны алу өчен бай булырга кирәк.

Кеше иң затлы, иң зәһәр эчемлекләр эчәргә тели. Шуларны ат бәясе хакка сатып ала. Моның өчен аңа байлык кирәк. Шуларны эчә-эчә сәламәтлеген югалта да... ат бәясе хакка дарулар сатып ала башлый. Ә сәламәтлек аңа нигә кирәк? Юк, озак яшәр яки нәтиҗәле эшләр өчен генә түгел. Иң мөһиме (!) сәламәтлек аңа тәге затлы һәм зәһәр эчемлекләрне кабат эчә алу өчен кирәк.

Кеше ял итәргә тели. Эшләп арыган өчен түгел. Эшләп арыган өчен ял итү кирәк булса, колхозчы, төзүчеләр җәй буе ял йортларында ятар иде. Югыйсә алардан да ныграк эшләүче юк бит инде. Тик алар ял йортларына йөрми. Тагын игътибар беләнрәк карасаң, ял йортларына ел әйләнәсе бер нәрсә дә эшләмәгән кешеләр йөри. Бу, әлбәттә, шулай булырга тиеш, чөнки эшсезлектән дә кыенрак нәрсә юк. Иң нык арыткан – эшсезлек. Ә асылда кешегә ял болай гына кирәк. Ял итү модада булган өчен. «Быел кайда ял иттең?» – дигән сорауга бирәр затлы гына чит ил исемен атамасаң, син бу дөньяда бер нәрсә дә эшләмәгән, булдыксыз һәм ялкау кеше кебек күренәсең. Шуңа күрә каядыр барып ял итеп кайту ул инде мәҗбүри эш кебек тоела башлый. Һәм күпләр шулай эшли дә: ял йортына баргач, бүлмәсеннән дә чыкмый ята. Чөнки аңа монда кызык түгел, ул инде барысын да күргән, барысын да белә. Аңа бер җирдә дә кызык түгел, чөнки бу планетада ул ял итмәгән бер урын да калмаган. Ләкин монда ел саен килергә кирәк. Бу – престиж.

Кеше ашарга, эчәргә, ябыгырга, ял итәргә, гыйшык-мыйшык уйнарга, канәгатьлек алырга, бай булырга тели. Ләкин берәү дә акыллы булырга теләми. Кеше үз организмы, үз язмышы, якыннары өчен зарарлы нәрсәләрне бик теләп башкара. Ә файдалысын – юк, монысына аны мәҗбүр итәргә кирәк. Кеше үз сәламәтлеген сакларга теләми. Намусын сакларга теләми. Эшләргә теләми, акча бирергә теләми, кайберәүләр хәтта рәхмәт әйтергә дә теләми. Кемгәдер әйтеп бетергесез игелек эшләгәннән соң сиңа рәхмәт әйтсен өчен күп очракта аны каты гына кыйнап алырга кирәк. Кеше, әлбәттә, акыллы зат.

Аннан соң, акыллы булу бик рәхәт хәл дә түгелдер. Чөнки акыл бик холыксыз нәрсә. Ул кешедәге бик күп сыйфатлар белән бергә ярашып яши алмый. Ул фәкать үзенә генә аерым игътибар таләп итә. Акыл – эгоист. Кеше организмына мәхәббәт дигән төшенчә килеп керә икән – акылы чыгып китә. Байлык керсә – акылы чыгып китә. Гел шулай характер күрсәтеп йөри. Хет ичмасам бер чыгып киткәч, кабат борылып та карама инде син. Юк. Байлыгы чыгып китә икән, кешегә кабат акыл керә. Адәм әүлиясенә әйләнә дә куя инде теге бәндә. Һәм үзе кешегә акыл бирә башлый. «Байлыкка кызыкмагыз, байлык – бер айлык, ә ярлылык, кадерен белеп тотсаң – гомерлек!» – ди. Ләкин байлык кабат килеп керсә, акылы тагын чыгып китә. Шул рәвешле адәм акылы үз гомеренең күп өлешен юлда үткәрә.

Кеше, әлбәттә, иң акыллы зат. Ә дөнья белән шул акыллы затның ахмак теләкләре идарә итә.

Әйтеп кенә бактым

Чират

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Вакцинаның икенчесен кадатырга, ягъни ревакцинациягә бер районның үзәк хастаханәсенә бардым, дөресрәге, поликлиникага. Чөнки хастаханә яңа госпитальгә әйләнгән иде. Поликлиника – шуның беренче катында. Бар җирдә чисталык, идәннәрдә – «социаль дистанция» саклау кирәклеген искә төшереп торган кызыл сызыклар...

Минем кебек таң тишегеннән торып чират алучылар артык күп түгел иде, әмма иртәнге сигезләр якынлашканда, сакланганны Ходай саклар, дип уйлаучылар саны ишәя башлады. Алдан язылып түгел, «тере чират»ка басасы иде монда. Кем артыннан кем икәнен һәрберсе белә, әмма терапевт кабинеты янына бер-берсенә терәлеп диярлек басканнар, кайда ул дистанция саклау!

Безнең бөтен гомер чират көтеп уза кебек. Чират торып алмасак, ризыгыбызның тәме, кияр киемебезнең рәте булмас кебек. Чиратлы гомер итү каныбызга шулхәтле сеңгән ки, без инде чиратсыз яши алмыйбыз кебек. Бу, күрәсең, илдәге тотрыксызлык белән бәйледер. «Иртәгә ни буласын кем белгән» кебек сүзләр бүген дә модада. Элек-электән ипидән башлап һәр нәрсәгә чират торып өйрәнгән халык без. Мөхәммәт Мәһдиев тә бер әсәрендә: «...балдыз – трамвайда, баҗай яшел суганга чират торганда, үзләренә кунакка чакырдылар...» – дип язган иде. Шунда да «чират» дигән сүз керткән бит әдибебез, димәк, чират аның да теңкәсенә тигәндер.

Әй, ул кибеткә берәр сирәк тауар кайтса инде! Кибет тирәсе ниндидер бәйрәмне хәтерләтә башлый иде. Дөрес, бу бәйрәмдә шатлыклы авазлар түгел, ә сүгенгән сүзләр күбрәк яңгырый. Мин авыл җирен әйтәм инде. Шәһәргә килсәк, Горбачев «коры закон» игълан иткәч, аракыга чират торулар күпләрнең төшенә кереп саташтыргандыр. «Вино» дип язылган кибетләр магнит кебек үзләренә тартып торса да, керсәң – кереп, чыксаң чыгып булмый иде алардан һәм «Аракыга чират торганда таптап үтергәннәр» дигән куркыныч сүзләр дә шактый ук еш ишетелде.

Менә шундый «якты» хатирәләргә бирелеп, табибка чират торам. Халык саны ишәйгән саен, гөжләгән тавышлар да көчәя. Бу гөжләү җүнлегә түгел бугай. Әнә кемдер тавыш чыгарырга маташа: «Тере кеше артыннан мин чират алган идем», – ди. Икенчесе: «Юк, мин», – ди. Башкалар аларны тынычландырмакчы була, әмма бәхәстә катнашучылар саны арткан саен, шау-шу көчәя генә бара. Менә ишек ачылып китә дә табибәнең башы күренә: «Тавышланмагыз, эшләргә комачаулыйсыз, барыгызны да кабул итәм бит», – ди. Шуннан соң бераз тынычланалар, димәк, буш кайтып китмәячәкләр.

Мин чират алдым да читкәрәк киттем. Халык моны башкача кабул итте, ахрысы, иркенрәк сулап куйдылар, тагын килеп басмаса ярар иде дигән сыман, миңа дошман күзе белән карап, бер-берсенә тагын да терәлебрәк бастылар. Ә ишектән яңа кеше килеп керсә, ул инде, гомумән, дошманга әйләнгән кебек. Аның: «Кто последний?» – дип соравына җавап бирми интектерәләр. Бу – үзләренчә протест белдерү.

Чиратлар кешене дуслаштыра да, дошманлаштыра да. Алар элегрәк бәндә баласының җәмгыятьтәге статусын да билгели иде. Артык ишекләрдән кереп, дефицит тауар, чиратсыз гына фатир-машиналар алучылар җәмгыятьнең каймагы исәпләнде. Бүген бөтен әйбер бар кебек, акчаң гына булсын. Ә менә чират дигән күркәм гадәт һаман да яши. Аны җәмгыять үзе яшәтә. Һәр нәрсә җитеш булса, халыкта кирәкмәгән уйлар туа башларга мөмкин. Ә менә, мәсәлән, чиратсыз гына табибка керү, блат буенча вакцина кадату кебек нәрсәләр безнең өчен зур җиңү санала, кешенең күңеле була.Яшәсен чиратлар! Алар бетсә, яшәүнең кызыгы да калмас кебек.

Якташым, язучы Вакыйф Нуриев белән шушы хакта сөйләшеп торган идек. Мин: «Чиратлар зиратта гына бетәдер инде ул», – дидем. Ялгышканмын икән. Бер әсәрендә чиратлар турында бер-ике кәлимә сүз язган булган Вакыйф. Бер абзый зиратта йөри икән. Кабер казучы егетләр: «Нәрсә, абый, кабер өчен җир эзлисеңме әллә? Нигә алдан чиратка язылмадың?» – дип шаярта башлаганнар. Ә абзый: «Мин чират алуын алам да, тик менә чиратка яшьләр килеп керә шул», – дигән ди. Яшьләрнең күпләп үлүе турында нинди моңсу шаярту. Әмма куанып, шатланып, сокланып, сыкранып, күңелле итеп яшибез бит әле, дип юанам.

КАЙДА СОҢ СИНЕҢ ТАБЫШЫҢ, «РОСНАНО»?

Моннан ике атна элек бу юлларның авторы «Синдә ник эш юк соң, авыл?» дигән язма әзерләгән һәм ни өчен авылда эш урыннары юк һәм аларны ачарга ярамый да икәнен дәлилләгән иде. Болай үзе авылда эш урыннары ачып була ул. Аның бик яхшы үрнәге дә бар бездә.

Октябрьгә кадәр Арча районының Оры авылы ярты Россияне комач (кызыл тукыма) белән тәэмин иткән, башка сәнәгать товарларын да мул җитештергән. Бай яшәгәннәр орылылар. Газета хәбәрчесе әле дә Ташкичүнең Оры бае салдырган ике катлы таш мәчетендә башын сәҗдәгә ора. Әмма бу инде – ике йөз ел элекке тарих. Ике гасыр элек русча да белмәгән татар бае рәхәтләнеп сәүдә иткән, Кытайга кадәр кәрван куган, сәүдә капиталын товар җитештерүгә тыгып, сәнәгать капиталына әверелдергән. Әле ул чакта Россиядә хәзерге кебек фонд биржалары булмаган. Спекулянтлар акчаны финанс куыкларына тыгып кабартмаганнар һәм яндырмаганнар да. Артык акчаң булса, аны эшкә тыгасың: я товар сатып алып сәүдә итәсең, я товарны үзең җитештерәсең. Татар баеның исә эшмәкәрлек куәсе зур булган, ярты дөнья белән курыкмыйча алыш-биреш иткән. «Татарга тылмач кирәкми» дигән сүз шул чакларда әйләнешкә кереп калган. Хәзер дә кирәкми диярлек ул татарга тылмач, безнең туган тел белән әле дә Җир шарының кимендә чирек өлешендә курыкмый йөрергә һәм алыш-биреш итәргә була. Әмма бит сүз башы «Роснано» иде.

Үткән атнада бит шул дәүләт компаниясенең техник дефолты Россиянең фонд биржасында тетрәнү китереп чыгарды, спекулянтлар нәкъ менә Россия компанияләренең акцияләрен күпләп сата башладылар һәм «распродажа» кагъазьләрне очсызландырды. Әле ярый коронавирусның «омикрон» дигән штаммы килеп чыкты да, түнтәрелешне шуңа сылтарга мөмкин булды. Хәзер бөтен дөньяда икътисади түнтәрелешне шул күзгә күренмәгән штаммга ягалар. Әмма мондый аклануны алып ташласак, без Россиянең финанс базарындагы дулкынны «Роснано» китереп чыгарганны күрер идек.

«Роснано»ның бөтен кеше күзе алдында дүрт аяклап мәтәлчек атуы безнең ике атна элек әзерләгән язмабыздагы («Ник синдә эш юк соң, авыл?») дәлилләрне куәтли дә инде. Ясалма рәвештә эш урыннарын авылда гына түгел, шәһәрдә дә булдырырга кирәкми. Зур акча тыгып, эш урыннары булдырсаң, ахырдан еларга туры киләчәк.

Әйдә, хәзер «Роснано»ның серен ачабыз инде. Нәрсә ул «Роснано»? Үткән елга кадәр утта янмый, суда батмый торган Чубайс идарә иткән (ваучерларны хәтерли торгансыздыр инде, Анатолий әфәнденең бар Россия халкын ничек итеп төп башына утыртуын онытмагансыздыр) компания ничек туды һәм ниләр белән шөгыльләнде? Моннан унөч ел элек, югары технологияләрне үстерү максатыннан, инвестицион компания буларак дөньяга килде ул. Инвестиция, димәк, акчаны яңа җитештерү мәйданнарына тыга да табыш ала, ул табыштан салым түли дә тагын инвестицияләр ясый. Инвестицион компания салымнан тыш әле дивидендлар да түли. Анысын акционерлар ала. «Роснано»ның акционеры йөз процентка – дәүләт, ул дәүләт акчасы белән эш итә. Менә бит нинди матур вазгыять! Дәүләт компаниягә акча бирә дә берьюлы дүрт куянның койрыгын тота: 1) югары технологияләр үсә; 2) югары технологик эш урыннары барлыкка килә (сүз уңаеннан, аларны авылда да булдырырга мөмкин); 3) бюджетка салымнар керә; 4) казнага дивидендлар ява. Безнең хөкүмәттәге дәү чиновниклар менә шулай акыллы һәм дөрес фикер йөртәләр.

«Роснано»ның бурычы менә болайрак: ул базардан югары технологияләр белән шөгыльләнергә теләгән яшь компанияләрне табып ала да шуларны акча белән тәэмин итә. Тегеләр шул акчага «нанотехнологик товар»лар җитештерәләр. Россиянең үз «айфон»нары һәм «айпад»лары базарга чыга һәм дөньяны яулый. Башта импортны алыштырабыз инде, билгеле. Теге «куян»нарның икенчесенең койрыгы, чынлап та, тотыла: «Роснано» тырышлыгы белән Россиянең 38 төбәгендә 115 предприятие ачыла, 40 мең яңа эш урыны булдырыла. 109 проектка 500 миллиард сум дәүләт акчасы сарыф ителә. Тик менә башка «куян»нарны әлегә кадәр беркемнең дә күргәне юк. 2011 елда Чубайс берсенең койрыгын ул вакытта Премьер-министр булган Путинга күрсәтеп алды алуын. Сыгылмалы дисплейлы могҗиза-планшет тотып килде аның янына. Барлык мәктәп укучыларының дәрескә шул планшетларны тотып киләчәгенә ышандырды. Тик бу чегән фокусы кебек кенә нәрсә булып чыкты. Америка – Британия стартабы эшләгән ул планшет сатуда булган икән инде. Безнең «нано» предприятиеләргә аны җитештереп мәшәкатьләнергә туры килмәгән шуңа күрә.

2014 елда «Оптоган» дигән заводта яктылык диодлары җитештерә язып калдылар. Ярты базарны «Оптоган» продукциясе колачларга тиеш иде. Уңышлы булырга тиешле ул проект «Роснано» белгечләренең профессиональлеге җитешмәү сәбәпле тормышка ашмады, диделәр. «Лиотех» дип аталган завод (бәясе – 15 миллиард сум) литий-ион аккумуляторлар җитештерә башларга тиеш иде. Газета хәбәрчесенең хәтере ялгышмаса, 2014 ел иде, аккумуляторларның зур өлешен Кытайга сатасылар иде, әмма чиннар «рус могҗизасы»ннан баш тартты. Базар булмагач, «Лиотех» түнде инде. Дөрес, 15 миллиард сумның 4 миллиардын чит илдәге офшорга чыгарып коткарып калганнар.

«Роснано» бер дә акчага тилмермәде. 2014 елдан 2015 елга күчкәндә, без барыбыз да акчасызлыктан суган суы суырганда, Чубайс әфәнде компаниянең Яңа ел корпоративында: «Безнең акча күп. Менә бөтенләй күп инде», – дип мактанды, һәм кайсыдыр явызлар, эчкерсез җитәкченең шул самими сүзләрен видеога яздырып, бөтен илгә шаулатты. Видео әле дә челтәрдә йөри. 2014 елда Оксана Дмитриева дигән беркатлы бер депутат Генераль прокуратурадан компания җитәкчелегенә карата җинаять эше ачуны сорады. Хисап палатасы ул чакта ук ачыклаган иде: 47 миллиард сум акча чит илләргә чыгарылган (ахырдан билгеле булганча, аларга инә дә сатып алмаганнар), 850 миллион сум менеджерларның транспорт чыгымнарына тотылган, сак хезмәте 550 миллион сумны умырган, 300 миллион долларны Люксембургтагы фондка күчергәннәр (фонд әллә Чубайсныкы, әллә компаниянеке – газета хәбәрчесе ачыклый алмады)... Җинаять эше ачмадылар, әлбәттә.

2017 елда ул: «Бер-ике адым гына ясыйсы калды, шуларны атлагач, дәүләткә бар акчасын кайтарып бирәчәкбез», – дип вәгъдә итте. Ягъни тагын өч куянның койрыгын учлап тотачаклар. Гипноз 2020 елга кадәр дәвам итте әле. Чубайсны озаттылар. Урынына яңа кеше билгеләделәр. Компания уңышлы гына эшли башлар кебек тоелды, чөнки әле ноябрь башындарак кына компания керемнең – 6 тапкыр, тулаем табышның 5,6 тапкыр артуы турында хисап бирде. Инвесторлар хәтта: «Чубайс китте – табыш килде», – дип шаярта башладылар, диделәр. Һәм... көтмәгәндә, аяз көндәге яшен кебек, компаниянең дефолты турында хәбәр килеп төште. Федераль Финанс министрлыгы хөкүмәт акчасына дефолтны булдырмый калачагын игълан итте инде. Әмма бу барыбер фонд биржасындагы түнтәрелешне туктатмады. Хөкүмәтнең «Роснано»дан тыш тагын башка дәүләт инвестицион компанияләрен дә 2 триллион сумга финанславы ачыкланды. Башкалары да куяннарны тырышып куган, әмма тота алмаганга охшаган. Хәзер аларны бөлдерсәң, бөтен финанс базары ишеләчәк.

Юк, автор бу язманы берәүне дә гаепләп язмады. Берниндй сәяси максат та куймады. Бик күп байлыклар сарыф ителә Россиядә технологик ыргылыш өчен. Нәтиҗәсе генә «пышш» иткән куык тавышы чыгару белән тәмамлана. Дәүләт акчасын яңа эш урыннары булдыру өчен тотарга ярамавын исбатлау өчен генә басып утырам компьютерым төймәсенә. Сүз уңаеннан, ул бик искерде инде, эленә дә кала. «Роснано» чыгарган арзанлы һәм сыйфатлы ноутбукларны күреп булмады.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ТАБИГАТЬ САТАШТЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кышкы яңгыр файдага?

Балтач районының Яңгул авылында яшәүче халык синоптигы Әмир Шәрәфиев, быелгы кыш артык салкын да, җылы да түгел – нормада булачак, дип фаразлый. «Узган ел да кыш салкын килә, диделәр. Нормаль кыш булды ул. Ике ел рәттән кыш җылы килгәнгә генә безгә бик салкын кебек тоелды ул. Узган кышта озакка сузылган салкыннар булмады. Ә менә быел кышның икенче яртысында озакка сузылган салкыннар булырга мөмкин. Мартның беренче яртысы да салкын булырга охшап тора. Быел җәй коры килде бит. Бу шуның белән бәйле», – ди тәҗрибәле халык синоптигы.

Әмир Шәрәфиев сүзләренә караганда, табигатьтә 100 елдан соң бөтен нәрсә кабатлана. Билгеле булганча, 1921 елда бик нык корылык булган. Быел да шундый ук корылык кабатланды. «Узган ел ноябрь аенда җиргә бер бөртек кар төшмәде. Карсыз суык булды. Уҗымнар да зыян күрде. Быел алай түгел. Кыш бик яхшы килә. Декабрь башындагы яңгырдан да куркырга кирәкми. Бу җылыту файдага гына. Декабрь башында күзәтелә торган агач сарысын чыгару дигән күренеш инде бу. Унбиш градуска кадәр суытканнан соң яңгыр ява да агачлардан сары тамчы тама. Агачларның ботакларына су тула да катып кала. Ул бөҗәкләргә дә, агачның тамырларына да файдалы. Кыш башында яуган яңгырларның уҗымнарга да зыяны юк», – ди Әмир абый.

Игенчеләр исә башка фикердә. Кукмара районының баш агрономы Илдар Габбасов сүзләренә караганда кыш башында яуган яңгырларның уҗымнарга бер файдасы да юк. Күпьеллык печән дә черергә мөмкин», – дип борчыла белгеч. Синоптиклар исә алдагы көннәрдә дә җылы һава торышы вәгъдә итә. КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы мөдире Юрий Переведенцев сүзләренә караганда, декабрьнең беренче ае республикада нормадан 5–6 градуска җылырак булачак, явым-төшем нормадан якынча 20 процентка артыграк булыр дип көтелә.

Чәчне дә үзгәртәчәк

Соңгы елларда глобаль җылыну дигән сүзләрне торган саен ешрак ишетергә туры килә. Табигатьтә барган кискен үзгәрешләрне дә галимнәр әнә шуның белән бәйләп аңлата. Климат үзгәрешләре буенча хөкүмәтара белгечләр төркеменең (IPCC) докладында китерелгән мәгълүматларга караганда, соңгы чирек гасыр эчендә җир йөзендә уртача һава температурасы 1,5 градуска җылынган. Дөнья океанының биеклеге 20 сантиметрга күтәрелгән. Алга таба да болай дәвам итсә, җир йөзендәге күп кенә төбәкләр су астында калырга мөмкин дип чаң суга белгечләр. Бу афәтне үз җилкәсендә татучылар да бар инде. Бу урында Бангладешта, Германиянең көнбатышында булган көчле су басу аркасында йөзләрчә кешенең торыр җирсез калып, башка илләргә күченеп китәргә мәҗбүр булуын искә алу да җитә.

Иң гаҗәпләндергәне шул: глобаль җылыну аркасында җир йөзендәге бар тереклек, шул исәптән кеше организмы да зур үзгәрешләр кичерергә мөмкин икән. Һиндстанның «Sasapost» басмасында дөнья күргән фәнни тикшеренү нәтиҗәләре шул хакта сөйли. Баксаң, һава җылына барган саен кеше организмында меланин дигән пегмент күбрәк эшләнә бушлый. Билгеле булганча, ул кешенең тән, чәч, күз төсе өчен «җаваплы». Димәк, Җир шары глобаль рәвештә җылына барган саен, кешеләрнең тышкы кыяфәтләре дә үзгәрергә мөмкин.

Тикшеренү уздыруда катнашкан галимнәрнең берсе, биолог Сара Райдинг сүзләренә караганда, климаттагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә кешенең орган һәм тән өлешләре дә үзгәреш кичерәчәк. «Глобаль җылыну аркасында акрынлап кешеләрнең тән өлешләре белән баш мие кечерәячәк. Соңгысы аеруча куркыныч. Баш мие кечерәю аркасында кешенең хәтере начарланырга, сөйләмдә тоткарлыклар барлыкка килеп, уку, акыл хезмәте авырдан бирелә башларга мөмкин», – дип фаразлый белгеч.

Ноябрь рекорд куйды

Табигатьтән киләчәктә тагын нәрсә көтәргә? КФУның метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев Һиндстан галимнәренең фикере белән килешеп бетми. «Хәзерге вакытта без, дөрестән дә, глобаль җылыну чорында яшибез. Күптән башланган үзгәрешләр бу. Әмма 1979 елдан башлап җир йөзендәге глобаль җылыну белән бәйле үзгәрешләр аеруча зур тизлектә бара. Моңа табигать тә җавап бирмичә калмый. Анда да киеренкелек арта. Су басулар, корылык, явым-төшемнең кирәк чакта яумыйча, кирәкмәгән чакта төшүе – бар да шуның галәмәте», – ди белгеч.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ДЕКАБРЬ АЕНА ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ
- Декабрьнең егерме бишендә агачларны бәс сарса, алдагы җәй иген уңар.
- Декабрьнең утыз берендә төнлә йолдызлар еш күренсә, ашлык уңар; шулай ук бәс булса да, ашлык уңар.
- Декабрьдә кар аз булса, җәй коры килә.
- Декабрьдә кара каргалар күренә икән, кыш җылы була.
- Карсыз декабрь – коры яз билгесе.
- Декабрь башында көчле бураннар, кар яуса, июнь башында яңгырлар була.
- Декабрь җилле икән, март җылы була.

Доцент сүзләренә караганда, Җир шарының җылына баруының иң төп күрсәткече – җылы кышлар. Быелгы декабрьне дә белгечләр гадәттәгедән салкынрак булыр дип фаразлаган булган. Чынлыкта ни булганын үзебез күреп торабыз. «Илнең Гидрометеорология үзәгенең яңартылган фаразларына караганда, декабрьнең беренче декадасында һава температурасы нормадан югарырак булыр дип фаразлана. Норма дигәндә 6–7 градус салкынлыктагы уртача тәүлеклек температурасы күздә тотыла. Декабрьдә явым-төшем дә күп булачак», – ди Тимур Әүхәдиев.

Быелгы ноябрь аеруча рекорд куйды. Шушы бер ай эчендә республикада 95 мм явым-төшем яуган. Соңгы тапкыр ноябрь аенда мондый рекорд 2002 елда куелган булган. Ул чакта җир өстенә 107 мм явым-төшем төшкән. Соңгы 200 ел эчендә Казанда уртача һава температурасы 4,5 градуска күтәрелгән. «Бу – бик зур күрсәткеч. Безнең илдә глобаль җылыну бөтен Җир шарында барган үзгәрешләр белән чагыштырганда 2,5 тапкыр тизрәк бара. Моның уңай яклары да бар. Әйтик, глобаль җылыну аркасында моңарчы чикле вакытка гына ачык булган Төньяк диңгез юлы ачыла. Бу икътисади яктан бик отышлы. Кыш соң килү, иртәрәк тәмамлану аркасында ягу сезоны да кыскара. Халык өчен монысы да отышлы», – ди Тимур Әүхәдиев.

Белгечләрнең глобаль җылыну аркасында киләчәктә бик күп төбәкләр су астында калырга мөмкин дигән фаразы белән килешми ул. Һәрхәлдә, безгә андый куркыныч янамый дип ышандыра. «Бу куркыныч, нигездә, утрауда урнашкан дәүләтләргә яный. Дөрес, безнең Сочи, Санкт-Петербург шәһәрләре дә суга бәйле. Әмма бу шәһәрләргә төзелгәндә үк су басу куркынычын кисәтүче барлык шартларны истә тотып нигез салынган. Киләчәктә табигатьнең ничек «кылануы» күбрәк үзебездән тора. Әлегә бөтен дөнья күләмендә 2100 елга кадәр температура үзгәрешен 2 градустан да арттырмау бурычы куелган. Моның өчен кешелек альтернатив энергия чыганакларына күчәргә тиеш», – ди ул.

Күчмәсе дә кышларга кала

Шул ук Һиндстан басмасында урын алган үзенчәлекле тикшеренү нәтиҗәләреннән аңлашылганча, глобаль җылынуга кош-кортлар җайлаша башлаган инде. Баксаң, 1871 елдан бирле Австралия попугайларының томшыклары 10 процентка зурайган икән. Галимнәр шушы ук җылыну аркасында тычканнарның очлыклары да зурайган дип ышандыра.

Орнитолог, биология фәннәре докторы Илгизәр Рәхимов исә моның сәбәбен бөтенләй башкада күрә. «Попугайларның томшыклары зураю җылылыкка бәйле түгел. Үзебездәге кара карга, чәүкә, күгәрченнең томшыкларына гына игътибар итеп карагыз. Хәзер аларның да томшыклары үзләренә хас булмаганча үсеп, бөгелеп тора. Ник дигәндә, бүген алар, нигездә, чүплекләрдә туклана. Аннан организмнарына төрле матдәләр эләгә. Шуның аркасында томшыклар да үзгәреш кичерә», – ди ул.

Ә җылы якка китә торган күп кенә кошларның соңгы елларда кышны үзебездә уздыруын шушы климатик үзгәрешләр нәтиҗәсе дип саный белгеч. Әйтик, кыр үрдәкләре дә күлләрдә боз катканчы җылы якка китми. Кышын кара карга очрату да гадәти күренешкә әверелеп бара. Узган ел кыш көне Түбән Камада сыерчык күрүчеләр дә булды. «Быел көз җылы булгач, күчмә кошлар бездә ноябрьгә кадәр кунак булды. Шул ук вакытта бездә кышлый торган карабүрек, чечетка дигән кошлар да килеп җитте. Тегеләре дә килеп җитте, болары да китеп бармады. Быелгы ноябрь безнең өчен әнә шундый кызык вакыйга белән истә калды», – ди Илгизәр Рәхимов.

Күпләр кошларның үз-үзен тотышына карап һава торышындагы үзгәрешләрне фаразларга ярата. Илгизәр әфәнде исә, кошларга караганда, үсемлекләр белән бәйле сынамышлар расрак килә дигән фикердә. «Миләш күп булган елны кыш салкын килә, диләр. Быелгы миләшнең күплеген үзегез күреп торасыз. Кыш, дөрестән дә, салкын килерме-юкмы – карарбыз», – ди орнитолог.

Һава торышы кискен үзгәреп торган көннәрдә әйләнә-тирәдәге үзгәрешләргә сизгер кешеләргә аеруча кыенга туры килә. Казан дәүләт медицина академиясенең госпиталь һәм хастаханә терапиясе кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты Регина Ахунова сүзләренә караганда, мондый көннәрдә хроник чирләре булган, аеруча йөрәк-кан тамыры авыруларыннан интеккән кешеләрдән сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булу сорала. Аларга активлыкны киметергә, ерак юлга чыгудан, очрашу-күрешүләрдән тыелып торырга кирәк. Һава торышындагы үзгәрешләр вакытында кешенең кан басымы уйнарга, буыннары, биле сызларга, кәефе төшәргә дә мөмкин.

Регина АХУНОВА һава торышындагы кискен үзгәрешләрне җиңел генә үткәрү өчен түбәндәге киңәшләргә дә колак салырга чакыра:

✓ Һава торышы үзгәрешләренә сизгер кешегә, иң беренче чиратта, йокы режимын бозарга ярамый. Йокы вакыты 6–8 сәгатьтән дә кимрәк булмасын!

✓ Бу чорда начар гадәтләрдән баш тарту, кәһвә, алкогольле эчемлекләр куллану, баллы ризык ашаудан тыелып тору хәерле.

✓ Тәүлегенә ким дигәндә ике литр су эчүне дә гадәткә кертегез.

✓ Туклану да игътибардан читтә калмасын. Һава торышы үзгәргән чорда авырдан эшкәртелә торган, майлы ризыклардан баш тартыгыз.

✓ Бу чорда йога белән шөгыльләнү, йөзү, саф һавада җәяү йөрү, бакчада эшләү дә файдага гына булачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САТУЧЫНЫ КӨТӘСЕ ЮК

ЗАМАНЧА КИБЕТЛӘРНЕҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ ТУРЫНДА

Узган ел Балык Бистәсе районында «Сатучысыз кибет» проекты тормышка ашырыла башлады. Заманча кибетләр 7 авылда эшли. Әлеге яңалыкны авыл халкы ничек кабул иткән? Кибеткә йөрү мәшәкать тудырмыймы? «ВТ» хәбәрчесе, Балык Бистәсе районына барып, «акыллы кибет»ләр тәҗрибәсе белән танышып кайтты.

Халык сорагач...

Балык Бистәсе районында бүген 13 авылда кибет юк. 19 авылга кирәк-яракны автокибетләр илтә. Шул ук вакытта райпо системасындагы кибетләргә гариза биреп, он, шикәр комы һәм башкасын китерү дигән нәрсә дә бар. Сатучысыз кибетләр буенча да сынау бара. Кибет проблемасын нигездә шундый ысуллар белән хәл итәргә тырышалар.

Цифрлы кибетләр турында Балык Бистәсе районы башлыгы Илдар Таҗетдинович фикерен белештек.

– Бу – сынау проекты. Тик торганда гына мондый кибетләр системасы булдырылмады. Район башлыгы булып билгеләнгәч, авылларга халык җыеннарына йөрдек. Чыршылы Елга (халык аны күбрәк рус телендә Шестая Речка дип йөртә. – **Авт.**) авылына баргач, халык, кибет кирәк, дигән гозерен җиткерде. Авылда модульле кибет бар, әмма ябык. Ни өчен дигәндә, кибетче юк. Ни өчен кибетче юк? Хезмәт хакы аз, кеше аз йөргәч, табыш юк. Чыршылы Елга халкы, безгә ипи, сөт кирәк, диде. Кечкенә авылларда мондый проблема бар. Автокибетләр йөри, ләкин алар көн саен килми. Районыбыз егете «Цифрлы авыл» проекты авторы Булат Җамалиев белән очрашып, әлеге проблема турында сөйләштек. Шулай итеп, районда сынау рәвешендә яңа проект булдырылды. Чыршылы Елгадагы беренче кибетне ачарга Президент та килгән иде, – ди Илдар Таҗетдинов. – Кибеткә йөрү өчен һәр кешенең махсус карточкасы бар. Шуның ярдәмендә кибеткә керә һәм чыга ала. Анда сөте дә, туңдырмасы да, башкасы да бар. Әйтик, ипи сатып аласың икән, мониторда бәясе языла. Исерткеч эчемлекләр сатылмый. Урлау очрагының да булганы юк. Өлкән кешеләргә башта электрон системага ияләшү кыен булса да, әкренләп өйрәнделәр. Кибеткә җаваплы бер кешене билгеләдек. Ул кирәк чакта ярдәм итә, тәртипне дә карап тора. Хәзер мондый кибетләр саны җидегә җитте. Кибет биналары иске. Бу проблема бар. Проект авторлары табыш артыннан кумый. Алар өчен технология мөһим. 6–7 авылда булганда файдалырак, әлбәттә. Бер машина килеп, товарны төрле кибетләргә тарата.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Киштәләр буш түгел

Чыршылы Елга авылына барганда урамда эт тә йөрми торган көн иде. Көн буе тоташ карлы яңгыр яуды. Авыл урамнарында резин итек белән дә йөри торган түгел. Әллә һава торышы начар, әллә башка сәбәбе булганга, кибеткә таба сукмак күренми. Авыл үзе наратлар кочагына сыенган, табигате искиткеч. Биек наратларга карап сокланасың да, урамдагы кулләвекне ерып, алга таба атлавыңны дәвам итсең. 40тан артык йорт исәпләнә, 100ләп кеше яши икән бу авылда.

– Кибет узган ел март аенда ачылды. Башта барыбызга да гаҗәп тоелды. Ничек инде кибетчесез кибеткә барып була?! Аннан аптырамый башладык. Теләгән кешегә, кибеткә йөрү өчен, махсус карта бирделәр. Тоз, шырпы, кер юу порошогы һәм башкасын сатып алырга була. Беренче кирәк-яраклар бар. Бер кергәндә, киштәдә Яңа ел бүләкләренә кадәр тора иде. Мин көн саен барып эшләгәч, товарларны зур кибетләрдән сатып алып кайтам, – ди Лена Осина.

Авыл кешеләренең фикере бер төрле генә түгел. Әнә Раиф Сафин, кибеткә ияләшеп булмый, балалар йөридер, мин бармыйм, ди. Күршесенең еш йөрүен әйтә. Аңа кибетче булсын! Машиналарны туктатып, үткән-сүткәннәрдән дә сораштык. Кайберләре, сайлау мөмкинлеге юк, дисә, интернеты эшләми, диючеләр дә булды. Кибеткә Ринат еш йөри дигәч, аны да эзләп таптык. Аңа ияреп кибеткә барган идек, тик керә алмадык. Әллә интернет өзелгән, әллә башка проблема. Тәрәзәдән генә күзәттек. Ярмасы, шикәре, тозы... Киштәләр буш түгел.

– Башта бик шатланган идем. Заманча технологияләрне чамалый торган кеше бит мин. Сатучысыз кибет – бик яхшы идея, әмма система ахырга кадәр эшләнеп бетмәгән. Әле ишеге ябылып кала, әле интернет эшләми... Туйдыра башлый да, шуннан кул селтисең. Берсендә бикләнеп тә калган идек. Әле ярый төймәсен таптык. Әбиләр шундый хәлгә калса, нишләр? Бармасак, товар озак ятып искерәчәк, – ди Ринат Фәйзуллин.

Төнлә – туңдырмага!

Күгәрчен, Ямаш, Кызыл Йолдыз авылларында яшәүчеләр белән дә элемтәгә кердек.

– Сатучысыз кибет 3–4 ай гына эшләп алды. Хәзер сатучы бар. Кибетче булмаганда, олы кешеләргә электрон карта белән әйбер сатып алу авыррак иде. Башта бер кыз авылдашларга өйрәтеп торды. Авылда мондый кибет кирәк түгел. Өлкәннәр пенсия килгәнче дип әҗәткә алып тора алмый. Авыл кибетләре шуның белән яши. Авылда яшьләр юк диярлек. Бюджетта эшләүчеләр кирәк әйберләрен районнан алып кайта. Аннан бу кечкенә кибеттә ярма белән консервтан башка әйбер юк та бит. Кибетчесез эшләгән кибетләр шук үсмерләрне дә кызыктыра дип уйлыйм, – ди Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылында яшәүче Чулпан Мингарипова.

Кызыл Йолдыз авылында 40лап кеше яши. 31 йорт бар, күбесе буш икән. Лариса Кибякова авыл халкын берничә ай буе заманча кибетнең тәртипләренә өйрәтеп торган. Товарларга заказ биргән. Лариса безгә сатып алу нечкәлекләре турында сөйләде.

– Хәзер кибеткә кергән кеше юк. Берничә ай эшләми инде ул. Башта уты янып тора иде, хәзер анысы да янмый. Карта куя торган «йозагы» ватык. Товарлары искереп бетәдер инде. Башта халык бик йөрде. Бик уңайлы, җиләк-җимештән кала бөтен әйбер дә бар. Күрше әбигә сораган әйберсен үзем алып кайтып бирә идем, – ди Лариса Кибякова. – Һәр товарга бәя язып куелган. Алган әйбереңне камера янына куясың да «сатып алынган» дигән язу чыга. Шунда ук акчаңны түләп китмисең. Акчаң булмаса, ул сиңа 500 сумга кадәр әҗәткә дә бирә әле. Тик икенче юлы кергәндә, әҗәтеңне түләргә кирәк. Көйсезлекләрне бетереп, кибет тизрәк эшләп китсен иде инде. Анда төнлә дә барып була. Минем, мәсәлән, туңдырмага барганым бар. Кунакка чакырганда, тиз генә кәнфит алырга мөмкин. Җайлы бит!

Кимчелекләр бетереләчәк

Авылларда халыкның сатучысыз кибеткә бәйле моң-зарларын район башкарма комитетының инвестицияләр җәлеп итү бүлеге җитәкчесе Дилүс Гатиятовка җиткердек.

– Бу социаль проект кебек. Авылда кибетче табу кыен, булган кибетләрне дә ябып бетерделәр. Халык башта яңалыкны авыррак кабул итте, тик хәзер заманча кибетләргә ияләшеп киләләр. Әбиләр бик йөрмәсә дә, яшьләр кызыксына. Дөрес, бөтен җирдә дә кибет дип бик исләре китеп тормый. Кайберләре үзләре ияләнгән сәүдә үзәкләренә йөри. Шомбыт һәм Бикчурай авылларындагы сатучысыз кибетләр эшләми. Бу ике кибетнең биналары иске, хуҗалары ташлаган булган. Берсе дә яңадан төзелмәде. Халыктан кибет кирәк дигән яңа мөрәҗәгатьләр дә кабул иттек. Шуңа күрә эшләмәгәннәрен ихтыяҗ булган авылларга күчерергә ниятлибез. Авыл җирендә мондый кибетләр кирәк, әмма район җирендә халык күбрәк «Магнит», «Пятерочка» кебек кибетләргә барачак. Авылда халык саны 100 кешедән ким икән, проектны булдыручыларга анда кибет тоту файдалы түгел. Дөрестән дә, кайвакыт техник көйсезлекләр килеп чыга. Бүген проект авторлары нәкъ менә шушы проблемаларны хәл итү буенча эш алып бара. Алар җитешсезлекләрне ел ахырына кадәр бетерергә уйлыйлар, – диде Дилүс Гатиятов.

Сәрия МИФТАХОВА

САТУЧЫСЫЗ КИБЕТЛӘР КИРӘКМЕ?

Илгиз ХАТЫЙПОВ,
Татарстан кулланучылар оешмасының (Татпотребсоюз) сәүдә идарәсе башлыгы:

Бу проект республикада бары Балык Бистәсе районында гына тормышка ашырыла. Бүген үк булмаса да, киләсе биш-ун елда авылның киләчәге шундый кибетләргә бәйле булачак. Сатучысыз кибетләр үсәр дип уйлыйм. Бүген авылда кибетче табу җиңел түгел. Аларга кытлык бар. Көне буе эшлисе077 килми. Җаваплылык та бар, акча белән эшләргә кирәк. Кайберләре компьютер белән эшләүдән курка. 20 ел элек, пластмасс чәйнектән чәй эчәбез, дисәләр, мин ышанмас идем. Хәзер яңа технологияләр барлыкка килә, караш та үзгәрә. Бәлкем, халык сатучысыз кибетләргә әлегә әзер түгелдер. Килачәктә фикер үзгәрер. Кечкенә авыллар өчен мондый төр кибетләр идеаль булачак. Мондый кибетләр атнаның җиде көнендә тәүлек буе эшләве белән дә уңайлы.

ЯШӘР ӨЧЕН ҖИҢҮ

«Дөньяда шулкадәр күп матурлык, язар өчен җим бар, сезгә әле дә шушы коронавирус тирәсендә бөтерелергә туры килә...» Республика клиник хастаханәсенең «кызыл зона»сына озатучы шәфкать туташы борчулы күзләре белән миңа төбәлә. Чирнең кешелеккә нык итеп ябышканын аңлый, сәламәтлеккә генә түгел, яшәү рәвешенә, тормыш-көнкүрешкә тәэсир итүен белә инде ул. Аның сүзләре белән дә килешми хәл юк, тик... Мин исә ни өчен язуыбызны аңлатырга тырышам: авыруның барлыгына ышанмаучылар, вазгыятькә битараф кешеләр шактый бит. Ышандыру өчен күрсәтергә, сөйләргә кирәк. Хәер, шәфкать иярләре үзләре дә икеләнеп торган кешеләрне «кунак»ка дәшәргә әзер. Чирләүче буларак түгел, билгеле.

Сан

«ВТ» хәбәрчесе хастаханәдә булган көнне госпитальдә **295** кеше дәвалана иде. Тәүлегенә **20**ләп кешене дәвалап, өйләренә кайтарып җибәрәләр.

Чир яшькә карамый

Бу юлы «кызыл зона»га Республика клиник хастаханәсенең вакытлыча ачылган йогышлы авырулар госпитале җитәкчесе урынбасары Сәяр Сиражетдинов белән кердек. Махсус кием кигәндә үк, вакцина ясатуым, чирләвем турында кызыксындылар. Хәтерләсәгез, «кызыл зона»га тәүге тапкыр кергәндә вакцина ясатмаган идем әле. Моның өчен шелтә дә ишеттем. Хәзер исә аңлы булуым өчен мактадылар. Йогышлы авырулар ята торган госпитальдә үлем белән тартышып ятучыларның күпчелеге исә – прививкасыз.

Коронавирус таралу алган, госпиталь ачылган көннән башлап биредә эшли инде Сәяр Сиражетдинов. Ике ел ял иткәне юк. Ике еллык киеренке, көнне төнгә ялгаган хезмәт...

– Нәкъ шушы коронавирус башланыр алдыннан ялга китәсе кеше идем мин. Калдым. Минем эшне кем эшләр? «Сменам бетте, сау булыгыз», – дип китеп булмый ич, – дип сөйли табиб. – Җиңел түгел инде. Әмма эшли-эшли иялəшәсең. Эшебез шул бит.

Сәяр Сиражетдинов «кызыл зона»да үткәргән ике сәгать эчендә бу сүзләрне бер генә кабатламаячак әле. Сырхауларның рәхмәтле карашларына да, безнең аптырау катыш борчулы сорауларыбызга да җавабы ул аның.

...Госпитальнең реанимация бүлеге мөдире Илдар Мөслимов сүзләренчә, ревакцинация вакыты җиткән кешеләр дә чирли башлаган. Шуңа да кабат вакцина ясатуны озакка сузмаска киңәш итә белгеч. Реанимациядәге вазгыятькә килгәндә, сырхаулар арасында авыр хәлдәгеләр күп. «Коронавирус яшәрде, дибез. Әлбәттә, өлкәннәребез дә авырый. Яшьләр реанимациягә кадәр үк килеп җитми иде. Хәзер аларны да үлем тырнагыннан йолкып алырга туры килә. Яшьләр дигәндә, 1970 нче еллардан соңгыларны күздә тотабыз инде. Әле беркөнне 1993 елгы бер кызны дәваладык», – дип сөйләде ул.

– Дөрестән дә, элегрәк чир өлкәнрәкләрне – 60 яшьтән узганнарны аяктан ега иде. Хәзер яшь кешеләр дә күп, – дип җөпли аның сүзләрен Сәяр Сиражетдинов.

– Бер атналык чикләү булды бит. Бу вакыт аралыгында нидер үзгәрдеме?

– Сүз дә юк, булышты ул. Эшне азга гына булса да киметте. Реанимация шыплап тулган иде бит инде, – ди Илдар Әнвәрович.

...Тәҗрибәле табиб-инфекционист Ләлә Галиева, коронавирус йоктырган кеше хисләргә бирелсә, аны дәвалау җиңел түгел дигән фикердә.

– Безгә эләккән кешеләр бик борчулы, хәсрәтле була бит. Эмоцияләрне йөгәнли алмау яхшыга илтми. Вирус бик катлаулы. Ул – кеше организмы өчен сынау. Кеше үзен ничек тота, бу бик мөһим. Төрле кеше төрлечә авырый, – дип аңлата ул. – Сырхауларның төрлесе бар. Үзләрен дорфа тотучыларны да аңларга була, чөнки һәркайсыбызның күңелендә кечкенә бала яши. Ул һәрвакыт канәгать булмый. Андыйларга тыныч кына барысын да аңлатабыз. Гадәттә, шундый дорфа сырхауларыбыз канәгать, рәхмәтле булып өйләренә кайтып китә.



«Татар-информ» / Михаил Захаров

Хастаханәгә эләкмәс өчен нишләргә соң? Ләлә Илдусовна бу җәһәттән менә нинди киңәшләрен бирде:

> Иң элек, тормыштан канәгать булырга, төшенкелеккә бирелмәскә. Спорт белән шөгыльләнү, дөрес туклану мөһим. Суны күп итеп эчәргә кирәк. Һәр көннең, һәр очракның уңай ягын табыйк.

Берлинны алган кебек

Нурия апаны «палатаның кәефен күтәрүче» дип таныштырдылар. 88 яшен тутырган. Олы яшьтәге апа чирне шат күңелле булуы аркасында җиңгәндер дә.

– Алга китеш бар, дип әйтергә кердегезме, бәбкәем? – дип сорады ул, табиблар белән мине күргәч. Шәфкать иярләре сөендерде үзен.

– Нурия апа терелүгә таба бара. Үпкәләрен тикшердек, чире юк инде. Нурия апа шат күңелле, позитив, аннан гел яхшы кәеф бөркелә. Кешенең эчке халәте дә бик мөһим, – диде Ләлә Илдусовна.

– Нурия апаның нинди сканвордлар чишкәнен күрегез сез! – дип сүз кыстырып куя янәшәсендә яткан күршесе. Чынлап та, кешегә тизрәк терелергә Ләлә Илдусовна әйткән күңел көрлеге дә, аңзиһен сафлыгы да булыша ул.

Ноябрь уртасында хастаханәгә эләгә Нурия апа. Моңа кадәр берничә көн өйдә дәваланган. Чирне ничек эләктергәнен тәгаен генә әйтә алмый. Кирәксәкирәкмәсә урамга да чыгып йөрмәгән.

– Якты дөньяның рәхәтен күреп, риза булып, «Аллаһка шөкер» дип яшәргә кирәк бит. Бәбкәем, болай авырган юк иде. Терелəм икән әле, Аллаһы Тәгалә биргән гомерне яшәргә кирәк, – ди әбекәй. – Табибларга рәхмәт. Исәнлек-саулык телим аларга. Сугыш елларында абыйлар: «Вперед идем, Берлин берем», – дип хат язалар иде. Без дә шулай ук хәзер. Чирне җиңәбез.

«Яшәргә кирәк икән ул!»

Ринат абыйга – 63 яшь. Таныш терапевты еш кына аңа: «Вакцина ясатыгыз. Чир йоктырсагыз, җиңелрәк кичерерсез», – дип әйткәләп торган. Кызганыч, Ринат абый бу сүзләргә вакытында колак салмый, прививка кадатырга өлгерми. Аннан хастаханәгә эләгә. Коронавирустан тернәкләнүне кискенләштерә торган өстәмә авырулары – шикәр чире дә бар икән әле аның.

– Чирне ничек эләктергәнбездер инде, белмим, кем әйтмешли, шулай килеп чыкты. 5 ноябрьдә хастаханәгә кереп яттым. 25 көн дәваланам инде, – ди дә Ринат абый туктап кала. Күренеп тора: аңа авыруны ничек кичерүе турында сөйләргә кыен. – Төнлә сәгатькә карыйсың да: «Кайчан 1 тулыр икән, аннан соң кайчан көн туар икән?» – дип кенә уйлыйсың. Кислородта да яттым. Шунысын аңладым: безнең халык ярдәмчел икән ул. Кислород битлегеннән йөргәндә, бәдрәфкә бару да кыен иде. Палатадагы егетләр булышып торды. Кулдан тотып алып баралар иде. Аларга рәхмәт кенә! Кемнең кемлеге авыр чакта беленә. Вакцина ясатырга кирәктер дигән фикергә килдем. Юкка гына тәкъдим итмиләр бит инде аны. Барыбер файдасы тия. Бу кадәр авыр булмас иде.

Ринат абый тормышка хәзер бөтенләй бүтәнчә карый башлаган.

– Яшәү кадере турында да, кешеләр турында да уйлыйсың икән... Яшисе килә, яшәргә кирәк икән! – ди әңгәмәдәшебез, телефонына төртеп. – Менә шушыңа оныгыбызның фотосурәтләрен җибәреп торалар. Үстерәсе килә, аларны күрәсе килә. Алар өчен яшәргә дә яшәргә, тырышырга кирәк әле, дим!

Ринат абый медицина хезмәткәрләренә бик рәхмәтле.

> Без аларны күзләреннән генә таныйбыз инде. Күренеп тора: арыйлар, авыр аларга. Әмма бирешмиләр. Афәрин аларга! Исәнләшеп, хәл белешеп торалар. Ягымлы итеп сөйләшәләр. Алардан начар мөнәсәбәт күргән юк. Мин аларны кешедән дә катырак кеше дип саныйм.

Янәшәдә басып торган Сәяр Дамировичка, укол кадап йөрүчеләргә ымлап:

– Менә шушыларга рәхмәт! Үз эшләрен яратып башкаралар. 25 көн эчендә беренче генә күрмим инде бу егет-кызларны. Сәламәтлек ташламасын аларны. Әле берсе: «Абый, отпускыга китәм, тернәкләнегез», – дип саубуллашып киткән иде. Кайтты да, мине күрде дә: «Сез әле дә ятасызмыни?» – дип шаккатты. «Сезне көттем!» – дип шаярттым. Бу чирне һичшиксез җиңәргә кирәк. Мондый табиблар булганда, бигрәк тә, – ди.

Нәтиҗәсе – күз алдында

Сәяр Сиражетдинов сүзләренчә, вакцина ясату башланганчы, чикләү чаралары кертелгәнче, коронавирус түгелме дигән шик белән көненә 200ләп мөрәҗәгать итүче булган. Шуларның яртысын хастаханәдә алып калганнар. Хәзер хәлләр башкача.

– Чикләүләрнең нәтиҗәсе юк түгел. Хәзер 70ләп мөрәҗәгать булырга мөмкин. Шуларның берничә дистәсе хастаханәдә кала. Әнә шул саннарга карап, уңай үзгәреш барлыгын чамалыйбыз, – диде табиб. – Беренче чорда медицина хезмәткәрләре өйләренә дә кайта алмый иде бит. Хәзер инде эштән соң өенә дә кайта, балаларын да күрә. Вакцина ясатуның да файдасы бар. Ул саклагыч кебек. Мин үзем дә былтыр чирләп алдым, март аенда «Спутник V» ясаттым, октябрьдә ревакцинация уздым. Шөкер, мин тыныч, саклану чарасын күрдем.

Чикләү чараларының медицина тармагы өчен әһәмияте зур булуына тагын бер дәлил китерде Сәяр Сиражетдинов. Ул мине сырхауларны кабул итә торган урынга алып барды. Коридор тулы кеше, шау-шу булыр дип көтсәм дә, кересе кузәтелде.

– Күмәк вакцина ясату башланганчы, монналан кеше өзелми, чират, басып торырга урын юк, конвейер сыман иде, – диде ул. Аның сүзләрен теркәү бүлегендә утырган апалар да раслады. – Чикләүләр кертелә барган саен, кеше саны да кимеде. Әлбәттә, бу безнең эш бетте дигән сүз түгел. Әмма ыгы-зыгы юк, тынычлап эшләп була.

P.S. «Кызыл зона»дан чыккач, бернинди киртәләрсез, махсус җайланмаларсыз гына мөстәкыйль сулыш алуның никадәр рәхәт булуын аңлыйсың. Ә сулыш алып кем туйган? Дөньяның матур төсләре, тәмле исләре бетмәгән бит әле. Озатканда да Сәяр Дамирович: «Сәламәт булыгыз берүк», – дип теләп калды. Сау-сәламәт булу. Һәркем өчен дә кадерле, кирәкле төп теләк шул хәзер.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

6 декабрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 22.40 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 00.00 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.30 «Трибуна Нового Века» 12+
19.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Барыс» (Нур-Султан). Прямая трансляция 6+
22.00 «Реальная экономика» 12+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.50 «Соотечественники» 12+
01.15 «Черное озеро» 16+
01.45 «Память сердца» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 22.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Башваткыч» 6+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 22.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.50 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
19.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Барыс» (Нур-Солтан) 6+
23.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.05, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ВЕРТИНСКИЙ» (S) 16+
22.40 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.20 «КЛЮЧ ОТ ВСЕХ ДВЕРЕЙ» 12+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «В ЗОНЕ РИСКА» 16+
04.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Джервонта Дэвис против Исаака Круса. Сергей Деревянченко против Карлоса Адамеса. Прямая трансляция из США
07.30, 09.00, 12.35, 15.40, 18.25 Новости
07.35, 21.50 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.25 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
10.25 Зимние виды спорта. Обзор 0+
11.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 Профессиональный бокс. Трансляция из США 16+
14.00, 15.45 «ОПАСНЫЙ БАНГКОК» 16+
16.05 «СЧАСТЛИВОЕ ЧИСЛО СЛЕВИНА» 16+
18.30 «Громко». Прямой эфир
19.25 Хоккей. КХЛ. «Динамо» (Москва) – ЦСКА. Прямая трансляция
22.40 «Есть тема!» 12+
23.05 Тотальный футбол 12+
23.40 «В ЛУЧАХ СЛАВЫ» 12+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Енисей» (Красноярский край) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Керлинг. Олимпийский квалификационный турнир. Смешанные пары. Россия – Дания. Трансляция из Нидерландов 0+
04.30 Санный спорт. Кубок мира. Трансляция из Сочи 0+
05.10 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» (S) 16+
23.35 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
01.20 Их нравы 0+
01.45 «ЮРИСТЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «Реальная мистика» 16+
07.50 Субтитры. «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.30 «Порча» 16+
16.40 «Знахарка» 16+
17.55 «Понять. Простить» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ. СЧАСТЬЕ ВЗАЙМЫ» 16+
01.00 «Реальная мистика» 16+
02.00 «Тест на отцовство» 16+
03.40 «Давай разведёмся!» 16+
04.30 Субтитры. «По делам несовершеннолетних» 16+
05.20 «Из России с любовью» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ДИВЕРСАНТЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.20, 01.30 «ШУМНЫЙ ДЕНЬ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 14.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Наука и война» 16+
19.40 «Скрытые угрозы». «Альманах №82» 16+
20.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Жорж Пак – «Крестный отец» Берлинской стены и самый высокопоставленный агент КГБ в НАТО» 12+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «ВОЕННО-ПОЛЕВОЙ РОМАН» 16+

7 декабрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 23.30 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
17.00, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». Габделфәт Сафин 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.30 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00, 01.15 «Черное озеро» 16+
00.20 «Видеоспорт» 12+
00.45 «Соотечественники». Я и мое отражение. Ярослав Гашек 12+
01.00 «Соотечественники». За доставленные хлопоты прошу извинить. А.Пешков 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.00, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.45 «Караоке татарча» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.25, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ВЕРТИНСКИЙ» (S) 16+
22.45 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.40 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.20 «Михаил Пиотровский. «Хранитель» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов» 16+
21.20 «КЛЮЧ ОТ ВСЕХ ДВЕРЕЙ» 12+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «В ЗОНЕ РИСКА» 16+
04.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.35, 15.40, 18.25 Новости
06.05, 19.35, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.40 Спец. репортаж 12+
09.30 «ОПАСНЫЙ БАНГКОК» 16+
11.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 «МатчБол»
13.30 «КУЛАК ЛЕГЕНДЫ» 16+
15.10, 15.45 «РОЖДЕННЫЙ ЗАЩИЩАТЬ» 16+
17.10, 18.30 «ТЮРЯГА» 16+
20.30 Футбол. Лига чемпионов. «Лейпциг» (Германия) – «Манчестер Сити» (Англия). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. «Реал» (Мадрид, Испания) – «Интер» (Италия). Прямая трансляция
02.00 Футбол. Лига чемпионов. «Милан» (Италия) – «Ливерпуль» (Англия) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Керлинг. Олимпийский квалификационный турнир. Смешанные пары. Россия – Австралия. Трансляция из Нидерландов 0+
04.30 Гандбол. Чемпионат мира. Женщины. Россия – Сербия. Трансляция из Испании 0+

НТВ

04.55 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» (S) 16+
23.35 «Поздняков» (S) 16+
23.50 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
01.40 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
02.10 «ЮРИСТЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика» 16+
07.50 Субтитры. «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 Субтитры. «Давай разведёмся!» 16+
10.00 Субтитры. «Тест на отцовство» 16+
12.15 Субтитры. «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.30 «Порча» 16+
16.40 «Знахарка» 16+
17.55 «Понять. Простить» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ» 16+
23.00 «ДЫШИ СО МНОЙ. СЧАСТЬЕ ВЗАЙМЫ» 16+
01.00 «Реальная мистика» 16+
02.05 «Тест на отцовство» 16+
03.45 «Давай разведёмся!» 16+
04.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
05.25 Из России с любовью» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Спец. репортаж» 16+
09.40, 01.35 «СЕМЬ СТАРИКОВ И ОДНА ДЕВУШКА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25, 14.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Наука и война». Док. сериал. «Летопись Победы» 16+
19.40 «Легенды армии». Владимир Исаков 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «БУДУ ПОМНИТЬ» 16+
02.55 «Военный врач Иван Косачев. Две пустыни: огонь и лед». Док. фильм. 16+
03.35 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 6–12 ДЕКАБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04) Хискә азрак урын биреп, күбрәк эшләргә. Бу атнаның төп девизы бу. Шулай икән, озакламый кесәнең калынаеп китүенә сөенеп бетә алмаячаксыз. Өстәвенә әле атна ахырында кирәкле бер кеше белән очрашып, бик мөһим бер мәсьәләне хәл итеп куячаксыз.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05) Кемнәрнеңдер хәленә керергә теләп, башыгызны авырттырмагыз. Тырышканыгызның кадере булмаячак. Эштә үзегезгә бер четерекле мәсьәләнең очына чыгарга туры килер. Хафаланасы юк: тиз генә барысын да бик оста хәл итеп, җитәкчегезнең мактау сүзләренә күмеләчәксез.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06) Берничә атна буе күңелегезне тынгысызлап килгән бер проблемадан, ниһаять, котылачаксыз. Әйтергә кирәк, хәйлә һәм зирәклек белән. Эштә әкренләп кенә максатыгызга ирешеп киләсез бугай. Бер үк вакытта сөендерә дә, бераз көендерә дә торган яңалык ишетерсез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07) Бердәнберегез, үзегезне бәхеткә күмеп, бик шәп сюрприз белән сөендерер. Тик менә эштә генә берникадәр буталчыклык хөкем сөрер кебек. Сәбәбе аңлашылгач, барысы да үз көенә кайтыр үзе… Инфляция котыра, дип авыз суын корытсалар да, акча мәсьәләсендә кыенлык булмас.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08) Тормыштан тәм табып, һәр нәрсәдән зур канәгатьлек хисе алып яшәү чоры. Күңелегезгә хуш килмәгән бер генә әйбер дә булмаячак. Шул ук вакытта сәламәтлегегез дә, тьфү-тьфү, тел-теш тидергесез. Пандемия чорындагы кагыйдәләрне төгәл үтәргә тырышасыз, шуңа шулай!

КЫЗ (24.08 – 22.09) Кайчандыр башлап ташлаган эшегезнең очына чыгу өчен искиткеч уңайлы атна. Җитмәсә, искиткеч уңышлы килеп чыгачак әле ул. Сак булыгыз: Яңа ел алды акцияләренә алданып, өч тиенгә яраксыз әйбер сатып алу куркынычы бар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10) Өс-башны карау, йөз-кыяфәтне тәртипкә китерү өчен әйбәт чор. Яшерен-батырын түгел: эшнең көйле баруы, кешеләр белән уртак тел таба белү матурлык, пөхтәлектән дә тора. Ял көннәрендә бер дустыгыздан әйбәт кенә хәбәр килеп төшәр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11) Атна башында үзегезне кызыклы гына хәл көтә. Кызыклы дип, үзегезгә әйбәт кенә файда китерәчәк ул. Эштә сезнең осталыктан көнләшүчеләр барлыкка килер. Иң әйбәте – аларны күрмәмешкә, ишетмәмешкә салышу.

УКЧЫ (23.11 – 21.12) Эштә кайбер кемсәләрдән акыллырак булуыгызны күрсәтергә җай чыгар. Бу хәл сезне бер башка үстереп җибәргәндәй итәр. Атна ахырында нәни генә бер бүләк үзегезне иң бәхетле кеше итеп сизүгә китерер.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01) Ял итү теләге пәйда булыр. Эштәге, өйдәге киеренкелек һәм ыгы-зыгы кайтавазы бу. Күпкә түзгәнне, азга түзегез – бик тиздән барысы да көйләнәчәк.

СУКОЯР (21.01 – 19.02) Экономиягә өйрәнегез – акча мәсьәләсендә кыенлыклар булмаса да, күздә тотылмаган чыгымнар килеп чыгарга мөмкин. Атна башында ярдәм сорарга мөмкиннәр. Әмма дустың дус булсын, хисабың дөрес булсын – менә сезгә шул.

БАЛЫК (20.02 – 20.03) Эштәге бәхәс сезнең файдага хәл ителеп куячак. Акча кереме дә артачак. Бу исә күп кенә проблемалардан котылу мөмкинлеге бирәчәк. Өйдә дә элекке киеренкелек юкка чыгып, искиткеч җылы мөнәсәбәтләр урнашачак.

Белдерү

Аттестат о среднем образовании на имя Орлова Андрея Юрьевича, выданный лицеем № 131 г. Казани в 2012 г., считать недействительным в связи с утерей.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ВТ МАХСУС ПРОЕКТ

МИНЕМ ТАТАРСТАНЫМ
Азнакай

МАРСЕЛЬ ШӘЙДУЛЛИН:
«ВӘГЪДӘ БИРГӘНСЕҢ ИКӘН – ЭШЛӘ!»

Чатыр тавы, бөек шәхесләре, нефть һәм татар төбәге буларак дан казанган Азнакай районы – быел 90 еллыгын, нефть идарәсе 65 еллыгын билгеләп узды. Район башлыгы Марсель ШӘЙДУЛЛИН белән аның тырыш халкы, тарихка мөнәсәбәте, уңышлары һәм авырлыклары турында сөйләштек.

:: Марсель Зөфәрович, шактый авыр елны узып барабыз. Бер яктан пандемия белән сыналсак, икенче яктан авыл хуҗалыгында корылык өметләнгән уңышны алырга мөмкинлек бирмәде. Яңа елны нинди кәеф белән каршы аласыз?

– Әйе, авыл хуҗалыгында, корылык булу сәбәпле, мактанырлык уңышларыбыз юк. Быел без 70 мең тонна ашлык җыеп алдык. Уңыш гектарыннан 12–13 центнер гына чыкты. Шулай да терлек азыгын әзерли алдык. Авырлыкларга карамастан, үз алдыбызга куйган бурыч-максатларыбыз үтәлә. Иң мөһиме, халыкта мал саны кимемәде. Районда 30 меңнән артык терлек бар. Шуларның 12 меңе – савым сыеры. «Агросила Азнакай» җәмгыяте Сукаеш авылында 2000 сыерга исәпләнгән мегаферманы сафка бастырды. Киләсе елга аның икенче чиратын төзеп, сыер санын 4 меңгә кадәр җиткерү планы бар. Районда тәүлегенә 160 тонна сөт савып алына. Ел авыр булуга карамастан, без бу күрсәткечләр белән горурланабыз. Болардан тыш, быел да «Татнефть» ярдәме белән бик күп эшләр башкарып чыктык. Шушы елларда районда теннис үзәге, яңа ЗАГС бинасы төзеләчәк. Күрсәткечләр буенча районыбыз – республикада алдынгылар рәтендә.

:: Шулай да пандемиянең авырлыгы кайсы тармакта аеручанык сизелде?

– Таякның каты башы эшмәкәрлеккә төште. Кайсылары ябылды, кайсыларының керемнәре кимеде, кайсылары хезмәткәрләрен кыскартырга мәҗбүр булды. Республика хөкүмәте, район ярдәм кулы сузса да, шактый авырлыкларга очрадылар. Халыкның сәламәтлеге турында әйтсәк, югалтулар шулай ук шактый булды. Бүген инде авыручылар саны кимүгә таба бара. Әлеге вакытта хастаханәдә кырыклап урын буш. Бер ай элек кенә урын юк иде. Табибларга берьюлы 120–130 авыру белән эшләргә туры килде. Авыручылар саны кимүдә вакцинаның да нәтиҗәсе күренә. Халыкның 85 проценты вакцина ясатты. Сөенечле яңалыгыбыз да бар: хәзер халык томографияне үзебездә генә уза алачак. Моңа кадәр башка шәһәрләргә барырга туры килә иде. Районда гемодиализ үзәге ачылуны да зур уңышыбыз дип саныйбыз. Кадрлар җәлеп итү буенча да сизелерлек эшләр башкарылды. Соңгы өч елда районга җитмешкә якын табиб кайтара алдык. Һәр авылга стоматология вагонын җибәрү дә халыкның саулыгын кайгырту максатыннан эшләнелә. Бүген районда барлыгы 82 студент югары медицина учреждениеләрендә белем ала, шул исәптән Казан дәүләт медицина университетында, җирле бюджет хисабына, «50х50» максатчан программасы буенча 25 бала укый. Хөкүмәт һәм «Татнефть» ярдәме белән белгечләргә 44 яңа фатир бирелде.

:: Азнакайның үзенчәлеге, бренды нәрсә?

– Беренче чиратта аның халкы дип әйтер идем. Чөнки азнакайлылар бик тырыш, сәләтле. Шулай ук табигатебез, Чатыр тавыбыз белән һәрвакыт горурланабыз. «Чатыр тау җыены» халыкара фестивале меңләгән халыкны җыя. Хөкүмәтебез, нефтьчеләребез ярдәме белән шәһәребез елдан-ел зурая. Ачык

һавадагы бассейн да күрше-тирә районнар арасында беренчеләрдән булып бездә ачылды. Быелгы җәйдә генә дә 100 мең турист кабул иттек.

:: Юкка чыккан авыллар – авырткан җиребезнең берсе. Күп очракта җитәкчеләр бу хакта сөйләшмәү яклы. Әмма сез, киресенчә, бу темага зур игътибар бирәсез. Югалган авылларның тарихына багышлап, китаплар чыгарасыз, бәйрәмнәр оештырасыз, элмә такталар, стелалар урнаштырасыз, зиратларын чистартасыз. Мондый игътибар нәрсәгә бәйле?

– Тарихны онытырга ярамый. Ул авыллар, халкы, кайчандыр колхозларны җитәкләгән көчле рәисләр турындагы мәгълүматны буыннан-буынга тапшыру – безнең бурычыбыз. Кайчандыр анда халык яшәгән, әби-бабалары, әти-әниләре җирләнгән зиратлар исән. 20–30 авылда зур эшләр башкарылды. Зиратлары шактыйдан бирле каралмаган тагын җитмешләп авыл бар. Анда элек яшәгән кешеләрне табып, җыелып, зиратларны чистартып, ветераннарның каберләренә таш куйдырырга ниятлибез.

:: Җитәкче буларак эшчәнлегегездә төп принцип нинди?

– Халык мәнфәгатен кайгыртып эшләү, әйткән сүздә тору. Вәгъдә биргәнсең икән – эшлә. Гадилек тә бик кирәк. Беренче чиратта мин халыкка хезмәт итәм, аны яратам. Райондашлар барысын да күреп-белеп тора. Халык белән эшләмәсәң, эш алга бармый. Шуңа күрә без даими рәвештә алар белән очрашабыз, фикерләшеп эшлибез.

:: Азнакайның үсеш ноктасы кайда дип билгелисез?

– Авыл хуҗалыгында резервларыбыз бар. Зур таянычыбыз – нефть өлкәсе һәм эшмәкәрлек. Алар белән бергә кулга-кул тотынышып алга атлау – безнең бурычыбыз. Районда бөтен яктан үрнәк булырга омтылган искиткеч яшьләребез – безнең киләчәгебез күп. Гомумән, безнең Азнакай – табигатьнең матурлыгы, нефть чыгару, җирнең уңдырышлылыгы, кешеләрнең хезмәт сөючәнлеге, гореф-гадәтләрнең сакланышы, үткәнгә карата хөрмәт һәм якты киләчәккә омтылыш урыны.

Шәхесләр

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЙЛАРЫ:
Әкрәм Вәлиев, Петр Манаков, Иван Никитин, Фәйзулла Әгъләтдинов

РОССИЯ ГЕРОЕ:
Ильяс Дауди (Сафин)

СОЦИАЛИСТИК ХЕЗМӘТ ГЕРОЙЛАРЫ:
Гәрәй Баһманов, Алмас Булатов, Әсгать Гарипов, Мөгаллим Гыймазов, Фәхрази Кәримов, Вәгыйз Хаҗиәхмәтов, Михаил Гринь, Газифә Хәсәншина.

ХӘРБИЛӘР:
генерал-майор Фатыйх Булатов, генерал-лейтенант Таһир Сәйфетдинов, вице-адмирал Валерий Пантелеев.

ШАГЫЙРЬЛӘР ҺӘМ ЯЗУЧЫЛАР:
Мәхмүт Хәсәнов, Марсель Галиев, Нур Әхмәдиев, Флера Гыйззәтуллина, Әнәс Кари, Гариф Галиев, Илдус Гыйләҗев, Рөстәм Зәкуанов.

МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘР ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ:
Таҗетдин Ялчыгол, Багбостан Мөэминова, Фәндәс Сафиуллин, Вәли Хаҗиев.

МӘДӘНИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ӘҺЕЛЛӘРЕ:
Нәҗибә Ихсанова, Әзһәр Шакиров, Зәйнәб Фәрхетдинова, Равил Галиев, Данир Сабиров, Әнвәр Шәрәфиев, Луиза Солтанова, Рәмзия Закирҗанова, Гыйбаз Хәбибуллин, Миргаяз Шәрәфиев.

ФӘН ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ:
Габделәхәт Әхмәдиев, Фәрид Галимов, Руслан Гарипов, Әнәс Гатауллин, Ринат Зәкиев, Хәниф Кәримов, Нәфис Сафиуллин, Наил Сафиуллин, Дания Сәлимова, Фатыйма Хәкимова, Рәис Хисамов, Зөһрә Хисаметдинова, Индус Шаматов.

АЗНАКАЙ – САННАРДА

- Азнакай муниципаль районы Татарстанның көньяк-көнчыгышында урнашкан. Тарихи чыганаклар буенча Азнакай авылы **XVIII** гасырның беренче яртысында барлыкка килгән. Район буларак **1931** елның **20** октябрендә оеша.
- Мәйданы – **2168,65** кв. км. **2021** ел башына районда **58999** кеше яши.
- Халыкның **86,1** процентын – татарлар, **11,2** процентын – руслар, **2,7** процентын башка милләт вәкилләре тәшкил итә.
- Азнакай районында **25** мәктәп эшли, аларда **7115** бала белем ала. **55** балалар бакчасы бар.
- Бөек Ватан сугышына Азнакай районыннан **15664** кеше китә, **7978**е сугышта һәлак була яки хәбәрсез югалганнар исемлегендә.

ХУҖАЛЫК ҖИТӘКЧЕСЕ ЛАНДЫШ ЗАКИРОВА:

«МИНДӘ – ИР-АТ ХОЛКЫ»

Хуҗалыкны 21 ел җитәкләгән хатын-кыз белән сөйләшергә туры килгәне юк иде әле. Мишәр Мөслиме авылында фермер хуҗалыгын җитәкләгән Ландыш ЗАКИРОВА белән аралашып утыру үзе бер рәхәт.

– Мин шушы авылныкы, – дип таныштырды ул үзе белән. – Гаиләдә дүрт кыз үстек. Кызлар гына булгач, мин әтинең малае ролендә идем. Бәлки, шулай булырга да туры килгәндер. Бөтен эшне бергә эшләдек. Һәрвакыт аның янында идек. Шуңа күрә холкымда да, гәүдә төзелешемдә дә, тавышымда да ир-ат чалымнары бар. Әни – терлекче, әти механизатор булды. Үзем дә кечкенәдән үк авылны бик яраттым. Авылыбыздагы агроном абыйның басуда машинасы белән йөрүләренә кадәр гел кызыга идем. 8 нче сыйныфны тәмамлагач, Минзәлә техникумында укыдым. 1989 елны колхозда агроном булып эшли дә башладым.

Кияүгә чыккач, гаиләсе белән Мөслим районында яшәп алалар да кабаттан Азнакайга кайтып төпләнәләр. Шуннан соң Ландыш ханым ул вакыттагы район башлыгы Әнәс Исхаков чакыруы буенча, 2000 елда туган авылына «Чулпан» хуҗалыгына җитәкче итеп билгеләнә.

– Бик авыр, болганчык еллар иде. Бурычлар җыелган, малга азык юк. Исемнәр дә берничә тапкыр алышынды. 2006 елдан исә рәсми төстә фермер хуҗалыгына әйләндек. Ләкин исеменә карап, җисеме үзгәрмәде.

:: Шушы еллар эчендә «Бу эш сиңа нигә кирәк? Хатын-кыз башыңа авыр бит» дигән сүзләрне еш ишетергә туры килдеме?

– Әлбәттә. Авылда мәктәп, ферма, колхоз бетсә, авыл юкка чыга, диләр. Кызганыч, мәктәп бетте. Ләкин хуҗалыкны тоттык, ферманы калдыра алдык, агрофирмаларга бирмәдек. Салымнарны түләп, хезмәт хакларын бирепбарабыз. Димәк, тырышуыбыз юкка түгел. 400 баш мөгезле эре терлегебез бар, шуларның 150се – савым сыерлары. Арттыру нияте дә бар, ләкин елы авыр килде бит. Бераз сабыр итәргә туры килә.

:: Әлеге җаваплы эштә сезнең хатын-кыз булуыгыз ярдәм итәме, әллә, киресенчә, авырлык тудырамы?

– Ир-ат булсам, менә шуны эшләр идем, дип уйлаганым юк. Тормыштагы кайбер ситуацияләрдә ир-ат югалып калырга мөмкин. Ир-атларга караганда хатын-кыз коллективын җитәкләргә авыррак. Тормыш булгач, төрле чак була. Бигрәк тә авылда барысы да уч төбендәге шикелле генә. Гаиләләрендә авырлыклар булса, миңа, җитәкче хатын-кыз буларак, аларны хәл итәргә булышу җиңелрәк.

:: Кайвакыт күңелегездәге «егетлек»не дә тартып чыгарырга туры киләдер.

– Ничек кенә әле! Йөрәгеңдә ир-ат холкын йөртмәсәң, мондый эштә эшләп булмый. Безнең хуҗалыкның аякка басып, тыныч кына эшли башлавына 7–8 ел гына әле. Башлаган елларда бик авыр булды. Каты куллы да булырга кирәк иде. Эшчеләрнең күзе сиңа төбәлгән бит.

:: Туктап каласы килгән вакытлар булмадымы?

– Ничек булмасын?! Булды. Мин дә бит – хатын-кыз. Мин дә бит – әни кеше. Минем дә башка хатын-кызлар кебек үк, ир ышыгында гына яшисем, матур күлмәк киеп, җылы өйдә тәмле ризык кына пешереп утырасым килгән вакытлар булды. Бигрәк тә әнә шул болгавыр чорларда. Хәзер, Аллага шөкер, рәхәт яшибез. Канәгатьлек белән, алга план корып эшлибез.

:: Үзегезнең уң кулыгыз кем?

– Төп ярдәмчеләрем – ирем белән улым. Алар һәрвакыт минем янәшәмдә. Улыма – 25 яшь. Барысын да сендереп, күреп үскән бала, мине күз карашымнан ук аңлый. Ә бөтен исәп-хисап эшләре – ирем кулында. Әнием дә, туганнарымның барысы да районнан чыгып китмәде.

:: Иң зур уңышыгыз нәрсәдә?

– Уңышым – соңгы елларда ирешкән дәрәҗәне саклап кала алу, ниһаять, үземнең хезмәтемнән канәгать була башлау. Соңгы 7–8 елда сулыш алып куярга җай була башлады. Аңа кадәр авырлыклар белән көрәшү, проблемаларны чишү генә иде. Аның вакыты да шул иде. Бездән генә тормаган мәшәкатьләр күп булды. Булганны тарату берни түгел, ә менә саклап калу бик зур тырышлык таләп итә. Авыл хуҗалыгында елдан-ел яңалык керә. Бүген яраган иртәгә ярамый. Бер калсаң, берничә елдан куып тоту мөмкин түгел. Шуңа күрә ничек тә тырышырга, сер бирмәскә кирәк.

Бәрәкәтле эш

Районда сөт җыю, суыту, эшкәртү һәм сату юнәлешендә иң уңышлы эшләүчеләрдән «Бәрәкәт» кооперативы санала. Җитәкчесе Рәмис Сәхапов әйтүенчә, 2018 елдан бирле эшләп килүче оешма көн саен шәхси һәм фермер хуҗалыкларыннан 7 тонна сөт җыеп ала. 194 шәхси хуҗалык булса, егермесе – фермерлар.

– Бүген безгә кеше 10 литр сөт бирәме, 20ме, 100 литрмы – аерма юк. Машина йөртүче һәркайсына туктап, сөтен алып китә. Элек сөте аз булган шәхси хуҗалыкларга туктап та тормаучылар булган, – ди Рәмис.

Бүген кооператив халыктан җыелган сөткә 26 сум 50 тиен акча түли. Башлангыч елларда башкаларга шактый көндәшлек тудырган.

– Бездә һәрвакыт бәяләр түбән иде, – ди Азнакай районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары Рәсим Бәдретдинов. – Аерма литрына 5–6 сум була торган иде. Егетләр килгәч, әлеге базарга сизелерлек үзгәреш керттеләр. Халыктан җыела торган сөт бәяләре 2–3 сумга күтәрелде. Башта кеременнән бигрәк югалтулары күбрәк булды, тик аның каравы алар сөт базарындагы бәяләрне күтәрүгә иреште.

Эшли башлаган чорларын Рәмис тә иң мәшәкатьле вакытларның берсе дип искә алды.

– Икенче яктан, үзем районда фермерлык ассоциациясе җитәкчесе булгач, алар белән эшләү уңайлырак иде. Барысы да – сөт бәяләрен күтәрергә теләүдән башланган эш. Яратып, кызыксынып башкарам хезмәтемне. Районда 100ләп фермер бар, – ди Рәмис.

Быел кооператив Түйкә авылында эшкәртү цехын ачып җибәргән. Җыелган сөтнең 10–20 процентын үзләре эшкәртә. Калганын зуррак заводларга җибәрәләр.

– Хәзерге вакытта көн саен ике тонна сөт эшкәртәбез. Азнакай районындагы егерме кибеткә авыл каймагы, эремчек, ряженка, кефир, сыр һәм сөт җибәрәбез. Әлегә барлык продукция сатылып бетеп бара. Киләчәктә бөтен сөтне үзебездә эшкәртеп, район халкын продукция белән тулысынча тәэмин итү бурычы тора. Кем белә, аннан соң, бәлки, республикага да чыгара насыйп булыр, – ди кооператив җитәкчесе.

Сөтнең сыйфатына да зур игътибар бирелә. Кабул ителә торган һәркайсы җентекләп тикшерелә.

– Иң еш очрый торган проблема – сөтнең әчүе. Ләкин үзебез эшкәртүч, андыйларын да кире борып җибәрмибез. Кефир ясыйбыз. Ә менә элек чыннан да авыр мәсьәлә иде. Заводлар алмагач, кире борып җибәргән чаклар күп булды, – ди ул.

Дөрес, эшкәртү цехы ясау чыгымлы эш булгач, узган елның ахыры – быелның башында халыкка түләнә торган сөт бәяләрен башкалар белән тигезләргә карар кылганнар. Бүген кооперативта 194 әгъза санала.

– Кооператив әгъзаларына зур игътибар бирәбез. Аларның продукциясенең күләмен һәм сыйфатын арттыру өстендә эшлибез. Хуҗалыклар терлекләренә витаминнарга бай, сыйфатлы, тәмле азык бирсен өчен, үзебезнең терлек азыгы үзәген ачтык. Бу мәсьәләдә эре хуҗалыклардан калышмаска исәп. Шәхси хуҗалыкларның үзләренә генә моңа ирешү авыр булыр иде. Сөт күләменә карамыйча, хуҗалыкларның һәркайсын ризык белән тәэмин итәсебез килә. Дөрес, башта халыкны яңалыкка күнектерергә кирәк булды, – дип елмая Рәмис.

ТУРИСТ КҮРЕРГӘ ТИЕШЛЕ 6 УРЫН

Туган якны өйрәнү музее

Сөембикә урамы



«Тарсус» паркы

СӘЯХӘТЧЕ УЕНЧЫКЛАР

Биредә татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, тормыш фәлсәфәсе белән уенчыкларга карап та танышырга мөмкин. Моның өчен кайчандыр данлыклы Дымков уенчыкларын кабатларга тырышып, соңыннан үзенә генә хас стиль булдырган Актүбә остасы Илсөяр Сәлахова янына кунакка килергә кирәк.

Азнакайга кадәр барып, районның брендына әверелгән «Актүбә уенчыгы»н күрми китеп булмады. Кайчандыр өйдә генә ясалган уенчыкларны бүген берничә оста җитештерә. Актүбә сәнгать мәктәбе директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, халык кәсепчелеге остасы Илсөяр Сәлахова сүзләренчә, өч дистәгә якын ел эчендә уенчык ясау ысуллары да, технологиясе дә шактый үзгәргән.

«Без «Актүбә уенчыгы»н партияләп җитештерәбез, шуңа да хәзер тизлек мөһим. Уенчыкларны гипстан махсус формалар ярдәмендә билгеле бер рәвешкә китерәбез, ә буяу эшләре кулдан башкарыла», – дип сөйләде ул. Ә максат үзгәрмәгән: «үзебезнеке» дип әйтерлек милли сувенирлар ясау. Үзебезнеке, димәктән, аңа кул сузучылар да юк түгел икән. «Безнең уенчыкларга охшатып, сувенирлар ясап сатучылар бар. Димәк, көндәшлек тә юк түгел. Тик алар пластик куллана, тиз һәм күп җитештерсәләр дә, сыйфат ягы аерыла», – диде бу турыда Илсөяр ханым.

Әлеге эшкә алынганда, Илсөяр ханым күргән-белгәннәреннән файдалана. Татар хатын-кызлары ничек киенгән, татар авылларында көнкүреш нинди булган, татар кешесе нәрсәне бик кадерләгән – барысын да искә төшереп һәм күз алдына китереп эшли. Уены-чыны бергә, диярсең. Ул чакта файдаланыр өчен махсус әдәбият табу кыенрак булган икән. Хәзер исә эшләр җайланган. Һәр уенчыкның «умыртка»сын үзе сыза Илсөяр Сәлахова. Эшне рәсемен ясап башлый һәм һәр уенчыкка исем кушып тәмамлый икән. «Укып, эзләнеп кенә калмыйбыз, тормыш иптәшем белән Россия шәһәрләре буйлап сәяхәт тә итәбез. Иң кызыксындырганы – халык кәсепчелеге. Ә ул яши әле», – ди ул үзе.

Ә халык кәсепчелеге статусын «Актүбә уенчыгы» 2000 елда ук ала. Бүген аларны Татарстан һәм Россиядә генә түгел, АКШ, Бөекбритания, Көньяк Словакия һәм башка илләрдә дә беләләр. Заманында уенчыкны күчтәнәч итеп АКШның 42 нче Президенты Билл Клинтонга да биргән булганнар. Актүбә сәнгать мәктәбендә Вашингтондагы Ак йорттан килгән Рәхмәт хаты түрдә урын алган.

Тиктормас Соколов дөньясы

Поши башлары, дәү кабан, бурсык-куяннар, кап-кара еланнар, киң канатлы бөркетләр... Юк ла, Азнакай урманнарында адашып йөрмәдек без. Бөтен гомерен балаларга багышлаган, җитмештә дә тик утырмаган Владимир Антонович Соколовның «дөнья»сында булып кайттык.

Ул әле дә ярты гомерен уздырган Актүбә мәктәбенә ашкынып килә. Дәресләренең күбесен урманның көчле кулларына тапшырса да, балалар белән эшләүдән һаман тәм таба. Мәктәптә үз почмагын да булдырган. Физкультура укытучысы булып эшли генә башлаганда ук, бернидән курыкмаган Владимир Антонович: туристик түгәрәк оештырып, дистәләгән балалар белән әллә кай җирләргә походка дип чыгып киткән. Урал, Төньяк Кавказ – ничәмә-ничә тапкыр айкаган урыннарының бик азы гына.

Сәяхәтләрдән исә буш кайтмый Владимир әфәнде. Ул оештырган музейдагы исәпсез кыйммәтле ташлар – шул еллар истәлеге. Һәркайсының тарихын, ә күбесенең бүгенге бәясен дә бик яхшы белә, кунакларга да сөйли. «Күпләр миңа музей тәрәзәләренә рәшәткә куярга куша, бу байлыкны урлар дип куркалар. Ә мин курыкмыйм. Саный башласаң, монда бер кабанны гына да 100 меңгә сатып җибәрергә була», – ди үзе.

Музейда иң таң калдырганы – төрледән-төрле хайван карачкылары. Аучылык белән кызыксынучы Владимир әфәнде хайван тиреләрен ташламый. «Карачкы ясау – бик четерекле, вак эш. Мәсәлән, менә бу кабан дуңгызын ясау өчен биш-алты айлап вакыт китте. Ләкин нәтиҗәсенә бер карау да җитә инде!» Барлык хайваннар аудан кайткан табыш түгел, билгеле. Күбесе – олы юлларда машиналар харап иткән кош-кортлар, җәнлекләр. Аларга Владимир Антонович кына түгел, аны күргән-белгәннәр дә игътибарлы икән. «Юлда шундый бер кош яки берәр хайван күрсәләр, миңа алып киләләр. Аучылар да шулай эшли. Барысын да үз җаем белән эшкәртәм аннары», – ди ул.

Һәр сабыйга – бишек җыры

«Әлли-бәлли итәр бу...» Әниегезнең йомшак тавыш белән салмак кына шушы җырны көйләгәнен хәтерлисезме? Хәзер сирәгрәк яңгыраса да, бишек җырларының сабыйларны йоклатучы гына түгел, ә ана белән баланың рухи дөньясын тоташтыручы күпер икәне күпләргә мәгълүмдер.

Азнакайда моны бик яхшы аңлыйлар. Шулай булмаса, районның һәр балалар бакчасында бишек җырларын көйләмәсләр иде. Азнакай район Советының оештыру бүлеге һәм районның хатын-кызлар берлеге җитәкчесе, «Бишек җыры» проектының идея авторы Эльвира Галиева сүзләренчә, мондый җырлар балаларда үз телләренә карата мәхәббәт уята.

– Әлеге проект 2016 елдан бирле эшли. Бүген бишек җырларын районның һәр тәрбиячесе диярлек белә. Без татар, рус, төрек, әрмән һәм башка телләрдәге җырларны туплап, текст һәм аудио форматындагы җыентыклар чыгардык, балалар бакчаларында эшләүчеләргә барысын аңлаттык, – дип сөйләде ул. – Бишек җырлары зур тәрбияви көчкә ия. Бала өчен тәрбияче – авторитет. Әгәр ул сабый балалар бакчасындагы йокы сәгатендә тәрбияче апасының бишек җыры көйләгәнен өенә кайтып сөйли һәм әнисенең дә җырлавын сорый икән, без максатыбызга ирештек дигән сүз.

Эльвира ханым әйтүенчә, ана моңы балага мәхәббәтне түкми-чәчми җиткерергә сәләтле. Тәрбиячеләрне генә түгел, аналарны да «әлли-бәлли көйләргә» өйрәтер өчен, Азнакайда түгәрәкләр дә эшләп килә. Шул рәвешле татар халкының милли хәзинәләреннән берсе булган бу җырларны халыкка таратасылары килә аларның.

Ык елгасы буйлап сәяхәт



Чатыр тау

Парапланда очу

ТӘГӘРМӘЧЛЕ ЙОРТ



Азнакай егетләре Илдар Сөнәгатов һәм Эдуард Петкеев ясый торган тәгәрмәчле йорт тагылмаларының (прицеп) даны Германия, Италия, Казахстан кебек илләргә кадәр таралган. Үзенең кухнясы, ял итә торган зонасы, биобәдрәфе булган әлеге техниканың популярлыгы елдан-ел арта.

Әлеге тагып йөри торган йортларны җылытырга, түшәмнәрен ачып куярга, караватка ятып, зур тәрәзәләре аша йолдызлар күзәтергә дә мөмкин. Кайнар һәм җылы суына кадәр бар. Кыскасы, могҗиза!

Предприятиенең генераль директоры Илдар Сөнәгатов әйтүенчә, егетләр «Тәгәрмәч өстендә сәяхәт итү» проектын 2018 елда тормышка ашыра башлаган.

– Без икебез дә 12 ел «Нефтемаш» заводында эшләдек. Аннан киткәч, менә шундый туристик йортлар төзү идеясе барлыкка килде һәм без районда эшмәкәрләр белән эшләүче Әнвәр Җиһангировка мөрәҗәгать иттек. Чөнки бу – бик җитди эш. Азнакай башлыгы Марсель Шәйдуллин теләктәшлек күрсәткәч, субсидияләр алып, үз эшебезне ачып җибәрдек. Шунысы мөһим: аренда өчен түләмибез. Безнең өчен бу – шулай ук зур ярдәм, – ди Илдар.

Эшмәкәрләр әйтүенчә, башлаганда авырлыклар булган, әлбәттә. Һәркайдагы кебек, монда да эшнең нәтиҗәсен күрү өчен, күпмедер вакыт узу кирәк. Сатып алучы табу да җиңел булмаган.

– Беренче ике елда кышкы сезонда бик авыр булды. Чөнки безнең прицеп яңалык булып килеп керде. Халык, болай сәяхәт итәргә мөмкиндер, дип күз алдына да китерми иде.

Хәзерге вакытта тәгәрмәчле йортның биш төрен ясыйлар. Бәяләренә килгәндә, 269 мең сумнан башлап 1 млн 600 меңгә кадәр җитә. Иң зурысы ике балалы гаилә сәяхәт итә алыр өчен ясалган. Оешманың баш конструкторы Эдуард Петкеев әйтүенчә, мондый йортларны ясар өчен 10 көннән башлап 4 айга кадәр вакыт кирәк. Ай саен уртача алганда биш шундый йорт ясап саталар. Гомумән алганда, эшмәкәрләр ясаган йортларның гомуми саны 100дән арткан.

– Аңлашыла инде, иң кыйммәтле тагылма – көчне дә, вакытны да иң күп алганы. Әлегә мондый катлаулы заказларны вакытлыча туктатып торырга булдык. Аны ясарга киткән вакыт эчендә ун яки егерме гади йорт эшләп була. Аларына ихтыяҗ да зур. Халыкта иң популярлары – 400–500 мең сумлыклары, – ди алар.

Әлегә аена биш йорт әлгертсәләр, киләсе елның гыйнварыннан унга җиткермәкче булалар. Инде апрельгә кадәр килешүләр төзелгән, хуҗалары тәгәрмәчле йортларын көтә.

– Бер урында гына торырга яратмыйбыз. Безнең өчен үсеш, алга бару мөһим. Яңалык буларак, йортларны ясау технологиясен алыштырдык. Моның өчен яңа җиһаз кирәк булачак. Хәзерге вакытта шушы мәшәкатьләр белән мәшгульбез, – ди Илдар Сөнәгатов.

Теләк тә, дәрман да бар. Тик менә монда да кадрлар мәсьәләсе авыррак икән. Азнакай башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе Әнвәр Җиһангиров әйтүенчә, эшче куллар җитми.

– Соңгы вакытта бик күп эшмәкәрләр белән аралашырга туры килә. Кызганыч, кадрлар мәсьәләсе бик катлаулы, – ди ул. – Хезмәт базарында эшче һөнәр ияләренә ихтыяҗ зур. Станокта эшләргә теләк белдерүчеләр юк диярлек. Югыйсә яхшы хезмәт хакы да түлиләр.

АЗНАКАЙ СЫЙЛАРЫ

ТАБИКМӘК

Азнакай блогеры Нурия ханым (@nuriya_hanum) татар халкының күркәм таба ризыгы – табикмәкне менә болайрак әзерли.

Кирәк: 6 йомырка, 1 л җылымса сөт, чүпрә, чәй кашыгы белән тоз, 2–3 аш кашыгы шикәр комы, 3 аш кашыгы тары оны, ярты стакан манный ярмасы, он.

Эш барышы: йомырканың агы белән сарысын аерасы. Камырын ясар өчен башта сарысы гына кулланыла, агы камыр ачыгач салына. Калган барлык ингредиентларны кушып, сыеграк кына камыр ясыйсы. Әзер камырны ачыганчы җылы урынга куеп торырга.

Табикмәкне кызган табада пешерәсе.

БӘРӘҢГЕ ТӘКӘСЕ

Камыр өчен: сөт һәм су, аз гына шикәр комы, тоз, бер аш кашыгы майонез, аз-азлап кына каз мае, ак май һәм үсемлек мае.

Эчлек өчен: вак итеп туралган бәрәңге, суган, тоз һәм ике төрле борыч. Пешкәч тә эчлеккә ак май сипсән, тагын да тәмлерәк була.

Бәрәңге тәкәсен кызарганчы 30–40 минут пешерәбез.

БАЛАН БӘЛЕШЕ

Лилия Мостафинадан рецепт.

Камыр өчен: 3 стакан җылы сөт, 1 аш калагы чүпрә, 5 аш калагы шикәр, 1 чәй калагы тоз кирәк булачак. Шуларның барысын да кушып, 5 калак он өстәп, 15–20 минут «ял иттерәсе». Шуннан соң ярты стакан көнбагыш мае, чама белән он салып, йомшак итеп камыр басабыз. Камырны төреп, җылы урынга куябыз.

Эчлек өчен: 5 стакан баланны (катырылган булса да ярый) җылы суда юабыз. Аңа 2 стакан манный ярмасы салабыз да, 2 стакан шикәр комы өстәп, болгатабыз.

Игътибар – үзе дәва

Горур Чатыр таудан ерак китәсе юк – шифаханә күренә. Күрше Башкортстан гына түгел, Самара, Оренбург, Чиләбе өлкәләре, хәтта Дагыстаннан ук килеп тә, шифасын күреп китәләр аннан. Даны еракка таралган Азнакай шифаханәсенең үзенчәлеге нидә?

Шифа йортының бинасын узган гасырның 60 нчы елларында ук нефтьчеләр сала. Ул вакытта бина баракка охшаган була. Хәзер бар да башкача, билгеле. Заманча корпуслар, өр-яңа технологияләр белән баетылган дәвалау бүлмәләре – шифаханәнең иң зур горурлыгы. Коридор буйлап атлаганда, бер дә медицинага бәйле урында димәссең үзеңне. Шифаханәнең администраторы Ләлә Нуретдинова сүзләренчә, дәваланырга килгән кешеләргә өйдәге кебек уңайлы мохит булдыру – төп бурычларының берсе.

– Без – бер гаилә. Дәваланучы белән дәвалаучы арасында электән шундый мөнәсәбәтләр урнашты. Безгә килгәннәр якын итүебезне карашыбыздан аңларга тиеш. Монда эшләүчеләр бер-берсенә дә шундый мөгамәләдә. Ләкин сөйләшеп караганчы, башта тирә-якка күз төшә бит. Игътибар итсәгез, шифаханә зур бер йортка охшаган. Монда хәтта төсләр дә шул хакта аңлата кебек, – дип сөйләде ул безгә.

Аппаратлы физиотерапия, натуротерапия, галотерапия, диетотерапия, криотерапия, балчык белән дәвалау... Ләлә ханым сөйләгән җылы, өйдәгечә мохиттә менә шушындый традицион һәм заманча дәвалау ысуллары кулланыла. «Баш табибыбыз Рөстәм Дәүләтшин медицина өлкәсендәге иң алдынгы технологияләр, дәвалау ысуллары белән һәрдаим танышып тора. Башка бер җирдә дә булмаган махсус аппаратлар – шуның дәлиле», – диде Ләлә ханым.

Азнакайдагы шифаханәгә дәва алырга килүчеләрне республиканың иң биек ноктасы – Чатыр тау белән дә таныштыралар. «Тауга менеп төшкәч, бөтен авыруларын оныткан күк булалар. Безнең шифаханәдә дәваланучы һәм ял итүчеләргә бәйле шундый күп хатирәләрем бар. Бервакыт бик ерактан бер абзый килде. Яшәренә бик аз вакыт калган, инде ышанычы да беткән. Ләкин менә-менә туарга торучы оныгы белән очрашасы килә иде аның. Ул вакытта да Чатыр тауга менәргә карар кылынды, ләкин бу кеше таунын итәгеннән ары күтәрелергә теләмәде. Мин аңа: «Күңелегездә йөрткән теләгегезне тауга менеп әйтеп карагыз әле», – дидем. Таудан төшкәч, карашы ук башка төрле иде аның. Чатыр тауның көче анда ышаныч уяткан. «Беләсезме, гомерем булып, оныгымны күрә алсам, аңа «Вера» исеме куштыртам», – диде ул. Биш еллап вакыт узган микән соң, шифаханәгә кечкенә Верочка белән бабасы килеп керде...» – дип искә алды Ләлә Ибраһим кызы.

Зөһрә САДЫЙКОВА, Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары

8 декабрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 23.30 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Калеб» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
17.00, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». Габделфәт Сафин 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.30 «Вызов 112» 16+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Соотечественники» 12+
00.20 «Соотечественники». Халил Абжалилов. Путь от пастуха до короля Британии 12+
00.45 «Черное озеро». Альметьевский чекист 16+
01.10 «Память сердца» 12+
01.25 «Не от мира сего...» 12+
01.40 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Tatarstan today. Дөньяга ачык» (субтитрлы) 12+
23.00 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә»(субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт 6+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Әлфия Айдарская турында телеочерк 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.45, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера года. «ВЕРТИНСКИЙ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Док-ток» 16+
23.55 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.35 «Фрейндлих. Алиса в стране лицедеев» 12+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 Премьера. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Премьера. «КЛЮЧ ОТ ВСЕХ ДВЕРЕЙ» 12+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 В ЗОНЕ РИСКА» 16+
04.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 15.40 Новости
06.05, 16.15, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 11.35 Специальный репортаж 12+
09.20 «СЧАСТЛИВОЕ ЧИСЛО СЛЕВИНА» 16+
11.55 Футбол. Юношеская лига УЕФА. «Зенит» (Россия) – «Челси» (Англия). Прямая трансляция
14.00, 15.45 «АМЕРИКАНЕЦ» 16+
16.55 Хоккей. КХЛ. «Трактор» (Челябинск) – СКА (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
19.20 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 0+
20.20 Футбол. Лига чемпионов. «Зенит» (Россия) – «Челси» (Англия). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. «Бавария» (Германия) – «Барселона» (Испания). Прямая трансляция
02.00 Футбол. Лига чемпионов. «Аталанта» (Италия) – «Вильярреал» (Испания) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Керлинг. Олимпийский квалификационный турнир. Смешанные пары. Россия – Германия. Трансляция из Нидерландов 0+
04.30 Баскетбол. Евролига. Женщины. УГМК (Россия) – ТТТ (Латвия) 0+

НТВ

04.55 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ГОРЯЧАЯ ТОЧКА» (S) 16+
23.40 «Национальная спортивная премия в 2021 году». Торжественная церемония награждения лауреатов (S) 12+
01.50 Их нравы 0+
02.10 Детективный сериал «ЮРИСТЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика» 16+
07.50 Субтитры. «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.30 «Порча» 16+
16.40 «Знахарка» 16+
17.55 «Понять. Простить» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ 2» 16+
22.55 «ДЫШИ СО МНОЙ. СЧАСТЬЕ ВЗАЙМЫ» 16+
01.50 «Реальная мистика» 16+
02.45 «Тест на отцовство» 16+
04.25 «Давай разведёмся!» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.05 Субтитры. «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Специальный репортаж» 16+
09.40, 01.30 «СВЕРСТНИЦЫ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25, 14.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Наука и война». Док. сериал. «Найти и уничтожить!» 16+
19.40 «Главный день». «Фильм «Доживём до понедельника» и Ирина Печерникова» 16+
20.25 «Секретные материалы». Док. сериал 16+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «СУМКА ИНКАССАТОРА» 12+
02.45 «Маресьев: продолжение легенды». Док. фильм. 12+
03.35 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+

9 декабрь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 23.30 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлан» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
17.00, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». Рифат Зарипов 6+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.30 «Вызов 112» 16+
21.00, 01.10 Черное озеро 16+
00.20 «Видеоспорт» 12+
00.45 «Соотечественники». Альбина Шагимуратова. Примадонна Востока и Запада 12+
01.35 «Память сердца» 12+
01.50 «Не от мира сего...» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БИТ шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Халкым минем» 12+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Әдәби хәзинә». Хәй Вахит 12+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Оныта алмыйм» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.05, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ВЕРТИНСКИЙ. ПЕСНИ» (S) 16+
22.30 «Большая игра» 16+
23.25 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.05 К 80-летию Виталия Соломина. «...И вагон любви нерастраченной!» 12+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут» 12+
14.55 Премьера. Алёна Спивак, Леонид Кулагин, Дмитрий Блохин, Валерий Сторожик. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Премьера. Светлана Колпакова, Алексей Фатеев, Андрей Фролов, Сергей Юшкевич, Елена Симонова. «КЛЮЧ ОТ ВСЕХ ДВЕРЕЙ» 12+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 Евгений Сидихин, Алексей Кравченко, Наталья Рычкова. «В ЗОНЕ РИСКА» 16+
04.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.55, 12.35, 15.40, 18.30 Новости
06.05, 18.35, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.20 «ТЮРЯГА» 16+
11.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00, 19.30 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 0+
14.00, 15.45 «НОКАУТ» 16+
16.35 «ХРАНИТЕЛЬ» 16+
20.30 Футбол. Лига Европы. «Легия» (Польша) – «Спартак» (Россия). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига Европы. «Марсель» (Франция) – «Локомотив» (Россия). Прямая трансляция
02.00 Футбол. Лига Европы. «Наполи» (Италия) – «Лестер» (Англия) 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Зенит» (Россия) – «Фенербахче» (Турция) 0+
05.00 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Маккаби» (Израиль) – УНИКС (Россия) 0+

НТВ

04.55 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Антон Пампушный, Олег Тактаров. «МАГИСТРАЛЬ» (S) 16+
00.10 «ЧП. Расследование» (S) 16+
00.45 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
01.10 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
02.10 Детективный сериал «ЮРИСТЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика» 16+
07.50 Субтитры. «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.40 «Порча» 16+
16.45 «Знахарка» 16+
17.55 «Понять. Простить» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ 2». 5-я - 8-я серии 16+
22.55 «ДЫШИ СО МНОЙ. СЧАСТЬЕ ВЗАЙМЫ» 16+
01.50 «Реальная мистика» 16+
02.45 «Тест на отцовство» 16+
04.25 «Давай разведёмся!» 16+
05.15 Субтитры. «По делам несовершеннолетних» 16+
06.05 «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Специальный репортаж» 16+
09.40 «ВОЗВРАЩЕНИЕ ВЫСОКОГО БЛОНДИНА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25, 14.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Наука и война». Док. сериал. «Кузница Победы» 16+
19.40 «Легенды науки» 12+
20.25 «Код доступа» 12+
21.15 Новости дня 16+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.40 «СУВЕНИР ДЛЯ ПРОКУРОРА» 16+
01.30 «НЕПОДСУДЕН» 12+
02.50 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ...» 12+
04.15 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+

10 декабрь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 20.45 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.00 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30, 16.00, 21.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» һәм «Сәйлан» 0+
16.30 «Точка опоры» 16+
18.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Нефтехимик». Прямая трансляция 6+
22.30 «Вызов 112» 16+
23.30 «КЛУБ ЛЮБИТЕЛЕЙ КНИГИ И ПИРОГОВ ИЗ КАРТОФЕЛЬНЫХ ОЧИСТКОВ» 12+
01.35 «Соотечественники». А.Арбузов. Волшебник органической химии 12+
01.50 «Черное озеро». Особая примета 16+
02.15 «УПКЫН» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Нәсыйхәт» 6+
18.30 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Нефтехимик» (Түбән Кама). Трансляция Казаннан 6+
21.55 «Туган җир» 12+
23.05 «Ком сәгате» 12+
00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
01.05 М. Гыйләҗев. «Бала баласы балдан татлы». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 13.40, 17.00 «Время покажет» 16+
12.55 «Горячий лед». Гран-при 2021. Финал. Осака. Фигурное катание. Женщины. Короткая программа. Прямой эфир из Японии (S)
15.15 «Горячий лед». Гран-при 2021. Финал. Осака. Фигурное катание. Танцы. Произвольный танец. Прямой эфир из Японии (S)
16.00, 04.25 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.30 «Голос». Юбилейный сезон (S) 12+
23.20 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 Док. фильм «Джим Моррисон – Последние дни в Париже» (S) 18+
01.25 «Вечерний Unplugged» (S) 16+
02.10 «Наедине со всеми» 16+
02.55 «Модный приговор» 6+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 20.45 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут» 12+
14.55 Премьера. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.00 Премьера. «Юморина-2021» 16+
23.00 Премьера. «Веселья час» 16+
00.45 «РАЗЛУЧНИЦА» 16+
04.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.35, 20.50 Новости
06.05, 17.50, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.25 «АМЕРИКАНЕЦ» 16+
11.35 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 Биатлон. Кубок мира. Спринт. Мужчины. Прямая трансляция из Австрии
15.05 Футбол. Еврокубки. Обзор 0+
15.55 Биатлон. Кубок мира. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Австрии
18.25 Хоккей. КХЛ. «Ак барс» (Казань) – «Нефтехимик» (Нижнекамск). Прямая трансляция
20.55 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Жальгирис» (Литва) – ЦСКА (Россия). Прямая трансляция
23.40 «Точная ставка» 16+
00.00 Смешанные единоборства. «Битва чемпионов. Школа против школы». Трансляция из Москвы 16+
01.00 Смешанные единоборства. Eagle FC. Мехди Дакаев против Маккашарипа Зайнукова. Трансляция из Москвы 16+
02.00 Бобслей и скелетон. Кубок мира. Трансляция из Германии 0+
03.00 Хоккей. НХЛ. «Вашингтон Кэпиталз» – «Питтсбург Пингвинз». Прямая трансляция
05.30 «РецепТура» 0+

НТВ

04.55 Сериал «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.25 «Простые секреты» (S) 16+
09.00 «Мои университеты. Будущее за настоящим» (S) 6+
10.25 «ЧП. Расследование» (S) 16+
11.00 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» (S) 16+
18.00 «Жди меня» (S) 12+
20.00 Премьера. «МАГИСТРАЛЬ» (S) 16+
00.20 «Своя правда» (S) 16+
02.00 Квартирный вопрос (S) 0+
02.55 «ЮРИСТЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «Реальная мистика» 16+
07.50 Субтитры. «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.30 «Порча» 16+
16.40 «Знахарка» 16+
17.55 «Понять. Простить» 16+
19.00 «САДОВНИЦА» 16+
23.20 «Про здоровье» 16+
23.35 «ПИСЬМО ПО ОШИБКЕ» 16+
03.00 «Реальная мистика» 16+
03.50 «Тест на отцовство» 16+
05.30 «Домашняя кухня» 16+
05.55 «6 кадров» 16+
06.00 «МОЯ ЛЮБИМАЯ МИШЕНЬ» 16+

ЗВЕЗДА

05.50 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
08.10, 09.20 «ФАРТОВЫЙ» 16+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
10.50, 13.25, 14.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.40, 21.25 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
21.15 Новости дня 16+
23.10 «Десять фотографий». Григорий Гладков 12+
00.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ ВЫСОКОГО БЛОНДИНА» 12+
01.35 «Военный врач Николай Бурденко. Война длиною в жизнь». Док. фильм 16+
02.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+

11 декабрь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12 +
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Мин»12+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «И туган тел...» 6+
13.45 «Гармунлы сәяхәт». Айзат Мәрданов 6+
15.00 «Туган җир» 12+
15.30 «Юлчы» 6+
16.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». Салават Миннеханов 6+
16.30 «Татарлар» 12 +
17.00 «Әдәби хәзинә» 6+
17.30 «Адымнар» 12+
18.00, 20.00 IX «Болгар радиосы» Милли музыка премиясен тапшыру тантанасы. Турыдан-туры трансляция 6+
19.30 Новости в субботу 12+
22.00 «КунакБиТ шоу» 12+
23.00 «ТУПОЙ И ЕЩЕ ТУПЕЕ-2» 12+
00.55 «Каравай». Старинные тюрко-татарские инструменты 6+
01.20 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
01.45 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
02.35 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Яралы язмышлар». Хәсән Туфан 12+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит» 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Яралы язмышлар». Хәсән Туфан 12+
14.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Хәлил Әбҗәлилов турында телеочерк 6+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
18.00, 20.30 «Болгар радиосы»ның IX Милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы 6+
20.00 «Адымнар» 12+
22.00 З. Хәким. «ИСКӘН ҖИЛЛӘР КӨЕНӘ» 12+
00.25 М.Фәйзи. «ГАЛИЯБАНУ» 12+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 Умницы и умники 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Этери. Диалоги с королевой льда» 16+
11.30 «Горячий лед». Гран-при 2021. Финал. Осака. Фигурное катание. Пары. Произвольная программа. Женщины. Произвольная программа. Прямой эфир из Японии
12.15 «Горячий лед». Гран-при 2021. Финал. Осака. Фигурное катание. Прямой эфир из Японии (S)
14.05 К юбилею Клары Новиковой (S) 16+
16.20 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым 12+
17.55 «Ледниковый период». Новый сезон (S) 0+
21.00 «Время»
21.20 «Сегодня вечером» 16+
22.45 Бокс. Бой за титул Чемпиона мира. Дмитрий Бивол (Россия) – Умар Саламов (Россия), Магомед Курбанов (Россия) – Патрик Тейшейра (Бразилия). Прямой эфир (S)
23.45 «Вертинский. Песни» (S) 16+
00.50 «Наедине со всеми» 16+
01.45 «Модный приговор» 6+
02.35 «Давай поженимся!» 16+
03.15 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
12.35 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
13.40 Мария Куликова, Владислав Резник, Алиса Авчинник, Анатолий Голуб. «ДОКТОР УЛИТКА» 12+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести в субботу
21.00 Премьера. Анастасия Крылова, Джеймс Тратас, Екатерина Копанова, Михаил Тарабукин, Дмитрий Пчела, Екатерина Семёнова. «ДОМ, ГДЕ СЕРДЦЕ» 12+
01.15 «ОТ СУДЬБЫ НЕ ЗАРЕКАЙСЯ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Крис Колберт против Хайме Арболеды. Бой за титул чемпиона мира по версии WBA. Трансляция из США 16+
07.00, 09.00 Новости
08.05, 13.25, 22.00, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «МЕТЕОР НА РИНГЕ». Мультфильм 0+
09.25 «ХРАНИТЕЛЬ» 16+
11.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «ПАРМА-ПАРИМАТЧ» (Пермский край) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар). Прямая трансляция
13.55 Биатлон. Кубок мира. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Австрии
15.05, 17.50 Лыжный спорт. Кубок мира. Спринт. Трансляция из Швейцарии 0+
15.55 Биатлон. Кубок мира. Эстафета. Женщины. Прямая трансляция из Австрии
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Ростов» (Ростов-на-Дону) – «Урал» (Екатеринбург). Прямая трансляция
20.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Венеция» – «Ювентус». Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Удинезе» – «Милан». Прямая трансляция
01.40 Сноубординг. Кубок мира. Параллельный гигантский слалом. Трансляция из Магнитогорска 0+
02.30 Формула-1. Гран-при Абу-Даби. Квалификация 0+
03.45 Гандбол. Чемпионат мира. Женщины. Трансляция из Испании 0+
05.00 Профессиональный бокс. Василий Ломаченко против Ричарда Комми. Прямая трансляция из США

НТВ

05.35 Павел Трубинер. «ВЫЗОВ» (S) 16+
07.25 Смотр (S) 0+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 «Готовим» (S) 0+
08.45 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.25 Едим дома (S) 0+
10.20 Главная дорога (S) 16+
11.00 «Живая еда» (S) 12+
12.00 Квартирный вопрос (S) 0+
13.00 «Однажды...» (S) 16+
14.00 «По следу монстра» (S) 16+
15.00 Своя игра (S) 0+
16.20 Следствие вели... (S) 16+
19.00 «Центральное телевидение» (S)
20.20 Ты не поверишь! (S) 16+
21.20 «Секрет на миллион» (S) 16+
23.20 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном (S) 16+
00.10 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Дана Соколова (S) 16+
01.20 «Дачный ответ» (S) 0+
02.15 «Федор Конюхов. Тихоокеанский затворник» (S) 12+
02.55 «ГРЯЗНАЯ РАБОТА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «МОЯ ЛЮБИМАЯ МИШЕНЬ» 16+
09.55 «ИДЕАЛЬНЫЙ БРАК» 16+
18.45 «Скажи, подруга» 16+
19.00 «ЛЮБОВЬ МЕРЬЕМ» 16+
23.00 «Скажи, подруга» 16+
23.15 «СЛЕПОЙ ПОВОРОТ» 16+
03.05 «ИДЕАЛЬНЫЙ БРАК» 16+

ЗВЕЗДА

06.10 «ВАМ И НЕ СНИЛОСЬ...» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ НЕУЛОВИМЫХ» 12+
09.45 «Круиз-контроль» 12+
10.15 «Легенды цирка с Эдгардом Запашным». «Эквилибристы братья Варданян» 12+
10.45 «Улика из прошлого». «Тайны новых воровских пирамид». 16+
11.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Замужем за дьяволом: как сложились судьбы первых леди Третьего рейха» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
14.05, 17.20, 18.30, 00.10 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА» 12+
18.15 «Задело!» с Николаем Петровым. Информационно-аналитическая программа 16+
21.05 «Легендарные матчи» 12+
02.45 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
03.00 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+

12 декабрь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Яшик сөенеп кенә!» Рифат Зарипов концерты 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «ХАЙКЮ». Мультфильм 12+
09.00 «Полосатая зебра» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Динара Шәйдуллина 12+
11.00 «Бер язмыш – ике моң». Фәридә – Алсу дуэтының юбилей концерты. 2 нче бүлек 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Адымнар» 12+
13.30 Илсөя Бәдретдинова концерты 12+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Салават Юлаев». Прямая трансляция 6+
20.00, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12 +
23.00 «ЧЕЛОВЕК ИЗ ЧЕРНОЙ «ВОЛГИ» 12+
01.00 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 00.40 «Татарлар» 12+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Синең җырларыңны көйләп...» Әлфия Авзалованың туган көне уңаеннан 12+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Шәүкәт Галиев турында телеочерк 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.35 «ТУКРАН ТӘҮБӘСЕ». «Мунча ташы» татар эстрада театры спектакле 12+
17.00 «Нәсыйхәт» 6+
16.45 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
17.00 Хоккей. КХЛ чемпионаты. «Ак барс» (Казан) – «Салават Юлаев» (Уфа). Трансляция Казаннан 6+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.30 «Ком сәгате» 12+
22.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Шәүкәт Галиев турында телеочерк 6+
23.20 «Халкым минем» 12+
23.45 «Ком сәгате» 12+
01.05 «Манзара» 6+
02.50 «Сөю кабатланмый». Нәфкать Нигъмәтуллин концерты 12+
05.35 «Шаян хәлләр» 12+

1 КАНАЛ

04.40 «СЕМЕЙНЫЙ ДОМ» (S) 16+
06.00 Новости
06.10 «Семейный дом» (S) 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Непутевые заметки» 12+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Жизнь других» (S) 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
14.00 К 70-летию знаменитого путешественника. «Полюса недоступности Федора Конюхова» 12+
15.05 К юбилею Клуба Веселых и Находчивых. Премьера. «60 лучших» (S) 16+
17.35 «Две звезды. Отцы и дети» (S) 12+
19.25 Шоу Максима Галкина «Лучше всех!» Новый сезон (S) 0+
21.00 «Время»
22.00 «Что? Где? Когда?» Зимняя серия игр (S) 16+
23.10 Премьера. Легенды бокса в док. фильме «КОРОЛИ» (S) 16+
00.15 «ТУР ДЕ ФРАНС» 18+
02.05 «Наедине со всеми» 16+
02.50 «Модный приговор» 6+
03.40 «Давай поженимся!» 16+

РОССИЯ 1

05.20 «РОМАН В ПИСЬМАХ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Большая переделка»
12.30 «Парад юмора» 16+
14.20 «ТАНЕЦ ДЛЯ ДВОИХ» 12+
18.40 Премьера. «Всероссийский открытый телевизионный конкурс юных талантов «Синяя птица»
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 Премьера. «Россия. Новейшая история» 12+
01.00 «Воскресный вечер» 12+
03.10 «РОМАН В ПИСЬМАХ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Профессиональный бокс. Прямая трансляция из США
07.00, 09.00, 12.35, 22.35 Новости
07.05, 12.40, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05 «НОКАУТ» 16+
11.35 Профессиональный бокс. Василий Ломаченко против Ричарда Комми. Трансляция из США 16+
13.20 Биатлон. Кубок мира. Эстафета. Мужчины. Прямая трансляция из Австрии
15.15 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
15.45 Формула-1. Гран-при Абу-Даби. Прямая трансляция
18.00 Биатлон. Кубок мира. Гонка преследования. Женщины. Трансляция из Австрии 0+
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Краснодар» – «Нижний Новгород». Прямая трансляция
21.00 После футбола с Георгием Черданцевым
22.40 Футбол. Чемпионат Франции. ПСЖ – «Монако». Прямая трансляция
01.40 Сноубординг. Кубок мира. Параллельный слалом. Трансляция из Магнитогорска 0+
02.30 Формула-1. Гран-при Абу-Даби 0+
03.45 Бобслей и скелетон. Кубок мира. Трансляция из Германии 0+
04.30 Лыжный спорт. Кубок мира. Трансляция из Швейцарии 0+

НТВ

04.25 «НЕБЕСА ОБЕТОВАННЫЕ» 16+
06.35 «Центральное телевидение» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
13.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
14.00 «Фактор страха» (S) 12+
15.00 Своя игра (S) 0+
16.20 Следствие вели... (S) 16+
18.00 «Новые русские сенсации» (S) 16+
19.00 «Итоги недели»
20.10 «Суперстар! Возвращение». Новый сезон (S) 16+
22.45 «Звезды сошлись» (S) 16+
00.25 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
03.05 Их нравы 0+
03.25 «ГРЯЗНАЯ РАБОТА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «ПИСЬМО ПО ОШИБКЕ» 16+
10.30 «СЛЕПОЙ ПОВОРОТ» 16+
14.35 «САДОВНИЦА» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «МОЯ ЛЮБИМАЯ МИШЕНЬ» 16+
23.20 «Про здоровье» 16+
23.35 «ОПАСНЫЕ СВЯЗИ» 16+
03.20 «ИДЕАЛЬНЫЙ БРАК» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 16+
07.15 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы». «Альманах №81» 16+
11.30 «Секретные материалы». Док. сериал. «Сбежавшие от возмездия. Охота на «Ястребов» 16+
12.20 «Код доступа» 12+
13.15 «Война миров». Док. сериал. «Атомные секреты советских разведчиков» 16+
14.05 «ОПЕРАЦИЯ «ГОРГОНА» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.25 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
21.55 «85 лет ансамблю песни и пляски Воздушно-десантных войск». Праздничный концерт 12+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «ФАРТОВЫЙ» 16+
01.35 «СИЦИЛИАНСКАЯ ЗАЩИТА» 12+
03.00 «Вторая мировая война. Вспоминая блокадный Ленинград». Док. фильм 12+
03.25 «Стихия вооружений: воздух». Док. фильм 12+
03.55 «ОПЕРАЦИЯ «ГОРГОНА» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 6 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Ибраһим Сәлахов. «Колыма хикәяләре». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 7 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.20 «Вместе за безопасность»
18.30 Рәшит Ваһапов язмалары

Чәршәмбе, 8 декабрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
11.30 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Әхсән Баян шигырьләренә җырлар

Пәнҗешәмбе, 9 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Марсель Гыймазетдинов шигырьләренә җырлар

Җомга, 10 декабрь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр».
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Лирик концерт

Шимбә, 11 декабрь

8.10 «Кошлар кебек очып китәр идем...» Әхсән Баян әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». Фәнзаман Баттал хикәяләре

Якшәмбе, 12 декабрь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Зиннур Нурмөхәммәтов язмалары
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Рөстәм Миңгалим. «Кунак кызы гел килмәс». Әлмәт ТДДТ спектакленең радиоварианты

ЕРЫК АВЫЗ

Үтеп баручы – балыкчыга:
– Ничек, эләгәме?
– Эләгә, – дип җавап бирә балыкчы, кашын-күзен җимереп. – Берне тоткан идем, суга ыргыттым.
– Кечкенә булгандыр инде?
– Юк, гәүдәгә синең чамадарак, ләкин шулай ук бик бәйләнчек иде.

***

Петя белән Василий Иванович мунча керәләр. Такта стена артында – хатын-кызлар бүлеге. Василий Иванович ярыктан теге якны күзәтә:
– Анка юынып ята!
– Василий Иванович, мин дә карыйм әле!
– Йә, нәрсә күрәсең?
– Анка күзеннән кала бернәрсә дә юк.

***

– Владимир Ильич, состав килеп җитте!
– Һммм... Нәгсә инде ул составта?
– Казылык төяп килгәннәр, Владимир Ильич!
– Алай икән... Ничә ай килгән дидегез әле ул составны?
– Өч ай, Владимир Ильич!
– Ә, юк! Балалагга, багы тик балалагга!

pixabay.com

КУРКЫНЫЧ ЯЛ

ЧИТ ИЛГӘ БАРЫР АЛДЫННАН НӘРСӘГӘ ИГЪТИБАР ИТӘРГӘ?

Сәяхәт, ял итәргә теләүчеләрне авырулар да, бәла-казалар да, пандемия дә куркытмый. Ә бәла аяк астында гына. Ноябрь аенда гына да ял итәргә дип киткән берничә татарстанлының төрле сәбәпләр аркасында гомере өзелде. Доминиканада ковид белән авырып, хастаханәгә эләккән Рәмзия Шәрипованың җәсәден якыннарына әле дә булса алып кайта алмадылар. Чөнки әниләрен дәвалаган чит ил клиникасы зур суммада акча таләп итә. Мондый күңелсез хәлләргә юлыкмас өчен, сәяхәт итүче һәр турист нәрсәне белергә тиеш? Пандемия вакытында аеруча нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк? Белгечләр белән шул хакта сөйләштек.

«Төркиядә авырдык»

Арчада яшәүче Гөлдания һәм Илдус Каюмовлар октябрьдә Төркиягә ял итәргә барганнар. Әмма кайтырга берничә көн кала Гөлдания ханым, коронавирус белән авырып, хастаханәгә эләгә.

– Алты көн ял иткәч, Гөлдания авырый башлады. Без шунда ук отельдәге фельдшерга мөрәҗәгать иттек. Температураны үлчәгәч, ул «Ашыгыч ярдәм» чакырды. Тиз арада килеп җитеп, икебезне дә түләүле клиникага алып киттеләр. Анализлар алдылар. Тест хатынымның коронавирус белән авырганлыгын күрсәтте. Ике кешелек яхшы палатага урнаштырдылар. Мин икенче көнне клиникадан чыктым. Юллама вакыты төгәлләнгәч, Татарстанга кайтып киттем. Хатыным клиникада дәваланып калды. Миннән соң тагын егерме көн торды әле ул. Бик яхшы дәваладылар. Без канәгать калдык. Иң мөһиме, хатыным исән-имин өйгә кайтты, – диде Илдус Каюмов.

Ул үзе дә иминиятләштерү белән шөгыльләнә торган кеше буларак, барлык нечкәлекләрен белеп, аңлап эш иткән.

– Ялга китәр алдыннан үзебезне 40 мең еврога иминиятләштергән идек. Яхшы клиникага эләгүебезнең төп сәбәбе әнә шул булды. Безнең өчен иминиятләштерүдә «ковидтан дәвалау» пункты булу мөһим иде. Төркиягә килгәч, икенче көнне отельдә туристларны җыеп сөйләштеләр. «Иминиятләштерү килешүен кем укып чыкты?» – дигән сорау биргәч, бары тик мин генә кул күтәрдем. Димәк, башкалар килешүне укып та тормыйча кул куйган булып чыга. Бәла ул гел булып тормый. Ялга җыенганда да артын-алдын уйлап эш йөртергә кирәк, – ди Илдус Каюмов.

Туристик иминиятләштерү

Бәхеткә, Каюмовлар гаиләсе очрагында хәлләр уңай хәл ителгән. Тик килешүне яхшылап укымау яки суммасы чит илдә дәвалану өчен җитәрлек булмау аркасында, проблемалары белән ялгызы гына калучылар да шактый.

Ә дөньядагы вазгыятькә карамастан, сәяхәт итүчеләр саны кимеми. Туристик оешмада эшләүче Ләйсән Галимова сүзләренчә, юлламаларга сорау зур.

– Ял итәр өчен һава шартлары уңай булган илләргә халык барыбер оча. Әлеге вакытта бик күп турист Мисырда ял итә. Ноябрь ялларында юлламаларга ихтыяҗ 20–25 процентка артты, – ди ул. – Яңа ел каникулы вакытында да Мальдивта ял итәргә теләүчеләр бик күп. Билетлар күптән сатылып бетте инде.

Кызганыч, аның сүзләренчә, сәяхәт итәргә баручыларның бик азы гына өстәмә иминиятләштерүне сайлый.

Нәрсә соң ул туристик иминиятләштерү? Агент Чулпан Солтанова аңлатуынча, ул чит илдә яки Россиядә ял иткән вакытта көтелмәгән чыгымнарны каплар өчен кирәк. Полисны рәсмиләштергәндә һәр турист үз саулыгын чамаларга тиеш. Иминиятләштерүнең стандарт пакетына медицина һәм медицина-транспорт чыгымнары, ашыгыч стоматология ярдәме керә.

– Бөтен туристик страховкалар юлламалар минималь, стандарт страховканы үз эченә ала. Мәсәлән, пляжда егылу, аякны сындыру, агулану очракларында чыгымнар иминият компаниясе фондыннан каплана. Тулы исемлек килешүдә язылган була. Шуңа күрә аны җентекләп укып чыгарга киңәш итәбез. Авырып киткән, бәлагә юлыккан вакытта табиб отельдә ярдәм күрсәтә яки авыруны хастаханәгә алып бара. Чит илдә күпчелек клиникалар түләүле. Әгәр хастаханәгә эләгеп, иминиятләштерүгә кергән бәя җитми икән, клиникада дәвалануның калган өлешен туристка үз кесәсеннән түләргә туры киләчәк, – ди ул.

Иминиятләштерү полисына мөмкин булган өстәмә чыгымнарны да кертергә мөмкин. Мәсәлән, монда документларны югалткан яки урлаткан, юридик ярдәм алган, рейс тоткарлану вакытындагы чыгымнар керә. Турист шулай ук багажын, үзе булмаган чагында шәхси әйберләрен һәм милкен, гражданлык җаваплылыгын да иминиятләштерә ала.

– Халык иминиятләштерүгә салкын карый. Алар 100–200 мең сумга юллама ала, ә иминиятләштерү өчен 200–300 сум акчасын кызгана. Шәхси клиникаларга мөрәҗәгать итү күпкә кыйммәтрәккә төшә югыйсә. Юллама алучыларның 20–30 проценты полистан бөтенләй баш тарта. Үзенә берни дә булмас дип уйлый, – ди Чулпан Солтанова.

Хәзерге вазгыятьтә иминиятләштерү аеруча мөһим дип саный белгечләр. Соңгы яңалыклардан билгеле булганча, хәзер минималь пакетка ковидтан авырган очракларны да кертә башладылар.

– Чөнки ковид дөнья буйлап бик тиз тарала һәм туристик компанияләр авырудан иминиятләштерүне кертергә кирәк дигән карарга килде, – ди Чулпан Солтанова. – Пандемия күп кешеләрне үз сәламәтлекләренә һәм шуңа бәйле финанс иминлегенә сак карарга өйрәтте. Авырган очракта берникадәр вакыт эшкә чыгып булмаячак. Терелгәч тә, күпләр хәлсезлектән зарлана. Эш бирүче аларны аңлармы? Авырганнан соң бар көчен биреп эшли алырмы? Кеше үз-үзләренә әнә шул сорауларны биреп, сәламәтлеген иминиятләштерү турында уйлый башлады.

Туристик компанияләрдә эшләүче белгечләр әйтүенчә, иминиятләштерү арзанга яки кыйммәткә бүленми. Монда төп хикмәт – дәвалануга киткән чыгымнарны каплау бәясе.

– Иминиятләштерү өчен никадәр күбрәк түләсәң, дәваланганда акчасын да күбрәк алачаксың. Стандарт пакетка гына кергән сумма дәвалануга тотылган чыгымнарны каплауга җитәрме? Ял итәргә баручы туристларны әнә шул сорау борчырга тиеш. Ләкин, кызганыч, кешеләр еш кына бу турыда уйламый. Миңа берни булмас, дип фикер йөртә, – ди туристик оешма директоры Рамазан Сабиров.

Барганчы кайтуыңны уйла

Шуңа күрә белгечләр бүгенге кебек тынгысыз вакытта гадәти, стандарт турпакетны түгел, ә киңәйтелгән иминиятләштерүне сайларга киңәш итә.

– Әгәр беренчесе 30–40 мең долларга исәпләнсә, икенчесе 100 меңгә кадәр булган чыгымнарны каплый. 300–400 мең долларлык дәвалану алырга мөмкинлек бирә торганнары да бар, – ди Чулпан Солтанова. – Мондый иминиятләштерү күпкә кыйммәт дип әйтеп булмый, аның каравы, көтелмәгән хәл килеп чыга калса, күңелең тыныч була. Шулай ук иминиятләштерүнең аерым төрләре турында да уйларга мөмкин. Мәсәлән, күпләр Мисырга дайвинг белән шөгыльләнер өчен бара. Бу очракта спорт иминиятләштерүе уңышлы булачак. Дөнья хәлен белеп булмый бит.

Татарстанның туризм агентлыклары ассоциациясе президенты Рамил Мифтахов исә хәзерге вазгыятьтә прививка ясатмыйча ялга баруны җавапсызлык дип бәяли.

– Хәзер туристлар өчен иң авыр карар: ял итәргә барып, үзеңне куркыныч астына куяргамы, әллә өйдә генә калыргамы? Чөнки күпләр турларны ярты – бер ел алдан алып куя. Ә безнең халыкка ял итәр өчен акчаны туплау җиңел түгел. Һәм аларның 100–200 мең сумнарыннан болай гына колак кагасы килми. Мин исә бу очракта киңәйтелгән медицина иминиятләштерүен сайларга киңәш итәм. Гадәттә аның бәясе бер көнгә 150–160 сум. Зур сумма түгел, ләкин ул сезне җитди проблемалардан саклап калырга мөмкин. Чит илдә сез акчасыз беркемгә дә кирәк түгел. Ә ковидны дәвалау башка илләрдә бик кыйммәткә чыга. Консуллыклар да, башка ил хөкүмәте дә мәрхүмнең җәсәден туган ягына бушлай кайтармаячак. Бу – бик катлаулы һәм кыйммәтле эш.

Зөһрә САДЫЙКОВА

СӘЯХӘТ ВАКЫТЫНДА БӘЛА-КАЗАГА ЮЛЫККАН ОЧРАКТА НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ?

Беренче чиратта иминиятләштерү полисында күрсәтелгән телефонга шалтыратырга кирәк. Аңа бәлагә юлыккан кешенең туганы, якыны да мөрәҗәгать итә ала. Бу эшне медицина оешмасына эләккәнче үк эшләргә кирәк. Ял итүченең исем-фамилиясен, полис номерын, телефонын хәбәр итәргә һәм кирәкле ярдәмне тасвирлап бирергә кирәк.

Шулай ук иминиятләштерү компанияләрен сайлауга да зур әһәмият бирергә кирәк. Бу базарда озак эшли торган, ышанычлы оешмаларны карагыз. Һәм кул куйганчы, килешүне бик җентекләп укыгыз.

ФӘРИТ ӘЮПОВ:

«БЕР ЦЕНТНЕР АВЫРЛЫК БИК ХӘТӘР ИКӘН»

Фәрит ӘЮПОВ белән укучыларыбыз яхшы таныш. Ул, турист буларак, космоска очарга җыена. Әзерлек эшләре инде күптән башланган, чират килеп җиткәнен генә көтә. Әмма бүген сүзебез ул хакта түгел. Фәрит, беренче тапкыр редакциягә килгәч, үзенең берничә ел элек төшкән фотосын күрсәтеп, безне шаккатырган иде. Авырлыгы бер центнердан артык зур бәдәнле бу кешенең канәгатьсезлек халәте чыраена да чыккан. Хәзер исә эшмәкәр егетебез бөтенләй башка, күз тимәсен, ыспай гәүдәле, тешләрен җемелдәтеп, елмаеп кына тора. «Космоска очар өчен җиңеллек кирәк бит. Ракетага авыр булмасын дип шулай тырыштым инде», – дип шаярта үзе. Аннан җитдирәк сүзгә күчәбез.

– Бер центнер авырлык бик хәтәр икән. Ул вакытларны искә төшерәсем дә килми. Авырлык арткан саен, сәламәтлек тә югала: бертуктаусыз тирләтә, кызурак барсаң, шундук хәл бетә, сулыш алу кыенлаша. Беркөнне шулай көзгегә карадым да: «Җитте, Фәрит», – дидем. Ярдәме тиде. Дөресен генә әйткәндә, шулай иңнәремдә бер центнерны «күтәреп» йөргәндә, бер танышымны очраттым. Замандында көчкә селкенә иде, ябыккан бу, йөгереп кенә йөри. Баштарак, әллә авырып киттеме икән, дигән уй да килде хәтта. Тик кызарып-алсуланып торган йөзен, җитез хәрәкәтләрен күргәч, бу уемнан кире кайттым. Менә шунда үз-үзеңне кулга алып буласына чын күңелдән ышандым.

:: Шулай да 30 килограммнан артык авырлыкны ташлау җиңел генә бирелмәгәндер?

– Морадыңа ирешү өчен теләсә нәрсәне гадәткә кертергә генә кирәк икән. Мин шуны аңладым. Әлбәттә, моның өчен 2–3 көн генә җитми. Мәсәлән, без ел саен ураза тотуны гадәткә кертәбез бит. Баштагы көннәрдә кыен кебек, аннан ияләнәбез. Хәтта рәхәтрәк тә булып киткән кебек. Ашауны тәртипкә салу да нәкъ шулай. Кыскасы, ябыгырга теләсәң, калорияне киметү дә җитә. Кеше тәүлегенә уртача 2500 килокалория «яндыра». Организмдагы энергия мускулларны эшләтү өчен генә түгел, эчке әгъзаларның эшләвен тәэмин итү һәм ризыкны үзләштерү өчен дә кирәк. Кайсы ризыкның күпме калория биргәнен белү кыен түгел. Интернетта хәзер әллә нинди кушымталар бар.

:: Булачак космонавтның көнениләр ашап үтә?

– Белгечләр санап чыгарганча, кеше көн саен үз тәненең һәр килограммына 30 миллилитр исәбеннән фильтрланган, кайнатылмаган су эчәргә тиеш (ашарга ярты сәгать кала, ашаганнан соң 1,5 сәгать үткәч). Моңа шулай ук шулпа, җиләк-җимеш, яшелчәдәге сулар да керә. Мин дә һәр иртәмне шулай башлыйм: ашарга ярты сәгать кала 2 стакан су эчәм. Бераз вакыт үткәч, сөт салып, каһвә эчеп куям. Үлән чәйләре дә бик әйбәт. Беркайчан да иртәнге аштан баш тартмыйм. Иртәнгесе – үзеңә, көндезгесе – күршеңә, кичкесе – дошманыңа, дип юкка гына әйтмиләр. Иртә белән ашамасаң, кичен нык итеп ашарга туры килә, чөнки организм барыбер үзенекен таләп итә. Талымласам, төшке ашка кадәр алма ашап куям, я берәр стакан чәй эчәм. Ашыйсы килүдән интегеп йөрергә ярамый. Әбәт вакытында яшелчәләрдән салат, майлы булмаган иттән (тавык яки күркәнеке) пешерелгән аш ашыйм. Яшелчә ашы, борщ булса, бигрәк тә әйбәт. Төрле яшелчә туралган, үсемлек мае салынган салат әзерлим. Кичкә исә суган белән пешерелгән карабодай боткасын үз итәм. Тамак туймаган кебек булса, тавык, күркә ите, балык капкалап алырга мөмкин. Кичке ашка кадәр кефир, бал һәм чикләвекләр белән чәй эчеп куйгаласаң да, кичке сәгать 6дан соң ашау-эчү мәшәкатьләре онытылырга тиеш. Соң ашаган азык майга гына китә.

:: Өстәл яныннан киткәндә тамагыгыз туйган буламы? Әллә инде күзегез гел эзләнәме?

– Мондый хәл килеп чыкмасын өчен ашны гадәттә эче тирән булмаган зур тәлинкәгә салып ашагыз. Халыкта күз туймады дигән төшенчә бар шул. Монысы шуның өчен кирәк. Башта азыкка карап торырга, дога укып алырга мөмкин. Аннан акрын гына ашыйбыз. Монысы ни өчен кирәк дисезме? Баш миенә туйганны белгертә торган сигнал, ашый башлагач та, 20 минуттан соң гына барып җитә. Димәк, тиз-тиз ашасак, өстәл яныннан туймыйча киткән кебек хис калырга мөмкин. Акрын ашасак исә, сигналлар килә башлый, димәк, табыннан без туеп китәбез. Шуңа күрә Европа халкы вакытны уздыру өчен табында гәпләшеп утырырга ярата да инде.

:: Күпме калория биргәнен дөрес исәпләгәндә, теләсә нинди ризыкны ашарга мөмкин, дидегез...

– Күңел теләгәндә капкалап кую зыян итми. Берәр ризык турында, их, кабып карыйсы иде, дип уфтанып йөрү һич кенә дә дөрес түгел. Тазарта торганнарыннан тора-бара арынырга гына, ягъни аларны ашамауны гадәткә кертергә кирәк. Бу хакта барыбыз да беләбез кебек, әмма үтәмибез генә. Әлеге исемлеккә чүпрәле камырдан пешерелгән, майлы ризыклар керә. Кара икмәккә генә күчү күпкә отышлырак. Терлек маен тора-бара үсемлекнекенә алыштыра барасың. Шундый ризыкларның тагын берсе – шикәр. Белгечләр әйтүенчә, кеше өчен көндәлек норма – 40 грамм. Моңа, әлбәттә инде, җиләк-җимештәге, башка продуктлардагы шикәр дә керә. Ә статистик мәгълүматлар буенча, без шикәрне ике тапкыр артыграк, көненә 70 грамм кулланабыз икән. Баллы әйберләрне чамасын белеп ашау шикәр диабеты авыруларын да кимәтә алыр иде. Тозга да бик игътибарлы булырга кирәк. Организм өчен көненә бер чәй кашыгы, ягъни 7 грамм җитә. Ә без аны да 2 тапкыр артык кулланабыз.

:: Теләсә нинди ризыкны ашарга ярый дисәгез дә, үзегез ит ашамыйсыз бугай, ягъни вегетариан тормышы алып барасыз...

– Әйе, 6 ел инде. Элек бер ел веган булып та алдым, ягъни сөт продуктлары да ашамадым, аксымны бөтенләй кулланмадым. Иткә килгәндә, чыннан да, кызыл итнең файдасын күрмим. Майлы ризыкны үзләштерү өчен энергиянең 70 проценты сарыф ителә. Аңлашыла ки, җиңел азыклар өчен энергия дә азрак, 20 процент тирәсе генә китә. Димәк, азыкны дөрес кулланcак, безгә инде көненә 1000–1500 килокалория дә җитә дигән сүз. Шулай булгач, организмны нигә дип «азапларга» ди әле? Бу галимнәр күзлегеннән караганда да дөрес. Организмдагы күзәнәкләр билгеле бер санда яңадан туугa программалаштырылган. Җиңел эшкәртелә торган азык ашаганда, әлеге цикл уртача 15 елдан артыкка озыная. Димәк, гомер дә озыная дигән сүз. Бу кан басымы күтәрелү, йөрәк өянәге, ашказаны җәрәхәте кебек күп кенә авыруларның булмый калуына бәйле. Авыр эшкәртелә торган ризыктан исә организмда шлаклар күп кала, бу төрле авырулар килеп чыгуга сәбәп булып тора.

:: Булачак космонавтның сәламәтлеген гел күзәтеп торалар дип беләм. Физик яктан чыныгу дигәндә, нәрсәгә игътибар итәсез?

– Хәзер күп кеше кабинетларда утыра, транспортта йөри, өйгә кайткач, диванга кырын ятып телевизор карый. Шуның белән сәламәтлеген бетерә дә инде. Кан йөрешен яхшырту өчен кимендә 10 мең адым җәяү йөрим, 30 минут актив хәрәкәт итәргә тырышам. Моны һәркем булдыра ала, вакыт юкка сылтыйсы түгел, гадәткә генә кертәсе. Авырлыкны китмәтү өчен спортзалда шөгыльләнүне дөрес дип тапмыйм. Монысы гәүдәне формада тоту өчен кирәк. Ә калорияне яндыру өчен дип, тренажерларда тир чыгарырга тырышу сәламәтлеккә зыян китерергә генә мөмкин. Эшкә җәяү барып кайтсаң, әбәт вакытында паркта, урамда йөреп керсәң, күпкә яхшырак.

Тагын бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк дип уйлыйм: кеше сөенечкә – шатлана, көенечкә кайгыра белергә тиеш. Авыр чакта елап алу да комачауламас. Нәрсәнедер искә төшереп, кемнендер әйткән сүзенә ямансулап, эчеңдә хис өере тоту бер дә дөрес түгел, мондый халәт организмны җимерә. Кеше күбрәк елмайса, көлсә, организмда спазмнар сирәгрәк була.

Безнең илдә хатын-кызлар уртача – 73, ир-атлар 68 яшькә кадәр яши. Кавказ якларында, Европа илләрендә гомер озынлыгы шактый озынрак. Ә бит барысы да шушы гап-гади кагыйдәләргә нигезләнеп яшәүгә бәйле. Татарлар – бик тырыш, эшчән халык, әмма гомер озынлыгы мактанырлык түгел. Әби-бабайларыбыз дарулар урынына үләннәр кулланганнар. Безгә бу хакта да онытырга ярамый. Минем үз әбием дә 17 бала үстереп, 98гә җитеп үлде. Рәхәт тормыштан түгел, шул табигатькә якын булудан бит инде бу.

:: Өегездә хәлләр ничек? Төрле тыюлар кертеп интектермисезме?

– Бернинди тыюлар да юк. Һәркем теләгән ризыгын ашый. Дөрес, кызыл ит белән колбасаны өйдә күптән күргәнем юк. Әмма бу мин куйган шарт түгел. Хәтта биш яшьлек кызыбыз Асия дә тавык яки күркә ите генә ашау ягында. Аның организмы да шундый ризыкка күнеккән инде.

:: Коронавирус чорында яшәү рәвешенә үзгәрешләр кертмәдегезме?

– Бу авыруга каршы тору өчен иммунитетның нык булуы кирәк. Организмыбызны тыңлый белсәк, үзебезне саклап кала алыр идек. Әйе, прививка ясаттык. Ашау-эчүгә дә күбрәк игътибар итә башладык. Иртән торгач, аз-азлап кына бүртерелгән бодай, солы ашыйбыз. Моның өчен бөртеклеләрнең язын утыртылганы кирәк, бүртергәндә мыекчалары ярты сантиметрдан артмаска тиеш.

:: Иң яратып ашаган салатыгыз?

– Сез, бәлки, әллә ниләр ишетермен дип уйлыйсыздыр инде. Кәбестә салатын яратам мин. Азрак уксус, тоз, үсемлек мае салып болгатасың да, шуның белән эше бетә. Бик тәмле, ә файдасын әйтеп бетерә торган түгел.

:: Әллә ниләр димәктән, мин, чыннан да, берсеннән-берсе хәтәррәк диеталар, күз күрмәгән рецептлар ишетермен дип уйлаган идем...

– Бернинди диеталар белән дә баш ватасы түгел. Гадәткә кертсәң, организм ул азыкны үзе «сорап» ала, ошатмаса, башкасын эзли башлый. Шуңа күрә үзеңне нидер ашаудан чикләргә дә ярамый. Тик чамасын белергә генә кирәк. Иң мөһиме, синең һәр гамәлең, шул исәптән ашап-эчүең дә канәгатьлек китерергә тиеш.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КИРТӘЛӘРСЕЗ ТОРМЫШ

Аларга җылы сүз, ярату, игътибар көн дә кирәк! Үзләрен инвалид дигәнне яратмыйлар. Физик мөмкинлеге чикләнгән дигән сүз белән дә килешеп бетмиләр. Чөнки каршылыкларны җиңеп, чикләрне узып яшәргә тырышалар. Аралаша торгач, аларның күңелләренең ихлас, йөрәкләренең зур икәнен аңлыйсың. Сынау артыннан сынау узып, үзләре генә түгел, башкаларны да сәламәтлекнең, гомумән, булганның кадерен белергә өйрәтәләр.

Алты кызлы өйнең кояшы

Теләк булса, чикләр юк. Үзеңне яратып, ничек бар – шулай кабул итеп яшәргә өйрәнсәң, тормыш рәхәт. Иң мөһиме – янәшәңдә иңен куяр кешең булсын! Арчада яшәүче Алсинә Кәлимуллина әнә шулай ди. Аңлаучы, яклаучы эзләп әллә кая барасы түгел аңа. 4 апасы, 1 сеңлесе бар аның. Әтисе Әнвәр белән әнисе Люция кызларның һәрберсе бәхетле булсын өчен бар көчен куя.

Алсинә турында без апасы Лиана белән сөйләштек.

– Табиблар куйган диагнозны искә алмасаң, сеңлебезнең бер кимчелеген дә күрмибез. Ул безнең гаиләгә бәхет өләшер өчен туган. Апаларыбыз Лилия, Гөлия, Гөлүсә кияүдә. Үз тормышлары белән яшиләр. Мин Арча гуманитар техникумында укыйм, Алсинә Яңа Кенәрдәге физик мөмкинлекләре чикләнгән мәктәп-интернатта белем ала, кечкенә сеңлебез Әлфинәгә 11 яшь. Күп булуыбыз безне татулыкка, бердәмлеккә өйрәтте. Беребезне беребез карап үсеп җиткәнебезне сизми дә калдык, – ди Лиана.

Әти-әнисе Алсинәне кечкенәдән тернәкләндерү үзәкләренә йөртә. «Исток надежды» үзәгенә йөри башлагач, кыз биюгә өйрәнгән.

Шулай итеп, Алсинә каушаудан, оялудан туктый, үзен иркен тота башлый. Бәйгеләрдә еш катнаша, 2018 елда «Ломая барьеры» фестивалендә җиңү яулый. Үзен күргәнне, белгәнне тойгач, Алсинә бу шөгыленә тагын да ныклап тотына.

– Әле ул «Абилимпикс» бәйгесендә дә җиңүләр яулый. 2019 елда беренче тапкыр катнашып, призлы урын алды. Быел да «Инә белән бәйләү» номинациясендә өченче урын яулады, – ди Лиана.

Бәйләү дигәннән, Кәлимуллиннар гаиләсендәге һәр кыз да кул эшенә оста. Кечерәкләре олыраклардан күреп, узыша-узыша бәйли алар. Әниләре оста бәйләүче икән.

Алсинә 9 нчы сыйныфны тәмамлагач, Арчаның төзелеш көллиятенә укырга керергә җыена.

– Сеңлемә күзләр тимәсен. Кайда булса да, үз сәләтен күрсәтә белә. Без аңа карап сокланабыз. Күңел төшкән вакытларда да аннан көч алабыз. Ул безнең өйне җылытыр өчен туган. Гаиләбезнең якты кояшы ул, – ди апасы Лиана.

«Оялып, биш ел өйдән чыкмадым»

Моннан 21 ел элек булган әлеге вакыйга Альберт Җаббаровның тормышын икегә бүлә. Янгын сүндерү станциясенә эшкә урнашкан егет спорт ярышлары вакытында 9 метр биеклектән егылып төшә. Егетнең умыртка баганасы сына. Баштарак үзенә бу хакта әйтмиләр. Аягына басар, дия-дия өч операция ясыйлар. Ярты елдан артык вакыт хастаханәдә үтә. Ахыр чиктә, язмыш сынавын кабул итәргә, яңача яшәргә өйрәнергә туры килә.

– «Син башка йөри алмаячаксың» дигән сүзне ишетү авыр булды. Үз эчемә бикләндем. Янымда бер дустым да калмады. Алар миннән түгел, мин алардан читләштем, – ди Чаллыда яшәүче 38 яшьлек ир-ат. – Биш ел буе урамга чыгарга оялдым. Күз алдына китерәсезме: көн буе өйдә утырам, урамга кеше йөрми башлагач, төн уртасында гына алып чыгалар. Шифаханәләргә йөреп читенсенмәскә өйрәндем.

Язмыш сынавын кабул иткән Альберт әкренләп спортка тартыла. Арбада биергә өйрәнә, баскетбол уйный башлый. Гел хәрәкәттә Альберт, машина да йөртә. Шуның аркасында үзенә яр да таба. Моннан 11 ел элек кул белән йөртү буенча киңәш сорап, Зөлфия исемле кыз яза аңа.

– Башкортстан кызы ул. Тумыштан ДЦП диагнозы бар, аяклары начар йөри. Интернет аша танышып, 4 ел буе дус булып йөрдек тә, бер-беребезгә кирәк икәнне аңлагач, 2014 елда өйләнештек. Зөлфиянең гаиләсе мине бик якын итте. Әти-әнием дә өйләнүемә каршы булмады. Аллага шөкер, матур гына гомер итәбез. Икәү булгач, җиңел инде. Янәшәңдә якын кешең булу кирәк. Безгә бигрәк тә, – ди ул.

Алар икәү генә, аерым фатирда яшиләр. Тормышка җайлашканнар инде. Дөрес, Зөлфия машина йөртергә өйрәнә алмаган барыбер. Ире янына утырып кына йөри икән.

– Һәр кешегә тиңе кирәк. Мин дә Зөлфияне очратуыма чиксез бәхетле. Кайчандыр үзем эчемә бикләнеп, урамга да чыкмыйча утырган кеше бит мин. Ә хәзер күпме дусларым бар. Тормышны яратып яшим, – ди ул. Бар нәрсәгә өйрәнергә була. Тормышта үз гаебе аркасында урын таба алмыйча йөргән сау-сәламәт ир-егетләрдән күпкә бәхетлерәк мин.

ИГЪТИБАРНЫ КЫЗГАНМЫЙК!

3 декабрьдә Халыкара инвалидлар көне билгеләп үтелә. Бу уңайдан Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова республикада яшәүчеләргә мөрәҗәгать итте.

«Татарстанда бүген мөмкинлеге чикле 289,1 мең кеше яши, шуның 16,5 меңе – балалар. Төп бурычларның берсе – аларга төрле өлкәләрдә ярдәм итү, үз потенциалларын тулысынча гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирү», – ди Эльмира Зарипова. Моның өчен дәүләт дәрәҗәсендә «Уңайлы мохит» программасы тормышка ашырыла. «Демография» илкүләм проекты да инвалид кешеләрнең проблемаларын хәл итүне күздә тота. «Өлкән буын» федераль проекты барлык районнарда гамәлдә. Татарстанда инклюзив белем бирү алымы тормышка ашырыла, мөмкинлеге чикле кешеләр өчен махсус эш урыннары булдырыла һәм җиһазландырыла. Республикада мондый кешеләрнең тулы канлы тормышы һәм социальләшүе өчен шартлар тудыру максатыннан, төрле чаралар үткәрелә. «Инвалидлар декадасында республикада яшәүче һәркемнең моңа мохтаҗ кешеләргә карата мәрхәмәт һәм миһербанлылык, игътибар һәм кайгыртучанлык күрсәтәчәгенә чын күңелдән ышанасы килә. Дөньяны һәркем өчен дә тигез, сәламәтлекләре ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен уңайлы һәм куркынычсыз итү – безнең кулларда һәм көчебездә», – диелә министр мөрәҗәгатендә.

Бала хакына – бакча

Казанда яшәүче Илья Школьников балалар бакчасы төзи башлаган. Авыр хәлдәге сабыйларга гына түгел, аларның әти-әниләренә дә ярдәм итү аның нияте.

Туганда тупырдап торган сабыйның соңрак башкалар кебек булмаганын күреп, әти-әнисе кая гына алып бармый! Табиблар башта төгәл генә берни әйтә алмый, ә аннары малайның физик һәм акыл үсеше туктап калганлыгы ачыклана. Нишләмәк кирәк, бергәләп көрәшергә, җайлашырга туры килә.

Константин үсә төшкәч, аны бакчага урнаштырасы килә Ильяның. Аңлашыла инде, махсус бакча эзлиләр. Белешә торгач, Казан түгел, хәтта Россиядә дә мондый диагнозлы сабыйлар өчен бакча булмавы ачыклана. Нишли дисез Ильяны? Бакчаны үзе төзергә карар кыла ул!

– Мин бу хыял турында Казан мэриясенә җиткердем. Алар миңа бина бирде. Әкренләп төзекләндерү эшләрен башладым. Кем генә булышмады! – ди Илья.

«Все сам» дип аталачак бакчаны Яңа ел бәйрәменә ачарга хыялланганнар. Әмма пандемия аркасында эшләре тукталып торган, үзе дә авырып алган. Башкарасы эш аз түгел әле.

– Авыру бала үстерү җиңел түгел. Аеруча әниләргә кыен. Әле бит бала авыру туса, ирләр китү ягын карый. Ир белән хатын арасында җылылык югала. Аларның бергә булырга, бераз ял итәргә хаклары бар. Безнең бакча әнә шул якны да кайгыртачак. Сабыйларны бездә калдырып тору әти-әнигә ял бирәчәк. Җәйге каникул вакытларында бакчаны тәүлек буе эшләтер идек. Әлеге уем чынга ашса, авыру баланың әти-әнисе, каядыр барып, ял да итеп кайта алыр иде, – ди ул. – Бакчага йөрүче сабыйларның авыр хәлдәгеләре үзләре утырырга, кулына кашык тотарга өйрәнсә дә яхшы булыр иде. Максатыбыз – андый балаларны гадәти мәктәпкә барырлык итү. Миндә хыяллар күп, шөкер, көчем дә бар. Тик бар да акчага килеп терәлә. Уйламаган җирдән ярдәм булыр, без, бакчаны ачып, болай итеп яшәп булганын күрсәтербез.



Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ЮЛ ЧАТЫНДА КАЛГАНДА...

«ЮЛ ЧАТЫНДА» ӘСӘРЕНӘ ШТРИХЛАР

Язучының тормышы белән якыннанрак танышкач, аның әсәрләренә дә караш үзгәрә. Сиңа эзоп теле белән язылганы да аңлашыларак төшә, геройларның мөгамәләсен дә яхшырак аңлый башлыйсың. Язучы Адлер Тимергалинның балалары, туганнары, аның иҗатын өйрәнгән белгечләр белән очрашкач, әнә шундый хисләр кичердек. «Бөекләр эзеннән» атлап киткәндә, без «Юл чатында» әсәрен юлдаш итеп алдык. Әлеге әсәр ярдәмендә «Татар әдәбиятында ни өчен фантастика жанры юкка чыгып бара?» дигән сорауга җавап таптык кебек. Әсәрнең исеме дә хәзерге халәтебезгә бик туры килә бит.

Рәссам **Алсу Тимергалина** белән аның остаханәсендә очраштык. Картиналар, балчык эшләнмәләрнең күбесендә тарих чагыла. Иң түрдә – әтисе Адлер абыйның портреты. Бөркет аңа вакыт тәрәзәсеннән борынгы китаплар алып чыга. Баксаң, Адлер исеме үзе үк немецчадан бөркет дигәнне аңлата икән.

– Мин – фантастика укып үскән бала. Клиффорд Саймак, Рэй Бредбери, Айзек Азимовларның виртуаль дөнья, роботлар турындагы әсәрләрен шулкадәр кызыксынып укыдым, – ди Алсу ханым. – Кырык-илле ел үтте, ул китапларда сурәтләнгән күп күренешләр безнең тормышыбызга үтеп керде. Кызганыч, тормыш үзгәрде һәм фантастика жанры урынына фентези дигәне килде. Бусы инде күбрәк сурәтләүгә кайтып кала. Фәнни фантастика заманнан бер адымга алга бара торган әсәрләр булса, фентези, кызганыч, эзләнүләргә этәрми.

Әтинең әсәрләре дә бит кешене эзләнүләргә этәрүе белән кыйммәтле. Алар шул яктан да миңа кадерле. «Юл чаты» дигән әсәре дәвердән дәвергә күчү турында. Күрәсең, әти вакыт машиналары, дәвердән дәвергә күчү ысуллары белән бик кызыксынган. Анда ХХ гасыр кешесе Болгар ханлыгына эләгә. Әсәрдә прототиплар да шәйләнә. Тынгысыз Бәйрәшева образы белән чынбарлык прототибы арасында аерма бик аз, мәсәлән.

Мин әтинең абруйлы, дәрәҗәле кеше булуын тоеп, күреп үстем. Казан сәнгать училищесын тәмамлап, Татар китап нәшриятына килгәндә дә җиңел булды. Әтине барысы да яхшы белә, аның исемен әйтсәң дә, ишекләр ачыла кебек иде. Миңа эшләр бирә башладылар, тышлыклар ясадым. Тик язучы баласы булуның үз кысалары бар. Әтиең дәрәҗәле икән, син дә аның баласы булуыңны расларга тиеш. Бу – үз өстеңдә эшләү, әдәпле булу дигән сүз. Әти минем өчен һәрвакыт зур кеше булды. Бәлкем, аның дипломнары, премияләре җитеп бетмидер, аңа карап кына ул зур галим булудан туктамады.

Әтине кырыс дип әйтә алмыйм, әмма русча сөйләшкәнне яратмады, гел кисәтеп торды. Аның никадәр хаклы булуын олыгайгач кына аңлыйсың. Хәзер әтигә телне яраттырганы өчен рәхмәтемне укыйм. Планетарийга йөрткәне, астрономия, физика фәннәренә төшендергәне өчен рәхмәт. Кызганыч, бу юнәлештә укып бетерә алмаган, югары белем алу мөмкинлеге булса, зур галим булыр иде. Әсәрләрендә дә бит күбрәк фәнни якка басым ясый ул.

Язучының улы **Рөстәм Тимергалин** әтисе белән әнисе вафатыннан соң гына очраша. Миңа әтине белергә вакыт бик аз бирелде, ди ул. Әтисенең әсәрләрен өйрәнү өчен бер эшеннән китәргә җыенуы турында да сөйләде. Без исә аның әтисенә ике тамчы су кебек охшаш булуына таң калдык. Менә нәрсәләр сөйләде ул безгә:

– Шулай килеп чыккан инде... Тууын мин Казанда туганмын. Тик әти белән әни бергә озак яшәмәгәннәр. Миңа бер яшьләр тирәсе булганда, без әни белән Әгерҗегә кайтып киткәнбез. Әти белән әни аерылышканнар. Кечкенә чагымда әтием барлыгын бөтенләй белмәдем. Беренче сыйныфта укыганда гына әни барысын да сөйләп бирде. Моңа әллә ни игътибар итмәдем. Чөнки ул чакта инде үги әти белән яши идек. 1984 елда әни озак авырудан соң бакыйлыкка күчте. Ул миңа әти белән очрашуны әманәт итеп әйтеп калдырды.

> Адлер **ТИМЕРГАЛИН:**
>
> Кешеләрне кызганам. Бик еш гафу итәм. Кайберәүләр моннан файдаланалар да. Туры әйтергә яратсам да, кеше күңеленә артык бәрелмәскә тырышам бугай.
> Халык арасына чумып, күренмичә йөрүне артык күрәм шикелле. Мин «серая» масса эчендә...

1985 елда мине абый Казанга, әти янына кунакка алып барды. Фатирга килеп кергәч, бөтен диварларның уң яктан да, сул яктан да китаплар белән тулганына игътибар иттем. Мин ят җирдә бик оялдым, әллә ни сөйләшмәдем дә, әти белән күбрәк абый сөйләште. Аннан хатлар алыша башладык. Әти миңа китаплар сала иде. Радио белән мавыкканга, детальләр дә җибәрде. Алардан тавыш көчәйткечләр, ут яктырткычлар ясадым. Бу мавыгулар әтидән күчкәндер дип уйлыйм.

Каникулларда аңа бара идем. Ул мине планетарийга, Казан елга портына, Кремльгә алып барды. Мин бит – дөнья күрмәгән авыл малае, барысы да кызык тоелды.

Мәктәпне тәмамлагач, КАИга укырга кердем. Әлбәттә, әти ярдәме белән. Яшәвен дә аңарда яшәдем. Янында гыйлемле кеше һәм шундый китапханә булгач, бөтен сорауларга җавап табыла иде. Уку буенча да, тормыш буенча да.

Институтны тәмамлагач, Әгерҗегә кайтып киттем, монда минем бизнес җайланып китте, әмма әти янына барып йөри идем. Тора-бара кешеләр килеп, миннән аның китапларын сорый башлады. Башта кечкенә генә шәһәрдә «Милләт сүзлеге»н, ике томлыгын сорауларына гаҗәпләндем. Китапларны алып кайта һәм тарата яки арзанга гына сатып бирә башладым.

Халыкның Адлер Тимергалин әсәрләрен яратуының хикмәте, бәлки, аның гадилегендәдер дә. Әйтик, үзе исән чакта якташлары – сарманлыларны, бигрәк тә Минзәләбаш авылы кешеләрен ярдәменнән ташламаган ул. Туганы, Н.И.Лобачевский исемендәге лицейның татар теле укытучысы **Долорес Малмыгина** сөйләвенчә, авыл егетләренә КАИга укырга керергә ярдәм иткән, укулары белән кызыксынып торган:

– Гаиләдә алар җиде бала була. Шул балалардан өч кыз белән бер малай гына исән калган. Адлер абый яшьтән бик акыллы булган, апаларының дәреслекләрен, бигрәк тә астрономияне җәйге каникулларда укып бетерүен әле дә сөйлиләр. Адлер абый игътибарлы, кешелекле иде. Гыйлем иясе булса, беркайчан да үзен өстен куймады, бусагасыннан кем генә атлап керсә дә, ярдәм итүдән баш тартмады. Ул укытып чыгарган кешеләр авылда хәзер дә бар әле.

Шагыйрь, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире **Газинур Морат** исә аның биографиясенә һәм әсәрләренең үзенчәлекләренә тукталды:

– Адлер абый белән күрешеп сөйләшеп утырырга туры килмәде. Миңа калса, ул үзе дә кешеләр белән очрашуларга атлыгып тормагандыр. Һәрхәлдә, замандашлары, якыннан белгән кешеләр шулай ди. Аның бик тә җитди сәбәбе бар. Адлер абый – аздан гына Сталинның җәллад балтасына эләкми калган кеше. Ул университетның физика факультеты студенты чагында кулдан язып, Сталинга каршы листовкалар ябыштырып йөри. Анда турыдан-туры исемен атап, Сталинны гаепләп яза. Бу бит – 19 яшьлек студент егет эше. Бу гамәле өчен Адлер абыйны «сары йорт»ка ябалар.

Адлер абый җәмгатьчелеккә фантаст язучы булып танылды. Мин исә, фантастика жанрын, укучыга әйтәсе сүзен әйтер өчен, эзоп теле формасында кулланмадымы икән, дип тә уйлыйм. «Юл чатында» дигән әсәре бу җәһәттән бик гыйбрәтле, бик кызыклы. Анда герой борынгы Болгар чорына китә. Бу әсәр, әлбәттә, фантастиканың бөтен таләпләренә туры китереп язылган. Мине исә андагы кыю фикерләр таң калдырды. Әсәр язылган вакытта аның геройлары әйткән фикерләрне кистереп әйтеп булмагандыр дип уйлыйм мин. Геройлар чиркәү нигезендә калган кабер ташлары турында да, тарихи җирлектәге кабер сөякләрен җыеп, ашламага тапшырулары турында да сөйли. Әсәрдә бик күп тарихи фактлар бирелә. Әлбәттә, ул чакта бу әсәрне фантастика итеп кенә биреп булгандыр.

> Фантастика жанрында бик сирәкләр эшли ала. Татар әдәбиятында, гомумән, санаулы гына. Мәсәлән, Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт»е. Хәзрәт анда кесә телефоныннан сөйләшә. Бер карасаң, әсәрне күтәреп, бөтен дөньяга мактанырлыгыбыз бар. 1910 елда язылган әсәр бит бу! Адлер абыйны да күтәреп йөрерлегебез бар. Тик без

аның гыйлем иясе булуын, әйтик, берүзенең тулы бер институт эшен башкарып, «Миллият сүзлеге»н язуын һаман да дөньяга чыгара алмыйбыз әле.

«Гыйлем» берләшмәсе мөхәррире, Татар китабы йорты җитәкчесе **Айдар Шәйхин** исә, башка шартларда яшәсәк, Адлер Тимергалин әсәрләреннән күптән фильмнар төшерелер иде, ди:

– Фәнни фантастиканы иҗат итү өчен кешенең әдәби сәләте дә, күзаллавы да гади язучыдан киңрәк булырга тиеш. Ник дигәндә, фәнни фантастлар киләчәкне күзаллый. Моның өчен фәнни гыйлемең булу кирәк. Боларның барысына да ия булган шәхесләр гадәттә күп булмый. Безнең әдәбиятта андый кешенең булуы әдәбиятның өлгергәнлеген күрсәтә. Адлер абый – шул яктан безнең өчен мөһим язучы.

Дөнья күләмендә фәнни фантастика төрле жанрлар белән кисешеп яшәешен дәвам итә, ул үсештә. Бездә, киресенчә, юкка чыгу алдында. Юкса безнең гасырның соңгы дистә еллы гына да фәнни фантастлар өчен бик зур мөмкинлекләр бирә. Әмма фантастика өчен фәнни белемле булырга кирәк. Татар филологы яки журналисты булып фәнни фантастика иҗат итеп булмыйдыр. Син математик, физик яисә астроном да булырга тиешсең. Фантастика жанрының шушы хәлдә булуының төп сәбәбе гыйлемле кешеләрнең әдәбиятка килмәвендә. Шуңа күрә фәнни фантастика сүлпәнәйде. Нинди зур әсәрләр дә күренми, аның белән кызыксынган, системалы рәвештә иҗат иткән язучылар да юк. Гәрчә фәнни фантастиканы иҗат итәргә, аңа хәтта милли теманы күчерергә дә мөмкинлекләр бар.

„«Юл чаты» миндә Болгар чоры белән кызыксыну уятты. Әлеге чорның кайбер үзенчәлекләрен мин беренче тапкыр шушы әсәрдә күрдем һәм кызыксынып китеп, башка чыганаклардан эзләдем. Аның героеның мантыйк һәм схоластикага нигезләнгән бәхәстә катнашуы да кызыксыну уятты. Болар барысы да Адлер абыйның зур гыйлемгә ия булганлыгын күрсәтә. «Миллият сүзлеге» кебек эшкә алынган кеше ул – чыннан да, киң кырлы фикер иясе. Урта гасырдагы теологик бәхәсләрне дә белә, фәлсәфә сорауларын да, географияне дә, алдынгы технологияләрне дә яхшы белә. Менә шундый булырга кирәк. «Юл чаты» милли хәрәкәттә барган процессларны анализлавы белән дә кызыклы.

Яшьләр Адлер Тимергалин иҗаты белән бик кызыксына. Ул төрле сайтларда, социаль челтәрләрдә яши. Әйтик, «ВК»да төркемен булдырган Халит Әбделмән – Башкортстанда яшәп иҗат итүче язучы, шушы юнәлештә иҗат итәргә тырышкан сирәк авторларның берсе.

Адлер абый иҗатын популярлаштырырга кирәк. Аның алымнары күп төрле, ләкин без аларның бик азын гына кулланабыз. Аны киләчәкне фаразлаган, төрле ачышлар ясаган шәхес буларак күрсәтеп булыр иде. Аның әсәрләре актуаль һәм дөнья әдәбияты белән аваздаш. Мәсәлән, мин «Рибб Локсның үлеме» дигән кечкенә генә хикәясен бик яратам. Ул – кино булырлык әсәр. «Ерак планетада» дигәне дә шулай ук. Быел «Дюна» дигән фильм чыкты. Ул бик популяр. Ә бит бу фильм «Ерак планета» белән аваздаш. Әгәр без башка шартларда яшәсәк, Адлер абыйның иҗатын инде күптән киного күчергән булыр идек.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

«БӨЕКЛӘР ЭЗЕННӘН» СӘХИФӘСЕНЕҢ ВИДЕОСЫ – САЙТТА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ТАМГА

(ХИКӘЯ)

< Ахыры. Башы 4, 12, 19, 26 ноябрь саннарында

– Әти, мулла бабай нәрсәгә төрттерде ул? – диде егет.

Миннехан черек утын яккан мич төсле төтенле иде, илтифатсыз гына:

– Яшьлектәге йөрәк эшенә әчләре поша, улым, – диде.

– Нинди «йөрәк эше», әти?

– Аптыратма, улым. Бу авылда яшәрлек рәт юк икән безгә.

– Мин Наратлыктан беркая да күченмим, әти.

– Сиңа кем күченәбез ди, малай актыгы! Зиратның ярты ягында Солтанбәк нәселе!

Карт-коры: «Билалетдин әҗәл таягын кайсыбызга ыргытты икән?» – дип кыбырсыды. Авылда бүген-иртәгә үлем көтеп, хәл эчендә ятучылар байтак иде, ә таяк... Таяк шапылдамыйча гына Нуриханнар йортына төште. Баскан саен аяк астында җир калтыраткан сау-сәламәт ата, «йөрәк пешә» дип, өч көн ятакта аунады һәм бер сәер гадәте белән өнне алды. Төннәрен ул, саташып, бүре булып улый, бу улау җәйге авылның котын очыра иде.

Үләр алдыннан Миннехан улына дәште:

– Нурихан... Бүреләргә тимә... Ерткыч аулау миңа Ходайдан бирелгән җәза ие... Безнең нәсел каядыр каргалгандыр... Җүнле адәм кәсеп итеп таба малны... Наратлыкта яшәмә, еракка кит... Минем җәсәд зиратта Солтанбәкләрнең соңгысы булсын... Теге йөрәк эше дигәнем... Йөрәк эше... Улым, син Билалетдин кызын сүмә, син бит...

Миннехан аучының кинәт кенә сулышы киселде. Нәрсә әйтергә теләде ата? Алар безнең дошман, дидеме? Син кыздан яшьрәк, дидеме? Хикмәт яшьтә идемени? Ярату өчен дөньяда бернинди киртәләр юк. Атаның үлеме дә хисләрне сүндермәде. Ул кайгылы күз яшьләренә коенган мизгелләрдә дә Озын толым турында уйлады.

-3-

...Мирзабәк елмаеп уянды. Яхшы фал иде бу, яхшы фал. Димәк, йорт иясе нарасыйны ят итмәде. Бала үзе дә ата кулына бик тиз ияләшергә охшап тора. Җан тартмаса, кан тарта, ә монда тамгалы малайның җаны да җиңел генә нәсел җебенә ялганыр шикелле. Тик аның кайсы туфракта шытканын уйласаң гына укшыта башлый. Йөз белән чуалган хатынга ул якынаерга да тиеш түгел иде. Тагын бер тапкыр үкенечле ялгыш белән бәрелешмәс өчен нишләргә соң хәзер? Солтанбәк ирләренә генә хас кирелекне ничек сындырырга? «Малай минеке түгел!» – дип инкяр иткән Нурихан, сүзен таптап, «юк, минеке икән» дисә, нинди фаҗига! Әһә, Солтанбәк оныгы очсыз хатыннар белән мәшгуль, диячәкләр. Яратмасалар да, әле Наратлыкта аның дәрәҗәсе югары иде. Ул – гаярь аучы төпчеге ләса.

Ниһаять, Шәрифә... Гомер алмагачының бердәнбер һәм соңгы багалмасы... Үрелә, үрелә Нурихан, ә багалма иң биектә, менә әзәм, менә әзәм дигәндә генә, ботак, кулдан ычкынып, һавага атыла...

– Әйдә, улым, битеңне юабыз да ботка ашыйбыз, – диде әти кеше, малайны кочаклап. – Син яламасын өчен мин аны куе итеп пешердем.

Бала, иренен бөрештереп:

– Ау, ау, – диде.

– Өйдәш йонлачны сорыйсыңмы, улым? Ул бездә төн кунды. Аның – үз дөньясы, синең – үз дөньяң, улым. Ә, юк, савытка борын тыкма, тәз утыр, туры утыр. Мә кашык. Сине адәми сыйфатларга күнектерәсе бар шул, кыргый. Җәле, ач авызыңны. Җә, чәйнә, улым. Вәт маладис! Сиңа кием бөтәйтәсе иде, улым. Әтисе күлмәгенә уранып үсми инде тәти егетләр. Бер-ике сәгать уйнасаң, күрше авыл кибетеннән сиңа ярардай күлмәк-ыштан җыеп кайта инде әтиең анысы. Хәзер уенчыклар кертәм.

«Уенчыклар» бер тартма ядрә иде. Нурихан бу байлыкны пәрәвез сарган тузанлы иске келәттән тапты. Утыз ел хуҗасыз картайган йортта энәгә дә кагылмаганнар, ни азгын малай-шалайны да аучы йорты кызыктырмаган иде.

– Олысы-кечесе сезнең йорттан шикләнде, олан, – диде Фәсыйлә карчык. Наратлыкта Нурихан белән ул гына ачылып сөйләшә иде. – Нигезегез җенле ие, олан. Төннәрен ялгыз бүре җылый ие анда.

– Сез, урман астында яшәп, акылдан язгансыз, – диде ир.

– Язырсың да, олан. Авылда адәм заты әзәя, зират зурайган саен зурая, – дип уфтанды кендек әбисе.

Малай, ни хикмәт, «уенчыклар»ны күргәч, сөенечле авазлар чыгарып бытылдарга кереште. Күр инде син! Нәни чагында Нурихан да ядрәләр белән уйнарга ярата иде.

– Син тимерләр белән юан, улым, – диде ир, киенә-киенә. – Бабаң боларның рәхәтен күрмәде. Әҗәл комачаулады, әҗәл...

...Нурихан кар күмгән юлдан атын атлатып кына барды. Сафринәләр турында бер карачкы чайкала иде, менә ул абына-сөртенә каршыга килде.

– Тр-р, малкаеңны туктат, Нурихан!

Башына мамыгы коелган шәл бәйләгән, өстенә ямаулы сәләмә фуфайка игән Сафринә иде бу. Ирнең дилбегә чорнаган кулы калтырады. Белә! Баланың аңарда икәнен белә! Күзсез-колаксыз авыл диген син. Нишләргә? Юлын дәвам итәргәме? Кире борылыргамы? Хатын малайның эзли калса, капка белән ишек бикләнгән. Тәрәзәләр дә томаланган. Ядрәләр белән мавыккан Мирзабәк тавыш-тын чыгармас, шәт.

– Тукта, диләр, Нурихан! Синдә әзрәк баш төзәтергә юкмы? Шешәсе белән димим, күгәрчен тәпие чылатырлык кына. Төнката Орловка маржалары белән гөрләшкән идек.

Башка вакытта Нурихан сүгенер иде, бу юлысы, тотылудан курыккандай:

– Эчмим бит, миндә нинди аракы ди, Сафринә, – диде.

– Һи, беренче тапкыр исемем белән дәштең әле. Азгынбикә, дия идең гел, – дип кеткелдәде тешсез хатын. – Хет узышлый тәрәзәгә чиертер идең, җүнсез. Минем кочакта назланган сәгатьләреңне сагынмыйсыңмыни? Миндә бүгеннән аулак өй, иркәм.

Нурихан бөтен буе белән чанага сеңде. Нинди аулак өй?! Хатын аны юри сыный. «Бала миндә шул» дип танармы, янәсе.

– Орловкадан кайтарсалар – ишегалдында милиун эз! Ишек шыр ачык! Безнең чирләшкә җәфаны бүреләр апкиткән.

Сафринә чыркылдап көлде. Олыгайса да, хатын-кызның көлүе үзгәрми икән.

– Син әллә җүләрләндеңме?! – Ана дип саналган хатыннан мондый ук тупаслык көтмәгән иде ир.

– Ышанмасаң, Фәсыйлә түтидән сораш. Дәү генә бүре күтәргән иде, ди. Шәрфә сылукай тереләдеме әле? Минем сиңа иркенләп бер сер тишәсем бар, иркәм. Кичкырын кил...

– Юк, Сафринә!

– Һи, җансыз курчак! Сернең ахыры күңелсез була: син Шәрфәгә өйләнә алмыйсың!

– Тапталма, – диде Нурихан, дилбегәсен кагып.

Аңа Фәсыйлә карчыкның кылын тартырга кирәк иде. Кортка төнлә күргән кешесен таныды микән?

Тик ни ул, ни әби кыек бүкәнне туры ярмады.

– Нәстә диим соң инде итәген җилгә селкегән катынга, олан? Карамады баланы. Кешедән оят, эт имгәләде малай. Хайван да җәлли ие сабыйны. Өчәр көн өендә кунмас, Арлуфка ирләре белән типтерер ие. Җуклы-барлы пинсәмә ашаттым ашатуын Мирзабәк угланны. Тамагын ач итмәдем, Ходай риза булсын. Ие, эзләмәсен дип, бүре апкитте, дидем, ие.

Нурихан, дулкынлануын яшереп, учына йөткерде:

– Расмы соң бу... бу хәл? – диде. Калтыравык тавыш барыбер сата иде.

Карчык иргә үтәли тишеп карап торды.

– Һай ла, олан, һай ла! Сафринә акылга саеккан, ә син – таза-сау, камил бәндә. Ниткән бүре ди? Аллага шөкер, бала исән, аның кайгыртучысы бар. Чәй эчәсеңме?

– Рәхмәт, Фәсыйлә әби. Ашыга идем.

– Хәлемне белгәләп тор, олан. Заманында аул катыннарының әммәсен дә мин бәбиләттем, мин чирдән арындырдым. Үлсәм, садакаларыгыздан минем рухыма да өлеш чыгарыгыз. Синең дә кендек әбиең мин. Төннәрегезнең кай төшендә нинди миң-төртке бар – хәтерлим. Кашки нәсел тамгаларын да, ие, олан.

Нурихан хәйләкәр карчыкның кая табан сукрганын чамалый иде. «Әйе, малай минем өйдә, малайны мин – әтисе үстерәм», – дип, ирдән үз теле белән әйтерергә маташа. Ә Нурихан чарасыз: нәсел тамгасыннан да көчлерәк кирелек әскә калка... Инде кием кайгысы чүпкә әйләнде. Төнге вакыйгаларның көтелмәгән борылыш алуы ир файдасына түгел иде.

Мирзабәк ядрәләрне идәнгә тараткан, дөньясын онытып уйный иде.

– Улым, без синең белән кунакка барабыз, – диде Нурихан. Ул кинәт кенә башына суккан уен тормышка ашырырга тиеш иде.

Фәсыйлә – җир корты, җиде кат туфракны казып тикшермәсә, тынычланмый. Мөгаен, кичкә, мең сәбәп табып, ул Нуриханнарга сугылыр. Ә күрше авылда карчыгы белән генә Миннехан аучының яшьлек дусты яши иде. Өйләре җылы, үзләре ачык чырайлы. Нурихан базарга барышлый гел аларда туктала иде. Икеөч атнага баланы сыендырырлар, бәлки. Ә аннары күз күрер тагы. Иң мөһиме – бүген авылда гайбәт чүпрәсен күпертмәү. Шәрифәгә «эһ» дигән аваз да ишетелмәсен!

Боз шыгырдап туңган баскыч төбендә йонлач эт койрык болгый иде.

– Һоп, сикер чанага, хайван, – диде Нурихан. – Бабаңнарның күңеле иркен, син дә сыярсың.

ӘСӘРНЕҢ АХЫРГЫ ӨЛЕШЕ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** **vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.**

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 атнага бер, җомга килә ~~465 сум~~ **404,04 сум**

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә ~~1000,92 сум~~ **859,08 сум**

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru



Рәис Габдулла

26 ноябрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: Ишки, асла, Минһаҗ, баб, иялек, Наза, әгәр, Берн, Алиса, биек, Апе, Әтнә, тамак, чаука, фейхоа, Чип, енка, улар, угры. **Вертикаль буенча:** кам, Картуф, Сибай, Илназ, Ниамей, Шаһбан, спа, Баек, оешу, инҗир, Чан, әрбә, кур, лигнит, Учалы, Еники, кәрәкә, апорт.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җаваплар-ның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 Казанда Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты кайчан узды?
А) 1999;
Б) 2015;
В) 2013.

2 Ислам дине буенча татарларга табын әзерләгәндә нәрсә тыела?
А) исерткеч эчемлекләр кую;
Б) яшел төстәге җәймә куллану;
В) салкын ризык ашау.

3 Дмитрий Красильников кем ул?
А) Ромашкинодагы нефть ятмасын табучы;
Б) «Өч хатын белән тормыш» әсәрен язучы;
В) беренче милли китаплар бизәүче рәссам, журнал һәм газеталар өчен рәсемнәр ясаучы, реалистик иллюстрация остасы.

4 Төпләндерү – ул...
А) диалект сүз;
Б) колхозларны берләштерү;
В) КПСС милли сәясәт юнәлеше.

Җаваплар: 1) Б; 2) А; 3) В; 4) А.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 376

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73,
222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+